Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

10
октябрь 2018
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

МӘСНӘВИ ХӘЙРЕТДИНОВ «КӨЗГЕ ЖЫР».

Татарстанда ЮНЕСКО форумы

Республикабызда 4-7 сентябрьдә мәдәниятара диалог буенча ЮНЕСКО форумы узды. Чараның оештыручылары – Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча махсус илчесе Минтимер Шәймиев һәм ЮНЕСКО эшләре буенча РФ Милли комиссиясе.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +

10 (298)

октябрь 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

22

68 Эмил Җәләлетдинов: *«Яшьлеккә? Юк! Кире кайтмас идем...»*

78 **ҮЗЕМ ГЕНӘ ТҮГЕЛ**
Нурихан Фәттах

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Фәнис Яруллин**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
10 **Казан ханлыгының язмышы.** *Б.Хәмидуллин*
16 **Ямаширмә зиратында – Алтын Урда һәм Казан ханлыгы истәлекләре.** *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
22 **Ачлыктан соң Татарстан авыллары.** *Р.Сабиров*
28 **Эчкен татарлары.** *Р.Исакаев*
32 **Әхмәт бай.** *Р.Фәхреддин*
38 **Риза казый нәселе.** *Р.Шаһиев*
45 **Казиле мәчете һәм мәдрәсәсенең тарихы.** *Э.Гайнетдинова, Л.Закирова*
52 **Татар дөньясын яктырту: мәгърифәтчелектән – электр энергиясенә.** *З.Мингалиев*
58 **Муса Бигиев: «Киләчәк – исламиятнеке».** *А.Хәйретдинов*

ТАТАР ГАМЕ

62 **Сәхнә – аның тормыш аренасы!** *Г.Рәхим*
68 **Эмил Җәләлетдинов: «Яшьлеккә? Юк! Кире кайтмас идем...»**

ДИНИ МИРАС

74 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

78 **Үзем генә түгел.** *Н.Фәттах*
84 **Хәсән Туфан фатихасы белән...** *И.Фазлуллин*
85 **Рәшит Гәрәй шигырьләре**

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

86 **Хәйретдин Мөҗәй (1901-1944), Шамил Гәрәй (1916-1946)**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

88 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

90 **Аһәңи ләззәт чыганагы.** *Р.Гатауллин*
95 **Атлаган алга китәр.** *Ф.Җәүһәрова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

100 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
102 **Телебезне кадерләп саклыйк.** *Р.Юсупов*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
112 **Хәрби элемтәче һәйкәле**
114 **Киез итекләр иле**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Октябрь*

Заказ №Е-2520. Тираж – 2100 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 25.09.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Көзге җыр». 1979.
Мәснәви Хәйретдинов рәсеме

Фәнис Яруллин

(9.02.1938-8.12.2011)

Халыклар белән
Уйнаучылар бар.
Халык турында
Уйлаучылар бар.

Уйнаучыларның
Кулында власть.
Уйлаучыларның
Тик акыллы баш.

Власть – таш дивар,
Ул нык һәм каты.
Баш белән бәреп
Булмый шул ватып.

***

Акча бәясен
Алтын билгели.
Кеше бәясен
Халкы билгели.

***

Дөнья – камыт,
Туу белән киясең дә –
Булмый кабат салып.
Тормыш – тәртә,
Күпме генә чәбәләнмә –
Арасына кертә.
Язмыш – арба,
Гел шуны тартып йөрисең,
Кая гына барма. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

ГӘҮҺӘРШАД

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Әйе, энциклопедияләрдә түгел, тарих китапларында да аның турында берничә юл гына язылган. Ул, алда әйткәнебезчә, – Казан ханы Ибраһим белән Нугай бикәсе Нурсолтан кызы, Мөхәммәдәмин һәм Габделлатыйф ханнарның сеңлесе.

Нурсолтан улларын күбрәк яраткан, төрле сәбәпләр аркасында, кызы Гәүһәршад белән ул кадәр аралашырга, бәлки, аның мөмкинлеге дә, вакыты да булмагандыр. Өстәвенә, ханәкәнең холкы да «кәнфит» түгел. Шуңа күрә, ана белән кыз арасында табигый якынлык урнаша алмый...

Казаннан күкрәк баласы хәлендә алып кителгән һәм Кырымда үскән Гәүһәршад, әлбәттә, атасы хан булган илгә әйләнеп кайтырга ашкына. Аның бу теләге тагын шуның белән көчәя: Миңлемөхәммәд ханның варисы – Мөхәммәдгәрәй солтанның, беренче мәхәббәте Нурсолтанга дәрте суынмаса да, берзаман аның яшь кызына күзе төшә. Ул Гәүһәршад белән яшертен генә очрашуга ирешә, әмма йөзендәге чадрасын салдыруга, аның алдында ачы хакыйкать ачыла: Нурсолтанның кызы гүзәл анасына һич тә охшамаган икән. Кызып китеп, ул үзенә гашыйк җанны үпкәләтә-рәнҗетә, аның йөрәгендә төзәлмәс яра калдыра. Инде Гәүһәршад тәкәллефсез Мөхәммәдгәрәй солтаннан ераграк торырга карар кылып, Казанга китү көнен түземсезләнеп көтә башлый. Әмма Казанда да тынычлык юк икән, Мөхәммәдәминнең вафатыннан соң, Нурсолтанның икенче улы Габделлатыйф тәхеткә күтәрелер, дигән хәбәр таралгач кына, яшь ханәкә абыйсы хозурына барырга тәвәккәллек итә.

Ләкин ул арада Мәскәү кенәзе Василий III дилбегәне үз кулына алып өлгергән була инде...

Мөдәррис Вәлиев

***

Һиҗри белән 944 сәнәнең[1] кыш ахырында Мәскәүгә башында Шаһхөсәен сәед торган Казан илчелеге килде. Казанның максаты мәңгелек солых төзү иде. Кырым вәлидәсе Нурсолтан тарафыннан сөйләшүләр өчен ышанычлы җирлек әзерләп куелганлыгын Казанның яңа сәеде һәр адымында тойды. Мөхәммәдәминнең гозеренә күрә, Ходай Казанга тугрылыклы, биредәге хакимият тарафыннан якын күрелгән бояр Иван Челяднинны күндерде. Кенәзнең ышанычлы кешесе булган бу затка, Василий III колагына гына ишетелерлек итеп, Мәскәүгә каршы торуының чын сәбәпләре җиткерелде. Челяднин бояр бөек кенәзне, Мөхәммәдәмин үз дусларын бүтән сатмаячак, ул солых төзүне чын күңеленнән тели, дип ышандыра алды. Шулай итеп, килешүгә кул куелды һәм моннан соң чәчәк ату, янәшә тыныч яшәү

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

[1] Һиҗри белән 944 ел – 1511 елның сентябреннән 1512 елның сентябренә кадәр мөддәт.

еллары башланып китәр кебек иде. Ләкин Аллаһ Тәгалә хөкеме башкача булды.

Инде икенче елның җаендә үк Кырым ханы Миңлегәрәйнең уллары, картаеп килүче аталарының сүзен тыңламыйча, Мәскәү-Русь җирләренә һөҗүм иттеләр. Моңа ачуы чыккан кенәз Василий Габделлатыйф ханны зинданга ябарга боерды. Мәскәү кенәзләренең кулында озак елларга тотык һәм сарайдагы астыртын эшләрнең корбаны булган Габделлатыйф янә әсирлекнең бөтен авырлыкларын татыды. Бәхетсез анасы Нурсолтан күкләргә багып күпме генә дога кылмасын, Ходайга ялвармасын, Бакчасарай белән Истанбул аны иреккә чыгаруны ничек кенә таләп итмәсеннәр, кенәзнең каһәре төшкән ханга җиңеллек килмәде.

...Ә Шаһхөсәен сәед Казанга күптән көтелгән солых белән кайтты. Карачылар, аксөяк тарханнар, данлыклы угланнар җыелган, Мөхәммәдәмин үзе дә катнашкан хан диванында сәед мәңгелек солых турындагы фәрманны кыйммәтле фаянстан ясалган затлы савыт кебек чыгарып салды.

– Хәзер инде Мәскәү падишаһы безнең сәүдәгәрләргә сату-алу юлларын ачар, – дип хыялга бирелебрәк әйтеп ташлады олуг карачы Шаһйосыф. – Алар, шималь мехларын алып кайтырга кайчан мөмкин булыр икән, дип көтәләр, Казан базарларында шундый тауарның җитмәве сизелә.

Шаһйосыфның сүзләренә хаким гаҗәпләнмәде, Шириннар токымының инде күптәннән мех белән сәүдә итеп баеганын белә иде ул. Бәлки шуңадыр, хәзерге олуг карачының атасы, бер җитди гөнаһысы өчен җәзага тартылган Коләхмәд әмир гел генә мәскәүлеләр белән берлеккә тартылгандыр әле? Карачылар фәрманны кулдан-кулга йөртеп, агып торучы балавыз мөһерне күзләре белән капшый-капшый карадылар, тигез итеп сузылган юлларга игътибар иттеләр. Аргын ыруыннан булган әмир генә, фәрманга күз дә төшермичә, диван әһелләренең шатлыклы-әсәрләнгән чырайларына төкергән кебек, кычкырып сорый куйды:

– Явыз дошманыгыз белән төзелгән солыхка сөенәсезме?! Кичә ул дошманны кыйнадыгыз, ә бүген аның алдында бил бөгәсез, яугирләрегез җиңүе аркасында кулга төшкән әсирләрне Мәскәүгә озатасыз! Кайда соң сезнең акыл кылычыгыз, егетлегегез, Казан алыплары-алпавытлары?

Мөхәммәдәмин кинәт башын артка чөйде: моңа җавап бирми калырга ярамый – инде күптән Аргын әмирләре артыннан алар тырышып-тырмашып яккан канәгатьсезлек, нәфрәт кисәвенең әче, зәһәр төтене ияреп бара. Себер ханы кочагына кереп оялаган карт Уракны гына искә төшерү дә җитә. Аргын ыруыннан чыккан әмирләр, Олуг Мөхәммәд варисларыннан бигрәк, Шәйбанилар нәселенә шатланыбрак хезмәт итәләр, алар риза булсынга сугыш учагын дөрләтеп җибәрергә генә торалар.

– Ә без, ат сыртыннан кигәвен куып торучы юеш борынлы малайлар кебек, юаш сукачылар вә күндәм сәүдәгәрләр булып калырга җыенмыйбыз да! – дип кистереп җавап бирде хаким. Аннары, ачу ташкынын баса төшеп, ул үзен тиз генә кулга алды һәм инде сүзен тыныч кына дәвам итте: – Хан даругаларыннан салымнар, торакларыбызны һәм бичәләрне бизәргә түгел, ә игенчеләрне, гаиләләребезне саклар өчен утлы корал сатып алуга тотыла. Без Төркиягә, дин кардәшебез солтанга кәрван җибәрәбез, ул безне ташламас, гаскәребезне коралландырудан баш тартмас, иншәАллаһ. Халык хак әйткән: «Кем имин яшәргә тели, шул яуга әзерләнергә тиеш». Сез инде безне батыр-гайрәтле булмауда битәрләргә маташасыз икән, батырлык, егетлек бит берничә баскычтан тора, мөхтәрәм әмир. Беренче баскычта без дәһшәтле дошманны акылга утырттык, хәнҗәрләребезне үткерләп, мәскәүлеләрнең үз көченә чамадан тыш ышанган тәкәббер башларына ордык. Икенче баскычка күтәрелеп, җиңүләребезгә зирәклек вә акыл өстәдек. Хәзер безнең кулларыбызда – мәңгелек солых турында килешү, тик

безнең кирмәндә урысның гаскәрбашлары яшәми, диварларыбыз тышында аларның яугирләре тормый, бөек кенәз үзен атабыз дип түгел, ә тиңдәш ир туганыбыз дип зурлый! Гайрәтебезне югалтуда, йә, кем генә безне гаепли алыр икән?!

Хакимнең вәгазен колак торгызып, зур дикъкать белән тыңлап торган Казан аксөякләре кинәт дәррәү җанланып, хуплау авазлары һәм бер-берсен рухландыру сүзләре белән, Мөхәммәдәминне яклауларын белдерделәр:

– Дөрестән дә шулай: сугыш аны үз башыннан кичермәгәннәргә генә тансык!

– Урысларның көче иләмсез, ерткыч аюны нигә үчекләргә-үртәргә, аны баллы сүз белән сыйлап тору, ә үз умарталыгыңа аягын бастырмау акылга муафыйграк түгелмени?

Танылган акыл иясе Әл-Кавус Багдади урыныннан купты:

– Хак диндәге кардәшләрем, тиңдәше булмаган Җами[2] әйткән ләбаса: «Никадәр генә зур булмасын бөеклекнең шавы, аның да бар чиге, аңа да бар тышавы». Ни булганына шөкер кылыйк! Изге Коръәндә язылган бит: «Аллаһы, теләсә, барыбызны да бер кавем итәр иде, әмма ул безне аерып, сүздә, гамәлдә ярыштырып сыный!» Без Иблис-мәлгунь авызына ташланып, явызлык вә үчлек утында кыздырып, орыш-яу кылычы койсак, шул кылыч илә сугыш мәхшәренә керсәк, бөек Аллаһ Тәгалә безне үлем һәм исәпсез-хисапсыз бәлаләр белән җәзага тартмасмы? Кылычыгызны дошман сезгә янаганда гына күтәрегез, әгәр дошман солых сорый икән, аны саф күңел вә ачык йөз белән, үз туганыгыз кеби кабул итегез. Ләкин бу дөнья чиксез, ә күк йөзе һәрвакыт зәңгәр булачак, дип уйлаган, үзләре исә гел шундый яшь калып, көчләре ташып торыр, дип ышанучы беркатлы җиңел-җилпе егетләргә дә охшап калмаска кирәк. Яшьлек мәңгелек булмаган кебек, адәм балалары арасында мәңге тыныч яшәү дә тормышка ашмас хыял гына. Тыныч тормыштан да тизрәк уалучан савыт юктыр. Кулыгыз кылыч сабында хәлдә, зинһар, аны кынысыннан чыгармагыз...

Диван мәҗлесеннән соң, хаким бакчага, үзе «Акыл ияләре чатыры» дип атарга яраткан урынына юл тотты. Ул почмакта аның икенче төркем яраннары җыелучан. Алар комсыз байгуралардан һәм сарай куштаннарыннан бөтенләй үзгә, аерылып тора. Болар, фәлсәфи уйларга бирелеп, бер-берсенә бөек затларның үлемсез язмаларын укый, кайчак үз хезмәтләрен дә күрсәтеп алырга батырчылык иткәли. Биредә шагыйрьләр, фәйләсуфлар һәм һәртөрле акыл ияләре җыелыша. Мөхәммәдәмин алар арасында барган кискен һәм ихлас бәхәсләрне, сүз көрәштерүләрне ерактан ук ишетеп килде дә, дөрләп үсүче үрмәле гөлләргә уралган рәшәткәле «дивар» күләгәсенә беркавым сыенып, гәпләренә колак салып торды.

Мөэмин-дин кардәшләр яшәүче чиксез киңлекләрдән сараена килеп торган шагыйрьләр һәм акыл ияләре алдына шәраб салынган савыт куелган. Ул – хан өстәленнән бүләк итеп җибәрелгән. Бәхәсләшүчеләрнең кайберсе гөнаһ дип санаган гамәлне санга сукмаса, башкалары, кулларындагы бокалларны өскә чөеп, колмак белән йөзем кавышкан затлы эчемлекне мактап туя алмый.

– Ходай йөзем агачын үзе яратмадымы икән? – дип сораган була арадан берсе. – Ә ул Аллаһ тарафыннан яратылган икән, аңардан куылган эчемлек тә зур гөнаһ санала алмыйдыр!

Бүтәннәрдән ак киеме һәм уй-иятләре белән аерылып торган кырку холыклы галим – дин белгече исә үзенекен тукый:

– Мәшһүр Әбелфәрәҗ Исфахани[3] шәраб эчүнең Аллаһ кичерердәй дүрт фасылы турында әйтмәгәнмени?! Иң элек адәм баласы тавис кошына охшар, аннары маймун (маймыл) холкына күчәр, дигән ул. Тора-бара ул үзен арысланга тиң санап, үз көченә

[2] Җами – фарсы, таҗик шагыйре һәм XV йөз фәйләсуфы.
[3] X йөз шагыйре һәм гыйлем иясе.

нык ышанган, горур бер зат булып күренергә мөмкин. Әмма, соңгы чиктә, шул сәрхуш бәндә дуңгызга әверелә һәм, аның кеби, пычракта-быкырдыкта ауный.

– Сезгә җавап итеп, хөрмәтлем, бөек Әбу Гали ибне Синаның сүзләрен китерәсем килә. Ә бит ул кешеләрнең чирләрендә генә түгел, акыл-шәрифләрендә ни булганын да белеп торган! – дип кычкырды инде берничә бокалны бушатып өлгергән яшь шагыйрь. Ул, тәнен оета башлаган киң утыргычтан күтәрелеп, кычкырып шигырь укырга ук кереште:

Рухны күтәрә, баета шәп шәраб,
Гөлчәчәкләрдән дә хуш ислерәк ул, хәраб.
Ата сабагы кебек, ачыдыр вә татлы,
Мәнафигъ анда хата күрә, ә зирәк – чынлык вә якты.
Акыллы затларга шәраб зарар түгел,
Әмма ул – наданнарга агу вә үлем.
Аңарда тәм белән катышкан зәкъкум[4]*, –*
Булыр ул балга кушылган агулы ком.

Мөхәммәдәмин, артык түзә алмыйча, посып торган урыныннан чыкты да басып торган хәлендә, бары тик эсселектән тәмам кипкән-корыган, дымга сусаган җир генә җылы яңгыр тамчыларын комсызланып йоткан кебек, гаҗәеп шигырьләрне тыңлап торды, аларны аңына сеңдерде. Югыйсә, ул хан диванында нечкә күңелен көйдергән, җанын җәрәхәтләгән, йөрәк майларын суырган бүре көтүенә тап булган итеп тойган иде үзен. Бары тик монда, байлык артыннан куу урынына чынлык эзләүче көрәштәшләре, каләмдәшләре арасында гына, хаким үзен иркен һәм җиңел хис итә. Менә алар, аны күргәч, шатланышып күтәрелделәр. Шагыйрьләр һәм йолдызбагарларның, акыл ияләре һәм көйчеләрнең күзләре уртак яктылык – үзләрен сыендырган һәм аларны тиңдәш санаган әфәнделәренә мәхәббәт һәм хөрмәт хисе белән нурланып китте.

– Ә Сез, хаким, шәрабка ничек карыйсыз? Кичереп булмастай гөнаһмы ул, әллә бөек хозурлыкка бирелү шартымы? – дип сорадылар алар Мөхәммәдәминнән.

Күңеленә яраткан шагыйре Гомәр Хәйям робагые шунда ук җиңел генә килүен тоеп, ул елмайды:

Шәраб тыелган сый, тик бар «ләкин» дигән дүрт хикмәт:
Кем – кем белән, кайчан һәм чамасын белеп эчәме, – күзәт.
Шул дүрт шарт үтәлгән чакта гына –
Акыл белән тотканнарга – чәркә рөхсәт.

Бирегә килеп кунаклаганнарның барысы да, ханның тапкырлыгына сокланып, көлештеләр, ә әрсезрәк яшь шагыйрь хуҗага мөлдерәмә тулы бокал сузды:

– Әгәр безне үз күрсәгез, ерак илләр бүләге булган шушы зәмзәм суын уртлап куегызчы, хаким.

Мөхәммәдәмин бу беркатлы чакыруга каршы килмичә елмаеп, чынлык, зирәклек вә камиллек эзләүче япмасына төренеп, чатырга керде, бурзайдай тән сакчылары, сарайның ялагай аксөякләре, туйдырып бетергән хатын-кыз җәмәгате вә мәкерле дошманнар – һәммәсе ул күтәрелгән баскыч артында калды. Чатырдагылар, изге дога сәгате сукмыйча, хан үзенең акыл ияләреннән аерылмачагын беләләр иде.

***

Ханлык белән ундүрт ел буе тыныч кына һәм зирәк идарә итеп килгән Мөхәммәдәмин хаким һиҗри белән 948 сәнәдә бик каты сырхаулап китте. Казан Иленең бар тарафыннан иң яхшы табиблар килде. Кырым ханлыгы да дәвалау осталарын җибәрде.

[4] Зәһәр, үтерә торган агу.

Мәвараэннәһердән кодрәтле Көчкенҗу[5] хан табиблык осталарының иң маһиры булган акыл иясен юллады. Сәфәвиләр[6] дәүләте башында торган Исмәгыйль шаһ та, Казан Илендә аның сәүдәгәрләре дә һичкайчан кууылу-талануга дучар булмадылар. Шаһ беренче көннән үк тауларда гына табыла торган үлән-шифаларны үз кәрваны белән юллаган иде. Казан хакиме беравык җиңеллек сизенеп, яткан түшәннән торды, гадәти эшләренә керешге. Әмма чир ханны әҗәл тигәнәсендә рәхимсез кулы белән янә бугазыннан эләктереп-буып алды. Тиздән Мөхәммәдәмин зур диван – бөек киңәшмә җыеп алмакчы булды. Анда катнашырга танылган һәм йогынтылы аксөякләр, мәшһүр дин әһелләре, гаделлек сагында торучы казыйлар, кыю угланнар вә ясауллар чакырылган. Үз биләмәсеннән Гәүһәршад ханәкә дә дәшелгән. Көтеп алынган түрә-аксөякләр килә башлагач, хан аларны үзе каршыларга булды. Алтынланган мендәрләрендә яткан бөек хаким, Казан алпавытларының һәр адымын санап, карлыккан тавышы белән барысын да үзенчә озатты. Хаким авырлык белән генә шуны әйтә алды:

– Җирләребезне чәчәк аттырганы вә аңа куәт-кодрәт биргәне өчен Ходайга рәхмәт укыйк. Хакимегезнең йөрәге шул Җир хакына типте, ханлыктагы һәрбер затны кайгыртып яшәде. Инде бу йөрәк тукталырга вә хуҗасын Ходай каршына алып барырга уйлый.

Өсләренә котылгысыз зур кайгы-хәсрәт киләсен белгәнлектән тынып-катып калган сарай кешеләре арасыннан җиңел шау үтеп китте. Алар арасында ханның үлем хастасына бирелүенә эче пошмаган берәү дә юк, чөнки хакимнең гомер чырагы сүнә баруы, аның артында кара пәрдә булып билгесезлек торганлыгы аңлашыла иде.

Тыныч кына сәүдә итеп, табыш алып яшәгән халык, Мөхәммәдәминнең җаны күкләргә ашкач, кем кулына каласын, нәрсәгә әзер торырга икәнен белми.

Хаким авырлык белән генә уң кулын өскә күтәрде һәм барысы да кабат тынып калды:

– Адәм баласының гомере чикләнгән, язмыштан узмыш юктыр, үлем ачысын, сәгате суккач, һәркем татый. Сезне, тугрылыклы, акыллы алпавытларым, бүген шуңа чакырдым: белгәнегезчә, Аллаһ миңа варисым булырдай бала бүләк итмәде. Әмма әле бердәнбер ир туганым исән, аны усал тәкъдир Мәскәү иленең тотыгы итте. Илчеләрнең кичекмәстән Ибраһим ханның улын алып кайтуларын телим. Тәхетемдә башка варисларны күрмим һәм, Олуг Мөхәммәд ханның турыдан-туры нәсел дәвамчысы әле исән булганда, Гәрәйләр нәселенең күтәрелүен ишетәсем дә килми! Бөек ханлык әһле, шул ниятебезнең барып чыгасына дога кылыйк. Атларыгызны җигегез, кыйммәтле һәдияләр алыгыз. Мәскәү кенәзе белән сөйләшкәндә, төлке булыгыз да бөркет кебек кыюлык һәм очып куну сәләтегезне күрсәтегез. Кенәздән безгә хаким итеп Габделлатыйфны бирү вәгъдәсен алуга ирешегез!

Бу сүзләрне хуплап баш иючеләр арасыннан хан Гәүһәршадны гына аерып алды. Ул баш имәде, ә карашында – берүзенең каршы торуы чагыла, күзләре ризасызлык уты белән көйри иде. Моны күргән хаким үзендә кире сеңелкәше белән икәүдән-икәү генә калып сөйләшерлек көч тапты.

– Хәтерлим, Гәүһәршад, туганыңны дошман күрүең исемдә. Әмма вакыт дигән елга бөтен каршылыкларны ком кебек юа, ә озак аерылышып тору һәм югалтулар безне күндәмрәк, килешүчәнрәк итә. Бер Габделлатыйф кына бу ханлыкның алтын дилбегәләрен күтәрә ала, бездә бер кан ага, без бит – бөек Олуг Мөхәммәд нәселеннән! Үтенеп сорыйм, туганың белән килеш, ике бармак арасына ит үсми, мин киткәч, аңа булыш, якла.

Ханәкә, ризалашканын белдереп, баш какты. Мөхәммәдәмин ютәлли башлады, аны

---

[5] Шәйбанилар нәселеннән булган бу хан Мәвараэннәһердә (хәзерге Үзбәкстан җирендә) 1510 елдан 1531 елгача идарә итә.

[6] Бу дәүләт фарсы җирендә 1502 дән 1736 елгача яши. Исмәгыйль шаһ 1502 -1524 елларда хакимлек итә.

«Гәүһәршадның соңгы алышы». Зөфәр Хәкимов рәсеме

озакка сузылган каты ютәл бөгеп салды. Ул арада хезмәтчеләр, табиблар йөгерешеп килде, Гәүһәршад ишеккә таба чигенде, шулай да, чыгып барганда, аны ханның хәлсез тавышы куып җитте:

– Исеңдә тот, сеңлем, син бит сүз бирдең...

Ханәкә хәтерли иде, әлбәттә. Әмма ярым мәет адәмгә биргән вәгъдәнең бәһасе күпме? Кабер якасында торган кешенең хәлен җиңеләйтим, дисәң, котылгысыз үлемен яктырак, әҗәл ачысын татлырак итү өчен, аның колагына теләсә нинди ялганны тагарагы белән бушатырга мөмкин. Ә ханәкә элегрәк Габделлатыйфның үзенә карата никадәр кырыс, каты булуын да онытмый. Әле Казанга агасы ничек кайтыр – кулга ияләштерелгән бер җанвар булыпмы, әллә тырнакларын яшереп, теләсә кемгә ташланырга әзер торган барыс рәвешендәме?! Шул чагында аның абыкае нәрсәгә лаек икәнлеге күренер – яклаугамы, әллә яңа сугышкамы...

Дәвамы бар

Урысчадан Мөдәррис Вәлиев тәрҗемәсе ■

15 ОКТЯБРЬ – ХӘТЕР КӨНЕ!

Казан ханлыгының язмышы

Булат Хәмидуллин

ГАДИ ХАЛЫК ТОРМЫШЫ

Казан ханлыгындагы гади халык тормышына да тукталып үтик. Нәрсәләр эшләгән дә ничек яшәгән ул халык? Өлешчә җавапны Казан ханлыгын яулау сугышларында катнашкан кенәз, зур гаскәри берәмлек башлыгы Андрей Курбский язмаларыннан укып белә алабыз. 1550 нче еллар башында ул Казан ханлыгын яулап алу вакыйгаларында катнаша, ханлык биләмәсенең элек дошман яулары артык бимазаламаган төбәкләрендә дә була. Шул елларда күргәннәре турында кенәз нәрсәләр яза соң? Әлбәттә инде, Курбский да иң әүвәл «дошман татарлар»ны яман итеп күрсәтергә тырыша. *«Ул басурманнарны яулап алырга кирәк»*, – дип яза. Шул ук вакытта татарлар тормышының уңай күренешләрен дә читләтеп узмый, язмаларында теркәмичә калдырмый.

А.Курбскийның гаскәре Муром каласыннан чик буендагы Васильсурск кальгасына җиткәнче ачлы-туклы җан асрап килгән («до Суры-реки мучились от голода»). Ханлык җиренә кергәч кенә тамаклары бөтәйгән («черемисский хлеб был паче драгоценных калачей»). Әйе, Тау ягының ул өлешендә башлыча «чирмешләр» – марилар һәм чуашлар яшәгән. Баскынчылар Тау ягы җирләре буйлап Казанга юнәләләр. Ике якның да яуга барганда йөри торган юлы була бу – атлы, арбалы һәм меңләгән җәяүле яугирләр тарафыннан тапталып беткән урын. *«Сура елгасыннан соң без сигез көн буе кыргый кыр һәм урманнар аша бардык. Бу тирәләрдә авыллар юк диярлек («зело мало»), булганнары да еракта, күренер-күренмәс утыралар иде («были в укромных местах и незримы»)»*, – дип яза кенәз. Ул тирәләрдәге авылларның, ят күзләргә күренмәслек итеп, чокырчакырлы җирләргә урнашкан булуын башка байтак кына тарихчылар да искә ала.

Шуннан соң кенәзнең гаскәренә баскынчы яу-гаскәрләр тарафыннан тапталмаган, халкы даими рәвештә илбасарлардан җәбер-золым күрмәгән Казан-Арча арасында хәрәкәт итәргә, Арчаны яулап алырга әмер бирелә. Андагы халыкның күпчелеге татарлар белән марилар була. *«Монда басу-кырлар киң, иркен, игеннең төрлесе мул булып үсеп утыра («поля великие и зело преизобильные, хлебов всяких там такое множество»), – Авыллар еш утырган, йортлары төзек, матур («зело прекрасны»), малтуар көтүләре еш очрый («скотов различных стад множество»)»*, – дип, сокланып туя алмыйча яза Андрей Курбский. Казан ханлыгының яу-сугышлардан читтәрәк торган башка төбәкләрендә дә иген мул булып үстерелгәндер, мал-туар көтүләре Арча якларындагыдан ким булмагандыр, дип күзаллыйсы килә. Өстәвенә, әле балыкка бай мул сулы зур елгалар да күп булган бит бу ханлык җирләрендә, ягъни мондагы халыкның үзен матди яктан тәэмин итәрлек мөмкинлеге булган. Ләкин бик еш кабатланып торган яулар, сугышлар гына ул халыкка тыныч яшәргә ирек бирмәгән.

Әйе, кенәз Андрей Курбский ханлык кырларында мул иген игелгәнлеген дә тасвирлый. Шулай да Россиянең шуннан соң киләсе гасырлардагы күпчелек галимнәре исә

---

*Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында



1549 елда Сигизмунд Герберштейн китабында басылган карта

һаман да әле татарларны, кыргый халык, дип тасвирлый биргәннәр, *«күчмә тормыш белән яшәгән татарлар җир эшкәртү, иген игүгә әһәмият бирмәгән. Шуңа күрә утрак тормыш белән яшәгән күршеләрен талап көн күргәннәр»,* – дип исбатларга тырышканнар. Шундыйрак уйдырмаларга урын калдырмас өчен генә булса да, безгә күптән инде Курбскийның иҗтимагый һәм тарихи эчтәлекле хезмәтләреннән Казан ханлыгы вакыйгаларына багышланган өлешләрен генә булса да үзебездә аерым китап рәвешендә бастырып чыгару фарыз. Гәрчә кенәз калдырган тарихи язмаларда безнең халыкка карата кайбер тәнкыйди фикерләр әйтелгән булса да.

Казан ханлыгының иң якын күршесе Мәскәү кенәзлеге аның төп дошманы санала. Дөрес, ара-тирә Нугай Урдасы һәм Әстерхан ханлыгы белән дә тарткалашулар булгалаган, ләкин төп көрәш Мәскәү кенәзлеге белән Казан ханлыгы арасында барган. Тарихчылар бигрәк тә балигъ булмаган кенәз Иван IV тәхеткә утыргач, Казан ханлыгы тарафыннан оештырылган яу-баскынлыкның активлашуын билгеләп үтәләр. Һәм бу активлыкны аның Мәскәү кенәзлегендәге үзара буталыш-тарткалыш чорына туры килүе белән аңлаталар. Шул замандагы дин әһелләре тарафыннан язылган, патша Иван IV нең улы Федорга багышланган бер хезмәттә («Повесть о житии Фёдора Иоановича») яшүсмер Иван IV идарә итә башлаган елларда Казан ханлыгының Мәскәү кенәзлегенә каршы еш һөҗүмнәр оештырганлыгы, христиан динендәге кешеләрнең аңардан җәфа чиккәнлеге бик җентекләп бәян ителә. Бөек кенәз тирәлегендәге боярлар тәхеткә якынрак елышу өчен бер-берсе белән тарткалашкан еллар була ул. Аларның бер-берсеннән өстен чыгарга тырышуы кенәзлекне тотрыксызлык хәленә китерә. Ул язмаларда, нәтиҗәдә, Казан ханлыгы бу елларда берникадәр көчәя, дигәнрәк сүзләр дә теркәлгән.

Сафагәрәйнең әлеге чордагы сугышчан активлыгын үзара якын мөнәсәбәттә торган Кырым, Әстерхан ханлыклары идарәчеләре дә, Казан ханлыгындагы дин әһелләре һәм кайбер бәк-морзалар да «дошмани диндәгеләргә каршы изге көрәш» буларак та кабул

иткәннәр. Кайбер язмаларда Сафагәрәй хан исеме «дин өчен бөек көрәшче, оста гаскәр башлыгы» буларак та теркәлгән. Ә бит шул ук елларда ханлыкның үз халкы да зур зыян күргән. Күрше дәүләтнең бер-ике шәһәрен талап кайту өчен хан оештырган ул яуларда ханлыкның дистә меңләп кешесе төп эшеннән аерылып катнашырга мәҗбүр ителгән. Бу хәлнең исә халыкның яшәеше өчен зыянлы булганлыгын да билгеләп үтәргә кирәк. Күрше дәүләт җирләренә оештырылган әлеге яулар, башлыча, мал талау һәм «без җиңдек» дип әйтер өчен генә кирәк булганга охшый. Халыкка алардан әллә ни файда килмәгән. Киресенчә, оттырышлар күбрәк булган. Беренчедән, әйтелгәнчә, меңләгән кеше йорт эшләреннән аерылырга мәҗбүр ителгән. Икенчедән, нинди генә «изге көрәш» саналмасын, яуда үлем-китемнәр дә аз булмаган. Тарихчы Сәлам Алишев та: *«Сафагәрәй ханның Кырым сәясәтенә буйсынып идарә итү еллары үз дәүләтендәге халык тормышы өчен авырга килде»,* – дип яза.

МИТРОПОЛИТ МАКАРИЙ. МӘСКӘҮЛЕЛӘРНЕҢ 1545 ЕЛГЫ ҺӨҖҮМЕ

1540 нчы еллардан ике күрше дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр бераз үзгәрә. Бөек кенәз Иван IV инде буй җитеп килә. Идарәче боярлар төркеме дә алышына. М.Г.Худяков, А.Е.Пресняковның «Царственная книга» мәгълүматларына нигезләнеп, кырыгынчы еллар урталарыннан кенәзлек хөкүмәте белән идарә итүчеләр сафына бик тә үзсүзле дин әһеле, митрополит Макарий да кушылу турында яза, *«фактически власть перешла в руки русского духовенства»*, дип тә өсти. (Киләчәктә нәкъ шушы Макарий күрсәтмәләре нигезендә яуланган Идел буе халыкларын көчләп чукындыру хәрәкәте башланачак.) Боярларның кайберләрен идарәдән читләштерү кебек кискен чаралар күреп, үзара тарткалашуларга чик куела. Тарихчылар, башка боярларны өркетү өчен, яшүсмер Иванның шул еллардагы дәүләт идарәсе әһелләреннән булган А.Шуйскийны ач этләрдән талатып үтертүен дә хәбәр итәләр. Яңа идарә әмере белән, 1545 елның 2 апрелендә мәскәүлеләр Казан ханлыгына зур яу оештыра. Мәскәү гаскәрләре Казан ханлыгы биләмәсенә төрле тарафтан – Идел буйлап та, Нократ елгасы буйлап зур көймәләрдә Чулман-Камага төшеп, көнчыгыш тарафтан да һөҗүм ясыйлар. Дистә ел чамасы тыныч яшәгән Казан иле халкы өчен бу һөҗүм көтелмәгән була. Шул чорга караган рус язма истәлекләрендә, елъязмаларында казанлыларның Идел белән Чулман ягыннан оештырылган мондый зур һөҗүмне

Зөфәр Хәкимов рәсеме

көтмәгәнлекләре, шул сәбәпле алар сафында югалтуларның күп булганлыгы хәбәр ителә. Бер елъязмада, Зөя елгасы тамагындагы үз утарында морза Мортаза Тәфкилевнең гаиләсе үтерелә, улы белән үзе әсирлеккә алып кителә, дип язылган.

Казан елъязмачысы да әлеге һөҗүмнең ханлыкның төрле төбәкләренә зур зыян китерүе, яуда, татарлардан тыш, мари, мордва, удмурт, чуашларның җир биләмәләре тирәләрендә дә җитди сугышлар булуы, һәлак булучыларның күплеге хакында хәбәр итә. «Казан патшалыгы тарихы» («История о Казанском царстве») китабында *«рус воеводалары Казанга һөҗүм иткән очракта, шәһәрнең яулап алыну ихтималы булуы, бу вакытта шәһәрдә зур гаскәр тупланып өлгермәгәнлеге, бәк-морзаларның һәм ханның шәһәрдән читтә калганлыгы»* да теркәлгән. Хан бу көннәрдә ау кошлары һәм этләре белән ауда йөргән, аның белән аз санлы сакчылары («дружинасы») гына булган икән. Әмма Казанга оештырылган һөҗүм барыбер мәскәүлеләр өчен уңышлы тәмамланмый. Дошман Хан капкасын яндырудан башкага ирешә алмады, диелә ул вакыйгага багышланган язмаларда. Р.Фәхреддиннең «Казан ханнары» китабында мондыйрак җөмләләр дә бар: *«Ошбу гаскәр Казан тарафларын яндырды. Ханның бинаалары да янды. Күп адәмнәр үтерелде»*.

Соңрак бу яуның нәтиҗәләре тагын да фаҗигалерәк рәвеш алачак. Хан һәм аның якыннарында искәрмәстән килеп чыккан бу яуны оештыруда Мәскәүгә йөз тоткан бәк-морзаларның катнашы бардыр дигән шик туа һәм ул шик тиздән дөреслеккә чыга. Кырымлылар төркеме белән казанлылар арасындагы мөнәсәбәтләр кабат кискенләшә. Мәскәүгә йөз тоткан кайбер түрәләр җәзалап үтерелә, башкалары Иван IV хозурына яисә Нугай Урдасына качып котыла.

МӘСКӘҮ КЕНӘЗЛЕГЕ БЕЛӘН ЯШЕРЕН АРАДАШЛЫК. САФАГӘРӘЙНЕҢ КАЗАННАН КУЫЛУЫ ҺӘМ СӨЕМБИКӘГӘ ӨЙЛӘНҮЕ

Әйе, мондый шик туугa нигез дә була. Мәскәү кенәзлеге белән яшерен арадашлык беркадәр иртәрәк башлана. Узган елда ук «Булат Ширин бәк һәм бөтен Казан җире биләмәсе халкы» исеменнән Мәскәүгә яшерен рәвештә илчеләр җибәрелгән була. Алар бөек кенәзнең Казанга гаскәр юллавын үтенәләр, ул гаскәр Казан диварларына якынлашу белән үк ханның үтереләчәге яисә кулга алыначагы турында белдерәләр. Бөек кенәзгә илчеләр ханның азынуын, казанлыларны рәнҗетүен, Казан бәк-морзаларына тиешле түләмәләрне дә кайвакыт үзенең чакырып китерелгән кешеләренә – кырымлыларга алып бирү очракларын хәбәр итәләр. Ханлык халкыннан җыелган салымнарның да бер өлеше Кырымга озатыла, дип зарланалар. Димәк, Сафагәрәй хан бу чорда казанлыларга карата үзен бик дорфа тоткан, Казан халкы арасында канәгатьсезлек туган.

Ул вакытта мәскәүлеләр заговорда катнашучыларга ярдәм итәргә вәгъдә бирәләр. Нәтиҗәдә, әлеге яу оештырыла, диелә тарихи язмаларда. Шушы хәлләр ачыкланганнан соң, 1545 елның ахырында Сафагәрәй хан Мәскәүгә йөз тотучыларга карата кырыс чаралар күрә. Җәзалап үтерелүчеләр арасында идарәче диван башлыгы, олуг карачы бәк Булат Ширин дә була. *«Сошли с политической сцены царевна Говгоршад и князь Булат... Их кружок боролся с иностранным засилием, как с русским, так и крымским»*, – дип яза М.Г.Худяков. Өстәвенә, халыкка күптөрле һәм чамасыз зур салымнар салына. Салым акчалары Кырымга китеп бара. Шул вакыйгалардан соң, Казан халкы баш күтәрә.

Сафагәрәй ханны Казан тәхетеннән төшерү кузгалышы 1546 елның гыйнварында башлана. Казан тарихчысы ул вакыйганы болай бәян итә: *«Ханлык түрәләре белән бергә бөтен Казан халкы кузгалды. Төркем-төркем җыелган халык озакламыйча бергә кушылды, хан сараена таба юнәлде. Сафагәрәй хан чак кына үлемнән калды, ул, хатыннары һәм аз санлы үз кешеләре белән, Казаннан чыгып качты»*. Шәһәрдә калган кырымлыларның байтагы үтерелә.

Сафагәрәй әүвәл үз төркеме белән Әстерханга юнәлә. Казан тәхетен кабат яулап алу өчен гаскәр белән ярдәм итүләрен үтенә. (Кайбер чыганакларда хәбәр ителүенчә, аның бер хатыны шундагы кайсыдыр хан нәселеннән була. Әмма бу ханлыкта аларның бик еш алышынып торулары мәгълүм.) Әстерхан ханы биргән аз санлы гаскәр белән Сафагәрәй Казан тәхетен кайтарып ала алмый. Елъязмачы: *«После того пришед (в Казань), побился, да ничего не учинил... Ушел в Ногайское княжество, пришёл к Юсуфу князю»*, – дип яза. Шулай аз санлы гаскәр белән уңышка ирешә алмагач, ул, ярдәм сорап, Нугай Урдасының зур олыс башлыгы Йосыф морзага мөрәҗәгать итә. «Казан тарихы» авторы нәкъ шул вакытта ханның Сөембикәгә өйләнүе хакында яза. (Алда әйтеп үтелгәнчә, Сафагәрәйнең өлкән хатыннарының берсе дә шул нәселдән – Мамай морза кызы була.)

ЯҢАДАН ШАҺГАЛИ. САФАГӘРӘЙНЕҢ КАЗАН ТӘХЕТЕН ЯУЛАП АЛУЫ. КАЗАН АКСӨЯКЛӘРЕНӘ КАРАТА РЕПРЕССИЯ. НУГАЙЛАР БЕЛӘН МӨНӘСӘБӘТ

Сафагәрәй Казаннан куылганнан соң, кайбер бәкләр тәхеткә яңадан Шаһгалине чакырып алалар. Аның, сөргеннән кайтып, Мәскәүдә яшәгән чагы була. Ханлыкның яңа идарәчеләре арасында кырымлыларның идарә итүенә каршы эш йөрткән Нарыйк бәк улы Чура белән Кадыш бәк тә була. Шаһгалинең Казанга килүенә алар да ризалаша. Һәм 1546 елның 13 июнендә Шаһгали, Касыйм татарлары атлылары һәм Мәскәү кенәзе Д.Ф.Бельский җитәкчелегендәге мең кешелек гаскәр белән, Казанга килә. Ләкин казанлылар шәһәргә йөз кешелек атлы белән Шаһгалинең үзен генә кертәләр. Башка яугирләр, шул исәптән Д.Ф.Бельский үзе дә шәһәр читендәге бистәләргә генә урнаштырылалар. Аларга Шаһгали белән якыннан аралашу тыелган була. Шул рәвешле Шаһгалине бу җәйдә казанлылар тулы вәкаләтле хан буларак танымый диярлек. Шуңа күрә ул Казанда бер ай чамасы гына була да, үзенә карата берәр төрле чара күрүләреннән шикләнеп, кабат үз тарафына кайтып китә.

Шул ук көздә Сафагәрәй хан, Нугай Урдасы гаскәре ярдәмендә, Казан тәхетен яулап ала. Һади Атласи: *«Нугайлар гаскәре башында аны Казанга Йосыф морзаның улы Юныс озата килә»,* – дип хәбәр итә. *«Ханның хатыннары нугайлар илендә калдырылган була. Алдагы җәйдә, аларны кайтаруны сорап, Сафагәрәй Йосыф морзага илче җибәрә. 1547 елда Юныс морза хан хатыннарын озатып куя... Сөембикә яңадан Казанга кайта. Шуннан соң Үтәмешгәрәй туа»,* – дип яза бер рус авторы.

Сафагәрәй тәхеткә утыру белән үк үзенә каршы баш күтәргән казанлыларга карата янә катгый чаралар куллана. 1546 елның көзендә байтак кеше, шул исәптән Чура бәк тә җәзалап үтерелә. Бәк-морзаларның берише Нугай Урдасына яки Мәскәү кенәзлегенә качып котыла. Рус елъязмачылары 1546 елның сентябренә Мәскәү тарафына качып киткән гаиләләр санының 76га җитүен теркәгәннәр. Алар арасында татарның билгеле шәхесләреннән Кулуш, Колчура, Терегул бәкләр, Нарыйк бәкнең улы, Чура бәкнең бертуганы Галикәй һ.б. була. Аларның кайберләре Мәскәү кенәзлегенә хезмәт итә башлый, байтагы соңрак Казанны яулап алу сугышларында да катнаша. М.Г.Худяков һәм башка авторлар кырымлылар хакимиятен танымаган бәк һәм морзаларның Казан ханлыгы язмышы хәл ителгәндә дошман көчләренә бердәм булып каршы тора алмавында Сафагәрәй ханның гаебен дә күрәләр. Сафагәрәйнең чамадан арттырыбрак яу-сугышлар белән мавыгып китүенә, ике күрше дәүләт арасында тотрыклылык булмавына каршы торучы аксөякләрне М.Г.Худяков та үз хезмәтендә аклый. *«Гәүһәршад белән Булат бәк тирәсенә тупланган төркем вәкилләренең эшчәнлеге Казан ханлыгы тарихында зур урын алып тора. Дөрес, әлеге эшчәнлеккә нисбәтле мәгълүматлар әлегә күп түгел. Булган кадәресеннән шунысы ачык – алар, барлык дәүләти һәм сәяси көчләрне*

бергә туплап, бердәм булып, Казан ханлыгы дәүләтчелегенең киләчәге, аны саклап калу өчен тырышканнар... (Путем примирения политических партий, старались за единение всех казанцев вокруг своей государственности)». Хаҗитархани да Казан ханлыгына багышланган дастанында Булат Ширинне *«вилаятьнең инсаннарына юл күрсәтүче»*, дип бәяли.

Сафагәрәй хан исә үзбаш булып кына идарә итәргә ниятләгән. Бу – ул чордагы күпчелек ил башлыкларына хас омтылыш. Шул рәвешле, ханның соңгы еллардагы идарә ысулы ханлыкны бик авыр хәлгә куя. Күпчелек елъязмачылар, 1546 елдан соң ханлык хөкүмәтендә дә кырымлылар өстенлек итә, дип икърарлыйлар. М.Г.Худяков та: *«1546 елдан соң Сафагәрәй кырымлыларны тәхеткә якынайтты. Казанда чит ил кешеләреннән торган хөкүмәт оешты. Хөкүмәт җирле гаскәргә түгел, бәлки яллы гаскәргә таяна... Сафагәрәй хөкүмәте бу дәвердә фәкать күрше илгә яу оештыру кебек эшләр белән мавыкты»*, – дип яза.

Ханның Казан аксөякләренә карата кылган явызлыклары, Казанга Кырым кешеләрен күбрәк китерергә тырышулары өстенә, ул әле «яшь каенатасы» Йосыф морза белән дә араны кискен өзә. Нәтиҗәдә, әлеге елларда Казан тәхете даирәсендә дә тынычлык булмый. Нугайлар гаскәре ярдәмендә Казанны кабат сугышып алганда Сафагәрәй хан аларга төрле-төрле вәгъдәләр бирә. Аерым алганда, Тау ягы белән Арча ягы тарафларыннан салымны җыюны аларга тапшыруны вәгъдә итә. Юныс морзаны Казанга чакырмакчы була. Ләкин, тәхетне кабат биләгәч, вәгъдәләрен үтәми, оныта. Һ.Атласи, борынгы китапларга, шул исәптән күпчелек тарихчылар искә алмаган XVIII йөз авторы Н.И.Новиков язмаларына да нигезләнеп иҗат ителгән «Сөенбикә» исемле тарихи хезмәтендә: *«Йосыф морза улы Юныс Казан бәге булырга телидер иде. Ләкин аның уйлаганы булмый кала. Шуңа күрә ул (да) Казан йортына ачулы иде. 1549 елның җәендә дә ул Казанга килеп, бәклеккә алуны үтенде. Аны Казанга кертмәделәр. Байтак кына кешеләрен дә кырдылар»*, – дип яза. Ә бит бу вакытта, 1549 елның җәендә, «усал, сүзендә тормас» Сафагәрәй дә юк инде. Юныснең үз гаскәре белән Казанга килеп төпләнүен, Сөембикә апасының иң якын киңәшчесе һәм ярдәмчесе булуын барыбер кемнәрдер теләмәгән. Кыскасы, Юныснең Казанда калуын теләмәүчеләр төркемендә Сафагәрәй кешеләре булганлыгын фаразларга мөмкин. Чөнки үзе исән чакта да ханның җитәрлек дәрәҗәдә оста яугир тәҗрибәсе туплаган Юныс морзаны Казанда калдырасы килмәгән.

Биргән вәгъдәләрен үтәмәгән хан исән-имин вакытта ук Нугай Урдасы бәкморзалары Казан ханлыгы җирләренә яулар оештыру белән яный башлыйлар. Рус елъязмачылары да Сафагәрәй ханның үз сүзендә тормавы аркасында ханлыкның бу елларда ике ут арасында калуы хакында хәбәр итәләр. Югыйсә, Казан ханлыгына мәскәүлеләрнең зур явы ябырылган көннәрдә, 1552 ел җәе башында, Йосыф бәк ярдәмгә ике мең кешелек атлы гаскәр җибәрә. Ул гаскәр, Япанчаның атлылары белән берлектә, Казанны камап торган дошман көчләренә актив һөҗүмнәр ясый. (Берничә тарафтан килеп тупланган Япанча гаскәрендә җәмгысе утыз мең чамасы атлы булган, дип исәпләнә.) Соңрак Йосыф бәк, азатлык сугышларында катнашу өчен, дип, казанлыларга ярдәмгә икенче улы Гали Әкърам җитәкчелегендә янә гаскәр җибәрәчәк. Әгәр элегрәк Сафагәрәй һәм аның төркеме белән ике арада каршылык килеп чыкмаган булса, Казан ханлыгы хәтәр көннәр кичергәндә ул зуррак гаскәрләр дә җибәрә алган булыр иде. Һади Атласи, башка чыганакларга нигезләнеп, Йосыф бәкнең Сафа киявен үз итмәгәнлеге турында яза.

Дәвамы бар ■

ЯМАШИРМӘ ЗИРАТЫНДА – АЛТЫН УРДА ҺӘМ КАЗАН ХАНЛЫГЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

Борынгы кабер ташлары – татар авылларының барлыкка килгән чорын билгеләүдә ышанычлы чыганак. «Татар энциклопедиясе» кебек абруйлы басмаларда да мондый дәлилләрнең тиешенчә исәпкә алынып бетмәве кызганыч, әлбәттә.

Татарстан Республикасының Биектау районы Ямаширмә авылы зиратындагы борынгы ташъязма (эпиграфик) истәлекләрнең иң әүвәлгесе 1382 елгы, тагын сигезе XVI гасырның беренче яртысына – Казан ханлыгы чорына карый. Иң мөһиме шул: әлеге зират хәзерге көндә дә файдаланыда. Бер үк зират эчендә сакланган төрле чор истәлекләре XIV гасырдан хәзергәчә дәвам иткән өзлексез тарихны исбатлый. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә Ямаширмә авылының Казан ханлыгы дәвереннән мәгълүм икәнлеге, ә энциклопедиянең 6 нчы томында 1565-1567 еллардан билгеле булуы әйтелгән[1]. Билгеле, бу очракта рус тарихи чыганакларының нигез итеп алынуы, шуларга өстенлек бирелүе күренеп тора. Әмма Ямаширмә авылының үзендә гасырлар буе сакланып килгән һәм галимнәр тарафыннан моңарчы өйрәнелеп, китапларда басылган[2] үзебезнең татар чыганагы санга сугылмау – тарихи фальсификациянең ачык мисалы.

[1] Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: ТР ФА Татар энциклопедия институты, 2002. – Б.803; Татарская энциклопедия: Т.6: У–Я. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2014. – С.516.
[2] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М., Л.: изд-во АН СССР, 1960. – С.21, 25, табл. 44; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.117; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. – Казан: изд-во «Мастер-Лайн», 1999. – С.33, 86.

Ямаширмә авылы зиратындагы эпиграфик истәлекләрне беренче күреп укуыбыз 2004 елда ук булган, ләкин мәкалә язып бастыру дәрәҗәсенә җитми калган иде. Инде 2017 елның 1 май, 11 октябрь көннәрендә ташъязмаларны җентекләп өйрәндек, текстларын укыдык, үлчәмнәрен алдык, фотога төшердек. Кызганыч, истәлекләрнең күбесе шактый таушалган, язулары ашалган – озаклап укуыбыз, кайбер катлаулы сүзгыйбарәләрнең һәм исемнәрнең мәгънәсен төгәл ачыкларга тырышуыбыз шуның белән дә бәйле.

Хәзерге вакыткача сакланган 9 борынгы кабер ташының төгәл еллары ачыкланганнары дүртәү: 1382, 1520, 1521 һәм 1539 елгылар. Калган бишесен, калып-рәвешләренә, язу һәм бизәлеш фрагментларына, үлчәмнәренә нигезләнеп, XVI гасыр (Казан ханлыгы чоры) истәлекләре буларак тәгаенләдек. 1382 һәм 1520 елгы ташларның текстлары (беренчесенең фотосы да) Һ.Йосыпов хезмәтенең кушымта өлешендә басылган[3]. Татарстанның археологик һәйкәлләре белешмәлегендә Ямаширмә зиратында барлыгы 7 ташъязма ядкәр барлыгы теркәлгән. Тагын икесе, димәк, ни сәбәптәндер, игътибардан читтә калган.

Алга таба ташъязмаларның текстларын һәм тасвирламаларын тәкъдим итәбез, аларга карата искәрмәләр, ахырда сүзлекчә бирелә:

№1. ***Габделмөлук Габделҗәббар улына куелган таш*. 1382 ел***

Алгы ягында (уйма язулы):

1) ...
2) көллү хәййү сәйәмүт
3) Һу[әл]-Хәййү әл-ләзи лә
4) йәмүт
5) бисмиллаһ[ир]-Рахман[ир-Рахим]
6) әл-хөкме Лилләһи [әл-Гали әл-Кәбир]
7) көллү нәфсин заикател-мәүт сүммә [иләйна түр-]
8) [-җәгун тарих] йите йөз сиксән түрүтдә
9) [җөма]диел-әүвәли аеның [бөрҗендә]**
10) ирдекем Габделҗәббар угылы Габд-
11) -елмөлүк иллик биш йәш[ендә] ... [кил-]
12) -гәндә шәһид ...
13) Тәгалә рәхмәт кыйлсын амин йа Ра[ббил-галәмин]
14) ...

Үлчәмнәре: 107 х 50 х 12 см.

---

*Бу ташның тексты басылган: Юсупов Г.В.Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 44. – Һ.Йосыповның әлеге хезмәтендә ташъязма текстының 1-4 юллары юк, ягъни ташның өске өлешендәге йолдыз эченә дүрт юл итеп уелган сүзләр кермәгән; 9 юл ахырындагы сүзне ул «берендә» дип укыган, ә без «бөрҗендә» дип тәгаенләдек;

---

[3] Юсупов Г.В. Күрсәтелгән хезмәт. – Табл. 44; текст 4.

кеше исеме анда Габделҗәббар угылы Инүк(?) дип бирелгән булса, без аны Габделҗәббар угылы Габделмөлүк дип укыдык.

**Һиҗри 784 елның җөмадиел-әүвәл ае милади 1382 елның 13 июленнән 11 августына кадәрге арага туры килә.

№2. ***Чура Ходайдат улына куелган таш*. 1520 ел***

Алгы ягында (уйма язулы):

1) Һу әл-Хәййү
2) әлләзи [лә йәмүт]
3) [вә көллү хәййү]
4) [сә-йәмүт] ...
5) ...
6) ...
7) калә эн-нәби галәйһиссәлам [әд-дөнья]
8) [сәгатүн] фә-әҗгальһа [тагатән]
9) көллү нәфсин заикател-мәүт сүммә иләйна түрҗәгунә
10) [калә эн-нәби галәйһис-сәлам әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти]
11) тарих тукуз йөз йикерме алтыда
12) мөбарәк зөлхиҗҗә аеның икесендә**
13) ирдекем Ходайдат угылы Чура кырык
14) йәшендә дарел-фәнадин дарел-бәкага
15) рихләт кыйлды Хакъ Тәгалә рәхмәт
16) кыйлсун амин

Үлчәмнәре: 126 х 52 х 22 см.

---

*Бу ташның тексты басылган: Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: текст 4. – Һ.Йосыпов хезмәтендә ташъязма текстының 3-4, 9-10, 16 юллары юк, ә 12 юлда «мөбарәк» сүзе генә бирелгән.

**Һиҗри 926 елның 2 зөлхиҗҗә көне милади 1520 елның 13 ноябренә туры килә.

№3*. ***Хуҗабай Янбай улына куелган таш. 1521 ел***

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә көллү нәфсин заикат-
2) -ел-мәүт калә эн-нәби галәйһис-сәлам әд-дө-
3) -нья сәгатүн фә-әҗгальһа тагатән ...
4) тарих тукуз йөз йикерме йитедә
5) шәүвәл аенда** ирдекем Янбай
6) угылы Хуҗабай даре фәнадин даре
7) бәкага рихләт кыйлды нәүвара Аллаһу кабриһи

Уң ягында (күпертмә язулы):
1) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары
Сул ягында (күпертмә язулы):
1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари
Үлчәмнәре: 142 х 45 х 18 см.

*Ташъязма тексты беренче тапкыр басыла.
**Һиҗри 927 елның шәүвәл ае милади 1521 елның сентябрь аена туры килә.

№ 4*. ***Туктамыш Тук улына куелган таш. 1539 ел***
Алгы ягында (күпертмә язулы):
1) Калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә вә ма тәдәрри нәфси баи арди тәмәүет вә
2) калә ән-нәби галәйһис-сәлам әд-дөнья сәгатүн фә-әҗгальһа тагатән саддака
3) Аллаһу әл-Мөлүк тарих тукуз йөз кырык бишдә зөлхиҗҗә(?)**
4) аенда ирдекем Тук угылы Туктамыш
5) ... сикез(?) йәшендә дарел-фәнадин...
Уң ягында (күпертмә язулы):
1) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ...
Сул ягында (күпертмә язулы):
1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари
Үлчәмнәре: 130 х 51 х 24 см.

*Ташъязма тексты беренче тапкыр басыла.
**Һиҗри 945 елның зөлхиҗҗә ае милади 1539 елның апрель-май айларына туры килә.

№5. ***Кемгә куелганы билгесез таш. XVI гасырның беренче яртысы***

Уң ягында (күпертмә язулы):

1) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары

Сул ягында (күпертмә язулы):

1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари*

Үлчәмнәре: 118 х 52 х 17 см.

*Бер янына төрки-татарча, икенче янына гарәпчә уелган бу шигъри юллар Казан ханлыгы чоры эпиграфик истәлекләренең күпчелегендә очрый.

Язулары җуелган, өлешчә җиргә баткан, безнең тарафтан шартлы рәвештә 6-9 саннары белән номерланган ташъязмаларның кемнәргә куелганлыклары билгесез, әмма, һичшиксез, алар – XVI гасыр истәлекләре. Үлчәмнәре түбәндәгечә: 47 х 45 х 20 см; 72 х 38 х 13 см; 37 х 27 х 8 см; 50 х 20 х 10 см.

* * *

Сүзебез ахырында Ямаширмә авылы зиратының гарәп язулы тагын берничә ташы турында әйтик. Шушы авылда яшәүче Рәдиф Яруллин зираттагы бер ташъязма истәлекнең сөекле шагыйребез Габдулла Тукайга бәйле булуы турында белдергәч, аны да карап, мәсьәләне ачыкларга тырыштык. Рәдиф әфәнде бу кабергә 2014 елда яңа чардуган ясатып куйдырган. XX гасыр башына караган кабер ташының язулары шактый таушалган. Сакланган хәтле өлешеннән аның Сиражетдин мулланың кызы Һадиягә куелганлыгын укыдык. Ул 1913 елның 6 гыйнварында вафат булган. Өч тарафы язулы ташта кабер иясенең Шаһиәхмәт(?) Фазлыйәхмәт улы Хәмзиннең хатыны, шәригать хөкемнәрен зур тырышлык белән укыткан тирән белемле («суфия вә галимә») мөгаллимә булганлыгы теркәлгән.

Әлеге Сиражетдин хәзрәт кызы Бибиһәдиянең (1857-1913) Габдулла Тукайга турыдан-туры кан кардәшлеге булмаса да, ике арада бәйлелек бар: Тукайның әтисе Мөхәммәтгарифның беренче хатыны Бибигафифә (1843-1885) дә Ямаширмә авы-

лы мулласы Сиражетдин Нәҗметдиновның кызы булган[4]. Мөхәммәтгариф белән Бибигафифәнең кызлары Газизә (1877-1963) – Габдулла Тукайның яраткан апасы. Хатыны Бибигафифә вафат булгач, Мөхәммәтгариф мулла Бибимәмдүдә Зиннәтулла кызына өйләнгән һәм аларның уллары – булачак мәшһүр шагыйрь Габдулла туган. Ә Ямаширмә зиратына җирләнгән Һәдия Сиражетдин кызы – Бибигафифәнең бертуган сеңлесе һәм, аңлашылганча, Г.Тукай белән Һәдия арасында турыдан-туры нәсел бәйләнеше юк.

Бу зиратта гарәп язулы, XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башына караган тагын берничә ташъязма истәлек бар. Шуларның берсе – Бибизөбәйдә Мохтар кызына куелганы ташлар уйган мәшһүр оста – Мүлмә (Мулла Иле) авылының Фәтхелкадыйр мәзин Кәлмитев тарафыннан эшләнгән.

СҮЗЛЕКЧӘ:

Аллаһу әл-Мөлук – Аллаһ – хаким;
әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти – дөнья – ахирәтнең иген кыры;
әд-дөнья сәгатүн фә-әҗгальһа тагатән – дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр;
әл-Гали – Бөек (Аллаһ);
әл-Кәбир – Олуг (Аллаһ);
әл-хөкме Лилләһи – Аллаһның хөкеме;
әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, мәңгелек түгел – Аллаһның аңа әмере юк;
Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим – рәхимле, шәфкатьле Аллаһның исеме белән;
бөрҗендә – ай эчендә;
вә – һәм;
дарел-бәкага – мәңгелек дөньяга;
дарел-фәнадин – фани (вакытлы) дөньядан;
ирдекем – иде;
йа Раббил-галәмин – йә, галәмнәрнең Раббысы (ике дөньяның тәрбиячесе, хуҗасы);
калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә – һичбер кимчелексез бөек Аллаһ әйтте;
калә ән-нәби галәйһиссәлам – Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламнәре булсын) әйтте;
көллү нәфсин заикател-мәүт суммә иләйна түрҗәгунә – һәр җан үлем ачысын татыр, барыбыз да аңа кайтарылачакбыз;
көллү хәййүн сә-йәмут – һәр тереклек үлә;
күрәрмән дөньяны вәйран бары бакый ирмәс һәмишә йук карары – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, мәңгелек түгел – Аллаһның аңа әмере юк;
нәүвәрә Аллаһу кабриһи – Аллаһ каберен нурласын;
рихләт кыйлды – күчте;
саддака – хак сүз;
Һуа әл-Хәййү әлләзи лә йәмүт – ул (Аллаһ) үлемсез. ■

[4] Рәсүлева З.Ә. Тукай эзләреннән. – Казан: Татар. китап нәшр., 1985. – Б.13.

Безнең мирас №10 октябрь 2018

АЧЛЫКТАН СОҢ ТАТАРСТАН АВЫЛЛАРЫ

Рәүф Сабиров*

АВЫЛГА ЯКЫН КИЛҮ ӨЧЕН АНЫ ЯХШЫ БЕЛЕРГӘ КИРӘК

Партияне авылга якынайту, хөкүмәт оешмаларын авыл хезмәт халыкларына таба китерү, мәгърифәт, мәдәният, гыйлем вә сәнгатьле шәһәр белән алпавытлар, патшалар итеге астында ятып тупас, надан калган авыл арасында өзелмәслек нык элемтә ясау... – Менә безнең партиябезнең соңгы көннәрдә ташлаган лозунглары. Бу бөек лозунгларны гамәлгә ашыруда партиянең бөтен оешмалары ашыгып эшләп яталар. Әлеге мәсьәләләрне хәл кылу өчен төрле планнар төзелә, төрледән-төрле чаралар күрәләр. Табигый, бу чараларның берсе, бәлки бигрәк дә мөһим булганы – авыл тормышы белән якыннан танышу, ягъни авылның икътисади, иҗтимагый тормышын, авылдагы гыйлем-мәгърифәт учакларын, партия һәм совет оешмаларының куелышын ныклап тикшерү белән булырга тиеш. Шуннан соң гына инде авылга чын мәгънәсе белән якын килергә, аның бөтен халәт рухиясе белән танышырга мөмкин булачак. Татарстан өлкә комитетының 20 нче июльдә төзелгән «Татарстан авылларын тикшерү комиссиясе» дә үзенең төп максаты итеп әнә шул югарыдагы вазыйфаларны алган иде.

Соңгы елларда башыннан зур икътисади һәм сәяси үзгәрешләр кичергән татар җөмһүрияте авылларына якын килү, авылларның тормышларын өйрәнү мәсьәләсе тагын да мөһимрәк, тагын да җитдирәк булырга тиеш иде.

Комиссия үзенең эшенә Татарстан Җөмһүриятенең көньяк тарафына урнашкан Спас һәм Буа кантоннарыннан башлап, 15 көн эчендә 9 авылны, 4 волость советын, 1 хөкем бүлемтеген, 4 ячейканы, 2 волость кооперативын һәм 1 кантон башкармасындагы татарча эшләр бүлеген карап чыга алды. Эш планына җөмһүриятнең икенче тарафындагы бер кантонны тикшерү куелган булса да, бәгъзе бер сәбәпләр нигезендә анда барырга туры килмәде.

АВЫЛ ҖАНЛАНА

1921-1922 нче ачлык елларда хәят әсәре бетеп, тыныч бер каберстанга әверелгән авыл хәзерге көндә беркадәр терелә башлаган күренә. Гәрчә авыл башындагы басу капкасыннан алып урамның ике ягы белән бик күп тәрәзә капкачлары ябылган, абзарлар-куралары караучысыз калып череп ава, җимерелә башлаганнар, еллар буе кеше басма-

* Рәүф Сабиров (Рәүф Әхмәт улы Сабиров) – дәүләт эшлеклесе, 1921-1924 елларда Татарстан Үзәк башкарма комитеты президиумы рәисе. Республикабыз үсешендә саллы эз калдырган бу шәхеснең фаҗигале язмышы турында төбәкне өйрәнүче Гөләндәм Давыдованың «Халыкка кайтарылган исем» мәкаләсеннән (http://beznenmiras.ru) укып белергә мөмкин.

Безнең мирас №10 октябрь 2018

ган ишегаллары – әрем, кычыткан белән капланган булса да, авылның эчке тирәсенә киткән саен, хәят якынлаша, тереклек исе борынга бәрелә башлый.

Табигый, әле элекке гөрләп тора торган авыл юк. Урамны гөр китереп торган мал-туар хәзер чиктән тыш аз калган. Каз, үрдәк кеби йорт кошлары бөтенләй күренми. Чит халыкларны нәфрәт белән каршылаучы эт көтүләре дә күренми. Тормыш өчен кирәк булган тавыкларны да хуҗалык башына берәр данә генә санап чыгарырга туры килә. Ләкин башынан күп гыйбрәтләр кичергән, сугыш һәм ачлык фронтларында, революциянең кайнар ялкыннарында чыккан нинди генә авырлыклар алдында тормасын, һәммәсен үтәргә хәзер торган, чыныккан авыл бар. Авыл яшәргә сүз биргән һәм яшәячәк.

КРӘСТИӘННӘР БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

Без тикшергән беренче авыл Янбакты авылы иде. Көннәр яңгырлы булу сәбәпле, халык кырга чыга алмаган, ләкин авылда эш кайный. Лапасы төзегрәк хуҗалыклар, яңгырдан качып өлгергән көлтәсен сугып, чәчүлек хәзерлиләр. Кайберәүләр, җилкәсенә капчык асып, тегермәнгә баралар.

Көн ачылу белән сукага бару өчен сабан-тырмалар төзәтәләр. Безнең килеп төшү авыл чыбыксыз телеграфы буенча бик тиз халык арасына таралып җитте. Рәсми рәвештә дисәтник әйтүне дә көтми, халык җыела башлады, ярты сәгатьтән инде түп-түгәрәк җыелыш төзелеп җитте.

Комиссиянең беренче башлангыч вазыйфасы халыкка үзенең вазыйфаларын нык төшендереп, гадәттә авылга килеп китүче иптәшләр белән авыл халкы арасында була торган коры рәсмиятләрдән ерак булырга тырышу иде. Авылда, элекке гадәт буенча, авыл агалары һаман да сайлана икән. Янбактыда биш дисәтинәлек бар. Безгә бигрәк тә халыкның, үзен мәркәздән килгән кешеләр белән катнашлы рәсми бер мәҗлестә хис итмичә, үзара ясалган бер җыелышта итеп тота алуы кирәк иде.

Шуның өчен сүзне Англиянең безгә тоткан сәясәтеннән башламыйча, үзара хәл-әхвәл сорашудан башладык. Помгол дигән оешманы алар бик яхшы беләләр. Гомер буенча аны онытмабыз, диләр. Авыл чиктән тыш ачыгып, 5-6шар үлекне бер кабергә күмә башлаган вакытта аларга Помголдан һәм АРАдан ярдәм килеп җиткән. 130 баланы ике столовый туйдыра башлаган. Авыллар өчен паек чыккан. Җирләрне чәчәргә орлык килеп җиткән. Әгәр дә шул ярдәмнәр булмаса иде, менә бу халыкның уннан берсе калмый үлеп бетәр иде. Җирләр дә, бар да кысыр калачак иде, әле дә ярый вакытында ярдәм булды, диләр. Авыл картларына бу оешмаларда аңлашмаган урыннар күп тоелганга, без бераз иркенрәк тукталдык. Ачлыкның бер волостьта гына булмыйча, гаять киң үлчәүдә, эченә әллә ничә меңнәр кешене алган төбәкне чолгап алуын, шул кырые-чиге күренмәгән киң


ПРОВЕРЕНО 2006 г.

رەئوف سابيرف.

ئاچلقدان ,سوڭ
تاتارستان ئاوللارئ.

57880

تاتسيك قارشنداعى «تاتارستان ئاوللارن تيكشرو كاميسيەسى» نڭ
ماتيريياللارندان ئالب يازلدى.

تاتارستان مەعاريف كاميسارييانئنڭ سەياسى ئاڭ - بلم تاراتو
باش ئيدارەسى نەشرى.
قازان، 1923 يل.

Сабиров Р. Ачлыктан соң Татарстан авыллары: ТатЦИК каршындагы «Татарстан авылларын тикшерү комиссиясе»нең материалларыннан алып язылды. – Казан: Татарстан Мәгариф комиссариатының сәяси аң-белем тарату баш идарәсе нәшере, 1923

басуларны тутырып чәчәргә күпме азык орлык кирәк булганын, миллионнарча ач халыкны, йөз меңнәр үксез ятимнәрне туйдырырга, хисапсыз күп качакларны ашатып-эчертеп, урнаштырырга никадәр күп миллионнар, триллионнар акча кирәк булганын, озак сугышлардан әлсерәгән, әлҗегән хөкүмәткә шулкадәр күп икмәк, орлык һәм үләннәрне табу никадәр авыр булганын тәфсилле сөйләп үтелде. Бу вакытта халык тынып зур бер ихлас белән тыңлап торды. Тик ара-тирә генә кайбер иптәшләр аерым сөальләр биреп, ныграк ишетергә, яхшырак аңларга тырышалар иде.

– АРА һәрвакыт булып торачакмы?

– АРА кайсы патшалыктан ул?

– АРА – Америка халкының ярдәменнән төзелгән бер җәмгыять, дибез. Аны китереп, бөтен расходларын күтәрә вә аның игеннәрен ташу, кешеләренә йортлар, әсбаплар бирү – һәммәсен совет хөкүмәте оештырды.

Әйе, алар аңлыйлар. Һәммәсен дә, һәммәсен дә бик нык төшенәләр. Әле аларга килеп тәфсилле аңлатучылар сирәк була булуын. Ләкин алар үзләренең гади эшче башлары белән, укып яктыра алмый калган тупас зиһеннәре белән дә һәммәсен әйләндереп тикшерә алалар.

Гаиләне туйдырыр өчен генә дә билләрне бөкрәйтергә, җилкәләрне чыгарырга кирәк була бит. Меңнәр, миллионнарча җаннар уенчык түгел бит ул.

– Рәхмәт инде, эш башындагы җегетләргә!

Мондый бик гади тел белән чынлап йөрәктән чыккан самими сүзләрне сез авылда башыннан ачлык үткәргән, әле ачлык әсәре төсеннән чыгып бетмәгән һәрбер игенчедән, эшчедән ишетерсез.

Без, акрынлап, хәзерге әхвәлгә күчтек. Янбакты авылында ике кырда тутырылып чәчелгән, тишелеп чыккан игеннәрнең күренеше бик яхшы булса да, вакытында яңгырлар булмавы арыш ашлыгына бик зарар китергән.

– Саламга бераз гына күренсә дә, башы буш башак кына, иптәшләр, сез үзегез карап кисегез, сезнең күз алдында сугып күрсәтергә була, – диләр агайлар.

Без аларга комиссия һәммәсен бик ныклап тикшерәчәк, әле без сезнең авылда берике көн торып, һәммә эшләрегезне карап китәрбез, дидек. Спасның бу төбәкләрен чикерткә (саранча. – *Ред.*) баскан. Агайлар бу турыда да хөкүмәт тарафыннан күрсәтелгән ярдәмне онытмаячаклар.

Баштарак чикерткә белән көрәш эшенә алар ышанмау күзе белән карап килгәннәр. Яз көне килеп сөйләүче кешеләрнең сүзләренә көлеп кенә караганнар.

– Ходай кушса, берни дә булмас әле, дип уйлаган идек, соңыннан, йомыркаларыннан тишелеп чыккан вак кортларны күргәч, ышандык. Агрономнар нәрсә әйтсә, шуның сүзен тыңлап тордык. Һәр көнне 300 кеше эшләде, диләр.

Чыннан да, саранча белән көрәш фронтында бу авыл гадәттән тыш тырышлык күрсәткән. Авылның ике тарафыннан салам белән уҗым араларын такыр бусудагы чикерткә гаскәрләреннән саклау өчен, авылны 6 чакрым озынлыгында канау белән чолгап алганнар. Сугыш фронтларында йөргән кешеләргә бу канаулар чыннан да окопларны искә төшерәләр.

Елганың тирәнлеге ике-өч аршин булып, 4 аршиннан түгәрәк тирән чокырлар эшләнгән. Авылның хатыны, кызына кадәр чыгып, ябырылып килеп ятучы чикерткәләрне шул елга буйлап куып чокырга себереп төшергәннәр дә, өсләренә балчык сибеп, таптап күмгәннәр. Безнең аралашу шундый иптәшләрчә бер төс алганны күргәч, алга бер-бер артлы бик күп мәсьәләләр килеп басты. Җир мәсьәләсе, урман, мәктәп мәсьәләләре, китапханәне рәтләү һәм гражданнарның үз тормышларына, көнкүрешләренә бәйләнгән хосусый мәсьәләләр дә килеп чыктылар. Без бу

Ач Россиягә Америка ярдәме. М.Ф.Ларионов рәсеме

мәсьәләләрнең һәммәсенә дә аерым тукталып, көн караңгыланганчы фикер алыштык. Авылның бик күп серләренә төшенеп, әллә никадәр материал таптык. Икенче көн иртән, хуҗалыкларны аерым карап чыккан вакытта, безгә инде артык озак баш ватарга туры килмәде. Һәрбер йорт хуҗасы безнең нинди ният белән килгәнлекне белгәнлектән, һичнәрсәне яшермичә безгә аңлатып бирде.

Моннан соң без башка авылларда шул ук тәртип буенча эш алып бардык. Башка авыллар белән Янбакты авылы арасында тик бер генә аерма бар иде. Янбактыда безне бик ышаныч белән каршы алсалар, башка авылларда баштарак ышанычсыз күз белән: «Тагы нинди налог салырга йөри икән бу халык?» – дигән төслерәк каршылап, озак сөйләшкәннән соң гына без мөнәсәбәтне төзәтеп җибәрә алдык. Аның сәбәбе исә Янбакты авылы Спас кантоны шефлыгы астында булып, шеф вәкилләренең авылга еш килүләре, читтән килүчеләр арасында авыл белән нык берләшү, чын элемтә урынлашу бар икәне беленде. Башка авылларда исә безнең килү сирәк тәваф итүләрнең берсе иде. Янбактыдан соң без Спас кантонының Гусиха дигән волостлы урыс авылында һәм шул ук волостьтагы урыс, чуаш катнаш Ижбарскин авылында, Буада, Иске Шәйморзада, Чынлы һәм Янтуган авылларында крәстиәннәр белән утырышлар ясадык. Авылларда югарыда күрсәтелгән тәртип белән ясалган гомуми җыелышлардан аерым хуҗалыклар, икътисади җәһәттән төрле баскычта торучы аерым крәстиәннәр белән ясалган озак сөйләшүләр, фикер алмашулардан соң, гомумән шундый тәэсир кала.

Ачлык елга кадәр Татарстан крәстиәннәре белән партия һәм совет хөкүмәте арасында сакланып килгән тирән аңлашылмаулар тәмам бетүгә йөз тоткан. Гәрчә хөкүмәтнең крәстиән тормышында мөһим урын тоткан җир, урман кодекслары, хайван, орлык һәм авыл хуҗалыгы кораллары кертү турындагы карарлары, хөкүмәтнең сугыш сәясәте, бәйнәлмиләл сәясәт вә башка бик күп нәрсәләр әле халыкка төшендерелеп җителмәгән кебек, икътисади җитешсезлек, хосусан, авыл хуҗалыгындагы зур бөлгенлек авыл халкының рухына начар тәэсир иткән. Авыл саен берничә данә очрый торган яңа сәүдәгәрләр, ачлык вакытында күбрәк спекуляция ясап, күбрәк җир чәчеп калган, ике ат, ике сыерлы берничә генә хуҗалыклар (мондый хуҗалыклар алты авылда ун гына табылды), иске заманда тирә-якны тетрәтеп торган авыл байлары, Шәйморзаның Гыймаз хаҗилары, Гусиханың Ушаковлары, алар өстенә поп һәм муллалар – бар да авыл белән хөкүмәт арасындагы мөнәсәбәтнең урнашып бетүенә зарар итәләр. Ләкин шуларның һәммәсенә карамастан, совет хөкүмәтенә һәм партиягә каршы һәр җирдә ях-

шырган, хөкүмәтнең бөтен фәрманнары һичбер мәҗбүри чаралар кулланмыйча җиренә җиткерелеп, төрле-төрле кампанияләр, атналар вакытында бөтен авыл халкының ныклап катнашулары, югарыдан килгән совет партия вәкилләренә камил ышаныч белән карап сөйләнгән бөтен сүзләргә игътибар белән колак салулары – болар һәммәсе дә эшче-крәстиән хакимиятенең авыл каршында ныгуын, урынын күрсәтә.

АВЫЛЛАРНЫҢ ИКЪТИСАДИ ХӘЛЕ

Тәфтиш *(тикшерү)* планында безгә өч авылны алып, шуларның бар күк хуҗалыкларын аерым-аерым карап чыгу куелган иде. Ләкин, эшкә тотынгач, планны беркадәр үзгәртергә туры килде.

Бердән, өч кенә авылны карап чыкканда авылның сәяси, икътисади, мәдәни җәһәтләрен киң рәвештә тикшерү мөмкин булмавы беленде, чөнки бер авылда мәктәп тә, көтебханә дә, ячәйкә дә вә башка шундый оешмалар да булып, икенчесендә берсе дә юк. Өченчесендә исә, берсе булса, берсе юк. Шунлыктан, безгә барлык 7 авылны карап чыгарга туры килде. Инде хуҗалыкларын аерым карауга килсәк, без монда авылның барлык хуҗалыкларын тикшереп, аларны берничә груһка бүлдек. Шул бүлекләрдә 3-4 хуҗалыкны карап чыгу авылдагы башка хуҗалыкларның хәле турысында фикер йөртергә юл бирде. Бу рәвештә эшләү вакытка икътисад ясарга мөмкинлек биреп, авылдагы партия, кооперация, совет эшләре белән ныграк танышырга вакытны күбрәк калдырды.

ЯНБАКТЫ АВЫЛЫ

Ул электән икмәккә бик нык авыл булган. Ачлыкка кадәр 310 хуҗалык булып, шуларда – 550-600 ат, 400 сыер һәм хисапсыз күп вак хайваннары булган. Сугыш һәм ачлыктан соң 103 хуҗалык бөтенләй җимерелеп эштән чыккан. 600дән 104 эшкә яраклы ат, 101 баш сыер, 25 баш сарык, 36 баш кәҗә (бәрәннәре белән) калган. Йорт кошларыннан бөтен авылга 48 баш тавыклары, ике йомырка салмаган кысыр үрдәкләре бар. Каз бөтенләй юк. Иген коралларына бу авыл элек бик бай булган, хәзердә сакланып калганнардан – 120 сабан, 65 тырма һәм 55 сукалары, алты сугу машинасы, биш орлык машинасы калган. Авыл һөнәр ягыннан бик түбән, чиктән тыш артта тора. Бөтен авылда бер тимерче, бер укымаган слесарь, бер җон тетүче бар. Хәтта киемнәрен дә читтән килгән тегүчеләр тегеп китәләр, сигезләп иске җил тегермәннәре, ике яргычлары бар. Кооперативка участный кешеләре дә юк. Бөтен халыклары: уку яшендәгеләре – 225, 17 яшьтәгеләре – 240, эшчеләре – 430, картлары 200 кешедән гыйбарәт. Шулардан укый-яза белүчеләр – 180, шуларның 40сы – хатын-кызлар. Ятимнәр – 104 бала, ярым ятимнәр – 125 бала. Кайткан качаклар – 235 кеше.

Җирләре: 1365 дисәтинә – арыш, шуннан чәчелгәне – 332 дисәтинә, 1575 дисәтинә – сабан. Шуннан чәчелгән – 386, парга калганы – 1155 дисәтинә. Шуннан сукаланган – 517 дисәтинә. Бу авылда игеннәр артык начар. Ашлык басуы кырыйдан бик нык зарарланып, сабан басулары исә чикерткә тарафыннан харап ителгән. Арыш – дисәтинәгә 15тән 20 поткача, сабан – 10нан 18 поткача ашлык бирә.

Икмәк бюджеты.

Арыш басуыннан: 332 дисәтинә 15 поттан барлыгы 4980 пот бирә.

Сабан басуыннан: 386 дисәтинә 13 поттан барлыгы 5018 пот бирә.

Барлыгы ике басудан алына – 9848 пот.

Бу авылның парга калган җире – 1155 дисәтинә. Шуннан сукаланган – 517 дисәтинә. Шуны чәчәр өчен дисәтинәсенә 8 поттан 4136 пот орлык кирәк.

Сабан басуына 500 дисәтинә чәчәргә уйлыйлар. Димәк, 8 поттан 4000 пот орлык

АРА хезмәткәрләре ач балаларны туендыра

кирәк. 925 җаннан гыйбарәт булган халыкка, ел буена туенып чыгу өчен, 1712 пот ашлык кала. Бу хисаплар эченә бәрәңге кермәде. Ләкин бу авыл, башыннан котчыккыч ачлык бәласе үткәреп җибәрсә дә, бәрәңге утыртуның авыл хуҗалыгы өчен никадәр файдалы икәнен төшенеп җитмәгән булырга кирәк. Чөнки басуларында, бер дисәтинә булсын, бәрәңге утыртылмаган. Һәр хуҗалык үзенең йорты тирәсендәге 15-20 квадратный сажин бакчаларына утыртканнар да шуның белән канәгатьләнгәннәр. Авылда, бәрәңгедән башка, кыяр, кәбестә, чөгендер кебек яшелчәләр бер хуҗалыкта да юк.

Менә Янбакты авылының икътисади хәле шуннан гыйбарәт. Күрсәтелгән цифрларга игътибар белән караганда, ачлыктан сакланып калган бу авылда әле хуҗалык эшләре никадәр зәгыйфь рәвештә торганын күрергә мөмкин булачак. Авылның өчтән бере, ягъни 310нан 103е бөтенләй юкка чыккан булуы, 600 аттан бер йөз баш ат калуы, вак хайваннарның тәмам кырылып бетүләре иген басуларының да бушап калуларына, йорт-җирнең җимерелүенә сәбәп булган. Киләчәк ел эчендә, табигый, зур өметләр күздә тотып булмый. Күрсәтелгән икмәк бюджеты җирләрнең бөтенләй чәчелми калуын, яхуд барлык ашлыкны чәчеп, ризыксыз калуның мөмкинлеген күрсәтә. Күп хуҗалыклар кыш өчен төрле суррогат, үләннәр җыярга керешкәннәр. Мәсәлән, бу авылда кәнүн дигән үләнне азыкка файдаланалар. Күп хуҗалыкларда без бу үләннән ясалган он һәм тартырга хәзерләнеп куелган уылган сабакларын таптык.

«Ничек чәчәсез? Ничек кыш чыгарга хәзерләнәсез?» – дигән сөальгә: «Иң алдан барлык көч белән чәчәргә тырышабыз. Кайберәүләребез читкә эшкә китәргә уйлыйбыз», – диләр. Дөрестән үк бу авылда бер без барган көннәрдә генә дә 20 кешегә читкә китәргә паспорт бирелгән һәм өч хуҗалык бөтенләй Себергә күчеп китәргә хәзерләнәләр иде. Бу авылда 21 нче елдан алга киткән бернәсә булса, ул да бер ел эчендә 18 ат, 14 баш сыер һәм берничә баш вак хайван арту булган.

Хайваннар, бигрәк тә атлар хасил итү, йорт-җир, каралты-кураны яхшырту һәрбер авылда бертөрле бара. Шуның өчен бу хакта киләчәктә авыллар хакында язылганда тәфсиллерәк рәвештә тукталырга туры килә.

Дәвамы бар

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** һәм **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

ЭЧКЕН ТАТАРЛАРЫ

Рафаил Исакаев

Нардуган бәйрәме

НАРДУГАН БӘЙРӘМЕ

Менә Нардуган бәйрәме – язгы кояш торгынлыгы көне җитә. Табигать уяна, кояш туры карый башлый. Барлык өчкүллеләр кебек үк, карт бабам гаиләсе дә киләсе кунакларга бәйрәм ризыклары әзерли. Күңеллерәк булсын өчен, буза кайнаталар. Бу ике көндә яшьләр төрле уеннар оештыралар. Өлкәнрәкләр, бәйрәм киемнәрен киеп, кунакка йөрешәләр, бүләкләр өләшәләр, язгы һава торышы һәм алынасы уңыш турында фикер алышалар.

Һәм яңадан көндәлек тормыш дәвам итә, күңелле вакыт килә: терлек-туар артым бирә башлый, шуңа күрә аларны күзәтеп торырга, кирәк вакытта ярдәм күрсәтергә дә туры килә. Карт әби белән киленнәр өчен кызу эш вакыты җитә: тай, бозау һәм бәрәннәрне карарга, ашатырга-эчертергә кирәк. Бу эштә оныклар да ярдәм итә.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

САБАН ТУЕ

Нардуган бәйрәмен үткәреп 5-10 көн узгач, яшьләрнең язгы уеннары һәм язгы чәчү алдыннан төп бәйрәм – Сабан туе була. Кар эреп җир ачыла башлагач ук, урамнарда «Күкәй уены» башлана. Анда балалар һәм яшь ирләр белән хатын-кызлар катнаша. Уенның тәртибе болай: һәркем берничә йомырка алып килә. Йоннан әвәләнгән йомшак тупчык белән чокырчыкка куелган йомырканы бәреп чыгарырга кирәк. Күбрәк йомырканы бәреп чыгарган кеше җиңүче дип таныла. Әлеге уеннар язгы кыр эшләре башланганчы бара. Бу уенны ешрак уйнасаң, «тук ел» булачак дип санала.

Сабан туе чиратлашып килгән берничә өлештән – йолалардан тора һәм иртә яздан чәчү башланганчы үткәрелә. Җитәрлек сандагы атлары булган һәрбер таза тормышлы гаилә, төп чабышларда катнашыр өчен, иң яхшы атын әзерли. Карт бабам улларына яраткан таен чабышка әзерләргә куша.

Чабышкының җайдагы итеп аның 20 яшьлек улы Нигъмәтулла билгеләнә. Ул тайны яхшылап карый, аны атланып йөрергә өйрәтә, әтисе җитәкчелегендә чыдамлылык һәм тизлеккә сынау чабышлары уздыра, өлкәннәрнең төпле киңәшләрен тыңлый. Шулай итеп, ат һәм җайдак бер-берсенә ияләшәләр. Бу бәйрәмгә бөтен авыл әзерләнә, аны түземсезлек белән көтә.

Инде әзерлек йолалары үткәрелгән дә. Аларның беренчесе – «Карга боткасы». Ул кара каргалар килгәч уздырыла. Балалар, һәр йортка кереп, ярма, сөт, май җыеп йөриләр. Аннан пешерелгән «карга боткасы»н бөтенесе җыелышып ашыйлар.

Яшүсмерләр ярышларга әзерләнә: башлангыч чабышлар уздырып, «ат аягын кыздыралар», хуҗалык саен кереп, йомырка җыялар. Сабан туе ярышларында катнашучыларга һәм җиңүчеләргә бирер өчен, һәр гаилә бүләкләр әзерли. Узган Сабан туеннан соң кияүгә чыккан яшь киленнәр бүләк җыючыларга үзләре чиккән башлы сөлгеләр бирәләр. Бизәкнең матурлыгына карап, киленнең осталыгы һәм сәләте турында фикер йөртәләр. Кызлар исә, чиккән кульяулыклары һәм башка кул эшләре әзерлиләр. Хәтта әбиләр дә сандыктан нинди дә булса бүләк табып алып бирә. Бүләк җыючылар итеп мөхтәрәм аксакаллар һәм яшүсмерләр билгеләнә.

Көянтә-чиләк белән узышу

Балалар Сабан туе бәйрәмендә

Икенче көнне халык Сабан туе мәйданына җыела. Бу – төрле көч сынашу, җитезлек, кыюлык ярышлары, ат чабышы, көрәш, йөгерү һ.б. Ат чабышлары әйләнәсе 4 чакрымга якын булган тозлы сулы Сәләкле күле тирәли үткәрелә. Юлны алдан ук әзерләп, чабышта катнашмаган атлардан таптатып куялар.

Һәм менә ат чабышы көне җитә. Өчкүлнең бөтен халкы – яше-карты, бәйрәм киемнәреннән, чабыш үткәреләсе урынга юнәлә. Атлар да бәйрәмчә бизәлгән. Бөтенесе дә матур һәм күңелле. Мөхтәрәм аксакаллар – хөкемдарлар чабышта катнашучыларга ярышның кагыйдәләрен һәм шартларын аңлаталар. Бабайлар һәм этиләр дулкынланалар, җайдакларга – оныклары һәм балаларына соңгы киңәшләрен бирәләр.

Чабышта ким дигәндә 30 ат катнаша. Менә җайдаклар, баш хөкемдарның кушуы буенча, тигез рәт булып тезеләләр. Чабышкылар, тояклары белән җиргә бәреп, түземсезләнеп пошкырыналар. Ул арада баш хөкемдар кулын өскә күтәрә – игътибар, – кул аска төшә һәм атлар, тузан күтәреп, кискен рәвештә алга ыргыла. Тамашачылар, үзләренекеләрне дәртләндереп, аларга көч биреп торалар: «Уздырма!», «Алга!», «Артка калма!», «Узып кит!» Менә елдамрак чабышкылар, гомуми төркемнән аерылып, алгарак ыргыла. Әмма алар арасында да күпмедер аралык барлыкка килә. Өч җайдак инде күлнең каршы як ярында. Алар арасында карт бабамның улы Нигъмәтулла да бар. Карт бабам, сөенеп, аңа көч биреп тора: «Әйдә, әйдә!» Тамашачылар дулкынлана, һәркем үз җайдагын күзли, чабышкылар әле алардан ерак булып, тавышларын ишетмәсәләр дә, кычкырып, үз җайдагын дәртләндерәсе килә.

Менә финишка якын текә борылышка җитәрәк бертигез диярлек 5 җайдак оча. Тик шулчак халыкны җәлләп ыңгырашырга мәҗбүр иткән хәл килеп чыга: борылышта бер җайдак, иярендә утырып кала алмыйча, җиргә барып төшә.

Берничә ир аңа ярдәмгә йөгереп килә, ә җиңүгә омтылып кызган аты узышны дәвам итә һәм финиш сызыгын беренче булып уза. Тамашачылар таң кала. Бу старшинаның бөтен тирә-юньгә танылган аргамагы була. Икенче булып финишка безнең Нигъмәтулла белән Иминкүл җайдагы килә. Күпмедер вакыттан соң башка чабышкылар да финиш

сызыгын уза. Ул арада иярдән төшеп калган җайдакны – старостаның бите сыдырылган, күзләре мөлдерәмә яшь тулы оныгын китерәләр. Хөкемдарлар аптырашта: һич күрелмәгән хәл – старшинаның аты беренче килгән, ә җайдак...соңгы булып. Беренче урынны кемгә бирергә?

Алар, тамашачылардан читкәрәк китеп, озак бәхәсләшәләр һәм киңәшәләр. Аннары тамашачылар янына килеп, старшинаның атын җиңүче дип игълан итәләр: сәбәбе – чабышның төп катнашучысы җайдак түгел, ә чабышкы. Моның белән барысы да килешә. Атны төп бүләк – сарык белән бүләклиләр, ә мескен җайдакка иң яхшы башлы сөлге һәм чиккән кульъяулыгы бирелә. Безнең Нигъмәтулла белән Иминкүл җайдагына бик матур чапан (кафтан) эләгә. Катнашучылардан берәү дә бүләксез калмый, бөтенесе – катнашучылар да, тамашачылар да канәгать була. Халык акрын гына өйләренә тарала. Анда аларны бәйрәм сые көтә. Табынга якын туганнарны чакыралар. Карт бабам, бик канәгать рәвештә, яраткан таен йөгәненнән тотып алып кайта, яныннан улы атлый. Туганнары һәм якыннары аларны ягымлы сәламли.

Сабан туе башка әчкен авылларында да шулай узган. Яшьләр кичке уеннарга җыелган, анда алар җырлаганнар, биегәннәр, төрле уеннар уйнаганнар. Бу берничә көнгә сузылган.

ЯҢА УҢЫШКА СЫНАМЫШЛАР

Бәйрәм – бәйрәм белән, ә өлкәннәрнең башыннан киләсе чәчү турындагы уйлар китмәгән. Картлар буыннан-буынга тапшырылып килгән төрле сынамышлар турында фикер алышалар. Алар менә нинди сынамышларга ышанганнар (сынамышлар Р.Таипов язмаларыннан алынды): әгәр март башында буран булса, терлекләргә авыр, күп азык кирәк булачак. Март башында җилсез торса, көннәр кояшлы торачак, җиләкнең күп булуы көтелә. Карт бабам 25 мартта сулы стаканны ике катлы тәрәзә рамнары арасына куйган. Әгәр төнлә су катмаса, көннәр җылы торачак; катса, җир әле 40 көн буе салкын булачак. Иртәнгә карт бабам куйган су катмаган, моңа бөтен гаилә сөенгән.

Йомырка сала торган оядан өч көн рәттән берәр йомырка алып, һәрберсенә билге салып, аерым-аерым үлчәгән очракта сынамышны юрау тәртибе болай:

– әгәр беренче йомырка авыррак тартса, чәчү иртәрәк, уңыш яхшы булачак;
– икенчесе икән – чәчү һәм уңыш уртача;
– өченчесе авыррак булса, бәла: чәчү – соң, уңыш – начар.

Карт бабамның бөтенесе дә яхшы килеп чыккан: беренче йомырка авыррак булган, димәк, 1869 елда мул уңыш көтелә. Дөрес, юраудан тыш, моның өчен күп тир түгәргә туры киләчәк.

Менә басудан кар китеп, җир кибә башлый. Инде, кыр эшләрен башкарыр өчен, җәйләүгә чыгарга вакыт. Карт бабамның (соңрак, ир туганнары белән этиемнеке дә) басулары Өчкүлдән 15 чакрым читтәрәк – «Малыш» (бу атама «мал эше» дигән сүзтезмәдән килеп чыккан булса кирәк) дигән урында урнашкан.

Р.Таипов билгеләп үткәнчә, әчкеннәр, күчеп килгән урыслар алмасын өчен, кырларны үз биләмәләренең «чик буенда» калдырганнар, ә авыл тирәли, көтү йөртү өчен, зур участокларны киртә белән әйләндереп алганнар.

Апрельнең икенче яртысында, җомга көнне бөтен гаилә мәчеткә китә. Җомга намазын үтәп, Аллаһтан мул уңыш сорап, дога кылалар. Хатын-кызлар өйдә бәйрәм ризыклары әзерләп, якын туганнарны ашка дәшәләр.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

ӘХМӘТ БАЙ
(1837-1906)

Ризаэддин бине Фәхреддин

ӨМИД ВӘ ФИКЕРЛӘРЕ

Инсан өчен иң ләззәтле тәгам *(ашамлык, ризык)* – үзенең маңгай тире илә тапмыш улганыдыр. Һөнәр вә сәнәгать һәрбер сәгадәтнең башы улып, буңа тәмәссек итмеш *(тотынган)* милләттләр нә йирдә улсалар да улсыннар, үзләренең каумиятьләрене *(нәселләрен)* вә миллиятьләрене сакларлар, дин вә диянәтләреннән аерылмазлар. Бу исә, мәгълүм бер мәсьәләдер. Иштә Әхмәт бай, ошбу мөкаддәмәләрне гүзәл аңладыгыннан, Русия исламнарының бармак саннарыннан күп дәгел микъдарында гына байлары улып та, калганнарының бөтен-бөтене һөнәрсез, эшсез, тамгы *(һаман кешедән өмет итү)* вә сәдака, хәер вә иганәт илә генә яшәмәкләренә риза улмаз, бәлки буны милләт инкыйразына көчле бер сәбәп игътикад идәр иде. Ошбуның өчен Русия исламнарының һөнәрле улмакларыны вә хәяте иҗтимагыяның дәвамына, бәни бәшәрнең бәкасына *(мәңгелегенә)* сәбәп улачак сәнәгатьләрене үз кулларына алмакларыны арзу кылыр *(теләр)* вә һәр йирдә ошбуны сөйләр вә ошбуннан бәхәс кылыр иде.

Әхмәт бай: «Рус авылларында һәр йортның үзенә махсус бакчалары вар. Хатыннарының иҗтиһадлары сәбәбеннән, шул бакчаларда кишер вә кыяр, чөгендер вә шалкан, бәрәңге вә кәбестә кеби шәйләр йитешер вә бунлар сәбәбеннән ризыклары мул вә бәрәкәтле улыр, шунлардан гыйбрәт алып, Каргалы халкы да шөйлә мәгыйшәт юлларына керсәләр, иркен мәгыйшәт кылуларына сәбәп улыр иде. Безнең мөселман халкы ни өчен шул рәвештә иҗтиһад күстәрмиләр вә ни өчен башкаларга күрә зәбун *(хурлыклы, начар)* сурәттә көн кичерәләр?» – дия әсәрле сурәттә сөйләр, ялкаулыктан зарланыр, халыкларны үз кул көчләренә таянырга өндәр иде. Ушандак Русия мөселманнары өчен иң файдалы кәсепләр – сәнәгать илә, замана низамына күрә тиҗарәт итмәк идеген, иске вакытларда улан сәүдә ысуллары ярамадыгыннан, анларны ташлап, башкалар кабиленнән байлыкны бер йиргә җыеп вә зур ширкәтләр тәэсис кылып *(төзеп)*, олуг эшләргә керешергә лазем улдыгыны, аз файда алмак ысулы илә күп рибех *(табыш)* китермәк тиешлелеген игътикад кылыр *(чын күңелдән ышаныр)* иде. Мөселманнарның ошбу эшләргә рәгъбәт итмәй *(омтылмый, кызыксынмый)*, берән-сәрән йөрмәкләренә

Әхмәт бай: «Ислам милләте мотлакан укырга вә язарга белсен, төркичә вә русча үгрәнсен. Дин танымаган мөселман баласы калмасын, һөнәрсез вә ялкау мөселман азайсын, милләт эчендә дөрест белүче вә гакыллы дин галимнәре вә гүзәл холыклы зыялылар хаҗәт микъдарында улып торсын!» – фикерендә иде.

Ахыры. Башы журналның 2018 елгы 9 нчы санында.

«Хөсәения» мәдрәсәсе

вә вак эшләр, бәрәкәтсез сәүдәләр илә вакыт тәләф итмәкләренә хакыйкать хәлдә тәәссеф әйләр *(кайгырыр, ачыныр)* иде.

Ширкәтләр илә эш күрмәк өчен замана әхвәленнән хәбәрдар улмак, башка кавемнар белгән шәйләрне белмәк лазем улдыгыннан, халкымызның мотлакан *(ничек булса да)* уку юлына кермәкләрене өмид кылыр иде.

Әхмәт бай: «Ислам милләте мотлакан укырга вә язарга белсен, төркичә вә русча үгрәнсен. Дин танымаган мөселман баласы калмасын, һөнәрсез вә ялкау мөселман азайсын, милләт эчендә дөрест белүче вә гакыллы дин галимнәре вә гүзәл холыклы зыялылар хаҗәт микъдарында улып торсын!» – фикерендә иде. Ушандак шәкертләр хакында да: «Ислам шәкертләре, дин гыйлемнәре белдекләре өстенә, беркадәр дөньяви гыйлемнәр илә дә ашна улсыннар. Бөйлә шәкертләр, әгәр дә имам вә мөдәррис улсалар, дин вә дөнья әмерләрендә халыкларны җитәкләп варырлар. Ля әкалле *(иң кимендә)* кире яктан тартып тормак вә артка өстерәмәк кеби фәлякәт *(бәхетсезлек)* юллары хәзерләмәзләр. Табигать иҗбар *(мәҗбүр)* итмеш эшләрнең хилафына хәрәкәт итмәзләр. Нагяһ *(көтелмәгәндә)* имам яки мөдәррис улмасалар, абруйлык вә тугрылык илә хезмәт кылып, башкаларга күчергеч улырлар. Һәрхәлдә, милләт бунлардан мөстәфид улыр *(файдаланыр)*», – дияр иде. Вә кәнденең мәдрәсәсене дә ошбу мәтлаб *(максат)* илә тәэсис итте. Дәрес программаларыны да ошбу мәсләгенә муафыйк сурәттә тәртип иттерде.

Әхмәт бай, мәдрәсә вә мәктәпләрнең биналары вә дәрес ысуллары мәрсия укы-

Дөньяда улан бик күп фазыйләт (яхшы эш) вә бик күп рәзаләтнең (яманлык) сәбәбе мал вә байлык идеге мәгълүмдер. Малны тапмак бөек иҗтиһадларга муафыйк исә, аны тота белмәк вә урыныны белеп сарыф итмәк дәхи зиядә гайрәт вә гакылларга мәүкуф (бәйләнгән) идегендә шөбһә юк.

лыргга лаек бер сурәттә идегене яхшы белдеге өчен, бунларның төзәлмәкләрене эстәр *(теләр)*, бинаалары хифзыссыйхәт *(сәламәтлекне саклау)* кагыйдәләренә муафыйк улмаклары тугрысында иҗтиһад әйләр, үзе аңладыгы кадәр ошбу хакта сөйләр вә байлыгы илә ярдәм вирер, тиешле урыннарда бәхәс кылышмактан кире тормаз иде.

Кангый тарихтадыр, Каргалы шәһәренә зур бер мәдрәсә тәэсис итеп, гүзәл сурәттә голүме гарәбия вә диния укыттырмак һәм дә һәрбер мәхәлләнең мәдрәсәләренә дәресләрне тәүзигъ итеп *(таратып, өләшеп)* вирмәк фикеренә керде вә чараларыны күрергә башлады. Фәкать буның морадыны *(теләгән)* белдекләре илә бәгъзе адәмнәр, халыкның агырган йирләренә сугып: «Әхмәт бай андый мәдрәсәне миссионерлардан акча алып сала булыр. Соңыннан учительләр китереп русча да укытырга керешер», – кеби һәртөрле һәзьяннар *(мәгънәсез сүзләр)* сөйләп, халыкны игъва иттеләр *(начарлыкка котырттылар)* вә шәһәрнең мөнасиб *(яраклы)* йиреннән мәдрәсә бинасы өчен урын вирдермәделәр. Ахырында Әхмәт бай шул вакытларда Каргалының иң начар вә иң фәкыйрь урыннарыннан саналмыш Дунай мәхәлләсеннән бер урын хәзерләп, мәдрәсәне шунда бина итмәк фикеренә төште. Лазем улан ком вә агач, таш кеби әсбабны хәзерләргә кереште. Бу дәфгасендә *(мәртәбә)* бәгъзе Каргалы муллаларының дәхи зиядә гайрәт сарыф итеп, гавамны аякландыра башладыкларыны күрдеге илә, хөкүмәт нәзарында фетнә кузгатучы җөмләсеннән хисап ителмәктән сакланмак өчен, ошбу касдыннан ваз кичте. Китертмеш әсбабыны сатты вә башка йирләргә күчертте.

Әхмәт бай соң гомеренең егерме еллар кадәр бер мөддәтендә бөтен-бөтене мөселман балаларыны укытмак эшенә вирелеп, бөтен мәҗлесне ошбу мәсьәлә илә кичерер иде. Шөйлә ки, акча вә байлыгы илә улан ярдәмнәре һичбер игътибарга алынмадыгы тәкъдирдә дә, ялгыз тел илә улан бу хезмәте микъдарында бер хезмәтне бу көнгә кадәр Русия мөселманнары арасында нә бер ахунд вә казый, вә нә бер мөдәррис, вә мөфти кыла алмамыштыр.

Кирәк улган мәхәлләләргә мулла сайламак тугрысында Әхмәт бай: «Мулла вә мөдәррис улырлык шәкертләрне җыеп, инабәтле *(ышанычлы)* галимнәр хозурында имтихан кылдырып карарга кирәк. Гыйльме илә холкы яхшы идеге мәгълүм улган шәкертләрне, мәхәлләгә бөтенләй ят кеше вә нә йирдә тәхсил иткән *(гыйлем алган)* улса да, карт хәзрәтнең фатихасыннан вә карт абыстайның каргавыннан курыкмай, шуны сайларга тиешле», – дия күп вакытлар сөйләп йөрде вә кәндесе буны тәҗрибә итеп күрде вә Оренбург шәһәрендә алтынчы мәсҗет хозурында *(карамагында)* улан вәкыф йортының вәкыфнамәсене дә ошбу гакыйдәсенә бина кылып яздырды. Фәкать башка күп мәнфәгатьле фикерләре кабиленнән, бу фикере дә рәваҗ тапмады *(таралмады)*, халыклар буңа риза улмадылар. Тугрысы, буның файдалы бер эш идегене аңламадылар, шул сәбәпле бу юлда улан иҗтиһады сәмәрәсез *(нәтиҗәсез)* калды.

ХӘЙРАТЫ (ИЗГЕ ЭШЛӘРЕ)

Дөньяда улан бик күп фазыйләт *(яхшы эш)* вә бик күп рәзаләтнең *(яманлык)* сәбәбе мал вә байлык идеге мәгълүмдер. Малны тапмак бөек иҗтиһадларга муафыйк исә, аны тота белмәк вә урыныны белеп сарыф итмәк дәхи зиядә гайрәт вә гакылларга мәүкуф *(бәйләнгән)* идегендә шөбһә юк. Дөньяда тордыклары мөддәттә инсаннар үзләренең

мәгыйшәтләре өчен буңа мохтаҗ улырлар. Икътисад кагыйдәләренә ригаять илә истифадә итеп *(файдаланып)* торсалар, җисемнәрене, рухларыны рәхәт яшәтерләр. Сәфахәт *(ахмаклык)* юлына сарыф ителенәчәк маллар тугрысы зәһәр вә бәла хөкемендә улып, буннан хәсарәт *(зыян)* вә нәдамәттән *(үкенеч)* башка нәтиҗә хасил улмаз.

Мәдәниятле кавемнәрнең мөхтәлиф *(төрле-төрле)* табәкалары *(катлаулары)* үзләренең тугмалары улан фәкыйрьләрнең хәлләрене ислах итмәк тугрысында күп бәхәсләр иттеләр вә күп чараларга тотынып карадылар. Әлеге мәсьәлә ошбу көндә дә гыйлем вә хәмиять әһелләрене иң күп шөгыльләндермәктә улан бәхәсләрдәндер. Бу тугрыда иттифакъ вакыйгъ улан бер нәтиҗә вар исә, ул да фәкыйрьләрнең балаларыны укытмак фикередер. Фәкыйрьләр хәлене ислах итәргә тырышучыларның һәрбере буңа мөслим улыр, инсаният әсәре улмак үзрә иң элек ошбу маддә кабул ителенер. Безем Әхмәт байның бөтен мәсләге вә максаты да ислам фәкыйрьләренең балаларыны укытмак вә мәсалих мөштәрәкәләр *(уртак файдалар)* тугрысында иганәт итмәктән гыйбарәт иде.

Әхмәт бай мал кадере белдеге вә бер тиенне буш йиргә сарыф итмәктән сакландыгы нисбәтендә Хак Сөбханә вә Тәгалә ризалыгы өмид ителмеш урыннарга вә мәсалих миллиягә сарыф итәр өчен рәгъбәт кылыр, бу кеби эшләр өчен кесәсе ачык вә кулы да югары торыр иде.

Әхмәт бай башкаларга күрә бакый вә гомерле, файдасы да дәвамлы улан хәйрат үзәренә мәхәббәт кылыр, мәсҗет вә мәдрәсә биналарыны да ошбу рәвештә кылыр, биналарның күркәм улмакыннан зиядә чыдамлы улмагына игътибар әйләр иде. Ошбу сәбәптән карья халыклары өчен мәйданга чыгаруы йиңел вә мәсарифы *(чыгымнары)* да аз вә дәвамлы улан гадәти таштан мәсҗет вә мәдрәсә биналары торгызмак юлыны халыкларга күстәрде вә буның файдалы идеге хакында халыкны димләде. Кәндесе тарафыннан соң вакытларда бина иттерелмеш мәктәп вә мәдрәсәләрнең һәрбере ошбу рәвештә гадәти ташлардан салынмышлардыр.

Әхмәт бай мәхыз *(фәкать)* күренеш вә шөһрәт өчен мал сарыф итмәк юлында улмадыгыннан, мәсҗет вә мәдрәсә бина итәчәк урыннарын бик тикшерер, мөҗәррәд *(ялгыз)* бер бай вә мулла, яки мулла улачак шәкертләр сүзенә инабәт итеп кенә (ышанып) эш башламаз иде.

Әхмәт бай: «Ничек улса да улсын, мулла илә мәсҗет күбәйтмәк, дин көчәйтмәк уладыр», – дия фикер итмәктә улан надан байлар арасыннан аерылып, югары чыкмыш вә ошбуның өчен дә мөҗәррәд халыкны аерырга вә фөкарә *(фәкыйрьләр)* өстенә йөк агырайтырга сәбәп улачак йирләргә мәсҗет бина итмәз иде.

Борынгы байлар мәсҗет вә мәдрәсәләрне күбрәк вакыт базарлы авыллар вә җәмгыятьләр күп улачак йирләргә торгызып та, шул мәсҗет вә мәдрәсәләрнең ялңыз үз исемнәренә генә мәнсүб *(караган)* улмакларыны арзу кылдыклары *(теләгәннәре)* мәгълүмдер. Әмма Әхмәт бай бунларның хилафына уларак, хәйратыны иң гаҗиз йирләргә һәм дә бергәләшеп итмәк сәдәдендә *(максатында)* улыр иде. Ошбу сәбәптән мәсҗет вә мәктәп бина итүчеләргә ярдәмләшер, үз тарафыннан ителгән гыймарәтләргә *(корылмаларга)* башкаларның ярдәм кылуларыны яратыр вә, гомумән, изгелек эшләрне җәмәгать илә эшләмәкне эстәр иде. Буның өчендер ки, мәсҗет вә мәктәп салыр өчен ярдәм сорап вармыш авыл картларына, һәрбер ихтималятне *(мөмкинлекне)* сорашып бетердегеннән соң, әгәр дә гыймарәтне лазем тапса: «Ярар, бән гыймарәт кылырым, фәкать ком, балчык, агач вә таш кеби әсбабны үзеңез чыгарып ташырсыз», – дияр вә халыкларның көчләре йитәчәк нәрсәләрене үзләреннән иттерер өчен тырышыр иде.

«Бай, һиммәтеңез саясында мәсҗетемез тәмам улды, фәкать намазлыгы юк, бик

килешсез рәвешчә торадыр. Имде мәрхәмәт итеп намазлык та вирәңез, шаять мәхрүм кылмазсыз», – дия намазлык сорамыш бер муллага: «Хәзрәт! Бән бөтен изгелекне үземә генә кочаклап алмак дәрәҗәсендә комсыз адәм дәгел. Мәсҗет тәмам улмыш исә, гүзәл! Имде намазлыкны авылның карчыклары вә хатыннары җыелышып җәйсеннәр. Бу мәсҗеткә анларның да маллары вә кул хезмәтләре катышсын! Намазлык та вирсәм, ихтимал: «Имде, бай, намазымызны да укып вир!» –дия килүеңездән куркам, шуның өчен намазлык вирмим. Ихатасыны үзең тоттыр, фәлән кадәр байлыгың варлыгы бәңа мәгълүм», – диде.

Казан шәһәрендә тордыгы ун ел мөддәтендә һәрберенең мәсърафы *(тотылган акчасы)* өч мең вә аннан артык улмак үзрә егерме гадәд микъдарында мәсҗет вә мәдрәсә бина итте, кырык кадәр мәктәпләрнең мөгаллимнәренә вазыйфәләр *(хезмәт хакы)*, ике йөз кадәр мәктәпләр өчен кирәкле китаплар вирәп торды.

Макариянең имамы торыр вә балалар укыр өчен дия тәэсис ителмеш кырык мең сум кыйммәтендә улан вәкыф йорт Әхмәт бай иҗтиһады илә мәйданга чыкмыш вә буның өчен кәнде малыннан 12 000 сум бирмештер.

Уфа шәһәрендә улан «Госмания» мәдрәсәсенә бер мең сум иганә итмеш вә Казан шәһәрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе файдасы өчен утыз мең сум мәсъраф тотып, Макариядә улан Лапаштин номерларыны вә Оренбург шәһәрендә улан үз мәдрәсәсе Хөсәения өчен, Мәкәрҗәдәге Хөсәеновский подворьесыны[1] вә бунлардан башка, өч йөз егерме мең сум төрле урыннар өчен вәкыф әйләмештер. Ошбу җөмләдән егерме биш мең сумны Хөсәения мәдрәсәсенең хисабына, нәзарәт *(идарә)* итү шарты илә, Оренбург шәһәрендә улан мөселманнарның җәмгыяте хәйрияләренә тәхсыйс итмеш *(билгеләгән)* иде. Җәмгыяте хәйрия исә, ошбу акчаны шарты илә кабул итте вә шуның илә үзенә милек итәрәк «Мәдрәсәи Хөсәения»гә якын урыннан йорт сатып алды.

ХӨСӘЕНИЯ МӘДРӘСӘСЕ

Әхмәт байның олуг хәйратыннан вә мәңгелек улан ядкяреннән Оренбург шәһәрендә улан Хөсәения мәдрәсәсе улса кирәк. Озынлыгы 82 аршынлы вә киңлеге дә 27 аршын, өч катлы, су илә елынмакта улан бу мәдрәсә өчен янында улан бөтен биналары илә[2] бер йөз мең сум микъдарында мәсъраф чыкмыштыр.

Буннан егерме еллар мөкаддәм Сибириянең могтәбәранынннан мәрхүм Нигъмәтулла хаҗи Сайдуков[3], беренче дәфга уларак ысулы җәдидә мәдрәсәсе тәэсис иттегеннән вә күпме-азмы сәмәрәсе күрелдегеннән соң, икенче мәртәбә уларак Әхмәт бай тарафыннан Оренбург шәһәрендә ошбу мәдрәсә ачылды. Шуны ахыр гомеренә кадәр дәвам вә тәрәккый иттереп, соң гомерендә гадәти тау ташыннан ошбу олуг бинаны гыймарәт кылдырды. Мәдрәсәсенең рәсми көшады *(ачылуы)* иҗра ителмәстән вә шәкертләр илә тулы улдыгыны күрмәстән мөкаддәм *(элек)* кәндесе *(ягъни Әхмәт бай)* вафат итте.

Ошбу ысулы җәдидә мәдрәсәсене дәвам иттермәк вә яңа бинаны да гыймарәт әйләмәк хакында вексельләре протест ителмәктән куркып, өч-дүрт бай вә хакыйкатьне яшерергә вөҗданнары манигъ улдыгы сәбәпле, ике-өч мулла, ихтимал ки, тарафдарлык вә хәерхаһлык күрсәтмеш улырлар. Әмма гомумиятьлә халык: «Иске тормышны

[1] Харис әфәнде Фәйзи хәбәренә күрә, ошбу Хөсәиновский подворье 45 мең сумга гына алынмыш исә дә, соңра тәгъмир кылынып, 75 мең сумга төшмеш. Әмма бу көнге кыйммәте йөз мең сумдыр. Соңыннан ишеттегемезгә күрә, ошбу подворье Әхмәт бай, Габделгани хаҗи вә Мәхмүт бай арасында мөштәрәк милек улып, калганнарының ризалыклары илә Әхмәт бай исеменнән вәкыф ителмештер. – *Р.Ф.*
[2] Хәлфә вә хезмәткәрләр өчен ике катлы таш йорт, таштан эшләнгән мәһабәт мәчет, мулла гаиләсенә исәпләнгән зур бүрәнә өй, ат араны, арбалык, утынлык кебек биналар.
[3] Сайдуков Нигъмәтулла (1829-1901) – сәүдәгәр, меценат.

бозмак вә илдә юкны чыгармак уладыр», – дия буның гамәлләреннән риза улмадылар, куллары илә манигъ итәргә кодрәтләреннән килмәгәннәр телләре илә, вә телләре илә манигъ итәргә көчләре йитмәгәннәр күңелләре илә буны инкарь иттеләр. Тәбдигъ *(яңа нәрсә уйлап чыгаручы)* вә тәзълил *(туры юлдан чыгаручы)*, хәтта ки тәфсикъ *(аздыручы)* вә экфар кылдылар. Коръән шәриф вә хәдисләрдә монафыйк вә гасый *(гөнаһлы)* бәндәләр хакында улан аятьләргә буны мисдак кылып *(туры китереп)*, һәрбер хосусый вә гомуми мәҗлесләрдә гайбәтене сөйләделәр. Дин бозучылар вә дингә җинаять итүчеләрнең башлыклары итеп санадылар. Ошбу адәмнәр Әхмәт байның гомере кыска улмак хакында егылып-егылып догалар әйттеләр. Әхмәт бай бер шатлык күрер улса: «Истидраҗ *(кызыгып алдану)*», – дия вә хәсрәт күрер улса: «Бәддога төште», – дия хөкем итәр улдылар. Гавам арасында да: «Әхмәт бай, миссионерлардан акча алып, мөгаллимнәр вә мәктәпләргә таратадыр. Уку бәһанәсе *(сылтавы)* илә мөселманнарны миссионерлар тозагына кертмәк уладыр, шуның өчен бу ысулы җәдидәнең гакыйбәте *(ахыры)* яман улачак», – сүзләре шөһрәт улды. Хәтта ки әтрафтан килүче эшчеләр вә уракчы хатыннарга кадәр ошбу җөмләләрне ерак йирләргә алып кайтып таратыр иделәр. Хәлбуки, гайн *(үзе)* ошбу вакытта ярым рәсми улан «Москва» газетасы аркылы миссионерлар тарафыннан: «Мөселманнарның күзләрене ачалар, хөкүмәт рөхсәтеннән башка мәктәпләрдә укыттыралар», – дия Әхмәт бай кебиләр өстләреннән шикаятьләр язылыныр иде.

Әхмәт бай бунларга да, анларга да илтифат итмәде. Укырга, язарга белмәдеге хәлдә, кәнденең фикереннән аерылмады, сәбат *(ныклык)* вә гайрәтеннән кыл кадәр күчмәде. Мәдрәсәсене дәвам иттердеге өстенә, ошбу тау кадәр улан «Хөсәения» бинасыны гыймарәт иттерде. Икътисади җәһәттән истикъбалене *(киләчәген)* тәэмин итеп, рәсми сурәттә вәкыфлар калдырды. Дин исеменнән вирелмеш вәгазьләр, нәфрәт вә тәүбихларга *(шелтәләүләргә)* каршы ошбу кадәр эш эшләмеш бер өмминең шәҗагать әдәбиясе *(батыр холкы)* нә кадәр улдыгыны һәркем үз гакылы илә белсә кирәк. Бәнем фикеремә күрә, Әхмәт байда улан җәсарәт вә шәҗагате әдәбия Наполеонда улан шәҗагат вә икътидардан бәләнддер *(югарыдыр)*. Гыйлемле вә мәгълүматлы улан күп кемсәләр буннан гыйбрәт алырга мохтаҗлардыр.

Хөсәения мәдрәсәсе ялңыз мәдрәсә генә дәгел, бәлки җәһаләт вә тәгассыб *(фанатизм)* илә мөхарәбә итеп *(сугышып)* тә, шунларга галиб улмакның ядкяре, сәбат вә мәтанәтнең нишанәсе *(куәтлек билгесе)*, һиммәт вә гайрәтнең мөҗәссәм тимсаледер *(гәүдәләндерелгән сурәте)*. Бу мәдрәсәдән бу көнгә кадәр өмид ителдеге дәрәҗәдә файда күрелмәде исә дә, иншалла, киләчәк бер көндә күрелер вә Әхмәт байның максаты йиренә килер. Бәндә өчен дөрест ният илә гүзәл эшнең сәбәбенә керешмәк бурыч улып, билфигыль *(чынлап)* файдасыны күстәрмәк Хак Сөбханә вә Тәгаләнең кәнде вазыйфасыдыр.

Аллаһы Тәгалә хәзрәте гөнаһларыны кичереп, урыныны җәннәттә әйләсен. Мәдрәсәсене дә дөньяның соң көненә кадәр гыйлем әһелләре вә ислам хадимнәре йитешәчәк урын итсен, амин!

Редакциядән: Хөрмәтле укучылар! Ризаэддин Фәхреддин китабының Әхмәд бай Хөсәеновның тормыш юлы һәм аның шәхесе хакындагы өлеше шушы урында тәмам. Мирас малы һәм васыятьләре турындагы кисәген журналыбызның киләсе саныннан укырга мөмкин.

*Текстны басмага **Җәүдәт Миңнуллин** һәм*
***Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Риза казый нәселе

(Ризаэддин Фәхреддиннең кызы Әсма Шәрәф белән аралашу тарихы)

Рәфкать Шаһиев

Әсма һәм Арслан Шәрәфләрнең Кичүчаттан алган тәэсирләрет соңгы сулуларына кадәр җитте. Әтисенең туган авылыннан күчергән энергия, яшәү көче аңа шактый гомер өстәде кебек. Ул авылдан яңа көч, дәрт белән, илһамланып кайтты. Аннан соңгы хатларда бу очрашуны искә алмаган юллар бик сирәк була иде.

Исәнме-саумы, Рәфкать туган!

Күп сәлам соңында иң яхшы теләкләр. Ничек кызык була бит кайчакта. Сиңа хат язам дип әзерләнеп утырганда, синнән хат килеп керде. Рәхмәт сиңа, хатың, хәбәрләрең өчен. Инде үземнең сүз башы: әниең Гайнелгыйлем ханыма, әтиең Шириаздан якташка, туганың Әлфиягә, кунак абыстайларга (исемнәрен белмәдем) бездән күптән-күп сәлам, хәерле теләкләр. Зур рәхмәт. Гаҗәп хәл булды, алай сирәк була: синең әниеңне беренче күргәч тә, будто бы әллә кайчан очрашкан, танышкан, якын белешкән кеше шикелле хис булды. Кайдан-нидән шулай? Вакыт аз булган аркасында озаклап сөйләшеп утырырга да туры килмәде, алдагы аш бүлмәсендә дә утырмадык. Ярый инде, якын дуслар булып калдык. Кичүчатлылардан мине сораучы булса, һәрвакыт бездән сәлам! Уңышлар телибез Кичүчат халкына. Миңа бик якын булдылар. Мине күргән, танышкан кешеләргә сәлам күндерә күр. Кичүчат халкы бик тәртипле, игътибарлы, уңган кешеләр булып хәтердә калды. Әткәйне хөрмәтләп истә тотулары да безгә күңел шатлыгы булды. Сиңа тырышып шул «бикле» мәктәпне ачуың, уку үзәген яңартуың өчен рәхмәт. Эшең бик күп булыр. Әткәй гомере буе ялкауларны, вакытларын әрәм итүчеләрне яратмады. Әгәр кичүчатлыларны күрсә, андый булмаганнары өчен шатланыр иде.

...Без кайткач, килә торган бөтен туган-тумача хәл белергә килделәр. Миңа әйтәләр: «Әсма апа, ну и ну! Син безнең «Герой нашего времени» булдың. Өйдә йөри алмаган кеше, шундый ерак җирдән сәяхәт итеп кайттың», – дип исләре китте. Үзем дә хәйран булам, барырга, күрергә, әткәйнең күп сөйләгән Кичүчатын күрергә шулхәтле теләк зур булган, көч-хәл биргән Ходай. Сез чакырып киткәч, Арслан әйтте: «Әннә, йөри алмыйсың, үзең хәлеңне кара. Бик барасың килсә, мин һәрвакыттагы шикелле ярдәм итәрмен. Үзең хәл кылырсың», – диде. Билгеле, әгәр Арслан шундый ярдәмчел булмаса, бара да алмас идем. Кызганыч, Риза Ишморат бара алмады. Ул бит хәзерге көндә әткәйнең үзен исән чакта күргән бердәнбер кеше. Сиңа аның газетада бу арада чыккан мәкаләсен җибәрәм. Аны күбрәк кеше укыса яхшы булыр иде. Кисеп салырга туры килә, конвертка сыймый. Үзебезне телевизордан күрмәдек әле. Менә мин сиңа йомышлар язам, шуларга җавап язарсың. Әле ярый китәр көнне өйгә Самдун абзаң килеп

Сулдан:
Р.Фәхреддин,
И.Терегулов,
Г.Әхмәров.
Уфа

сөйләшеп, танышып утырды, юкса мин бик борчылып (илтифат итмәде дип) китә идем. Син җибәргән газетада Кичүчат, «Елховнефть» турында гына. Тантана турында юк.

1) Таһир Габдрафиковка күп сәлам, зур рәхмәт. Илтифаты өчен, ихтирамы өчен, чакырганы өчен.

2) Әнвәр Шакирҗановка, апасы Нурсинә апага бездән сәлам, күчтәнәчләре тәмле. Зур рәхмәт!

3) Самдун абыеңа күп сәлам, зур рәхмәт матур фотолары өчен. Аңар хат кисәге язам, биреп, җавап сорарсың. Сорау: монда бер тарихчы (татар) русча «Татарстан» журналында әткәй турында мәкалә яза, шунда актыкта: «әле менә аның туган авылы Кичүчатта шундый ихтирам белән тантана үткәрелде, мемориаль такта [куелды], яңа мәчет [ачылды] (фото Самдунныкы)», дип язсам, ди, «мәчет Ф.Самдун проекты буенча», дип күрсәтсәм, ди, автор рөхсәт итәрме?

4) Инде: Гөлнәзирә ханыма күп сәлам, күчтәнәчләренә зур рәхмәт. Танышканга күңелем булды. <...>

Гөлнәзирә ханым ничек белә чибәр абыстайларны? Кемнәрне белгән, кемнәр кайда булган? Шуларны сорарсың, язарсың.

5) Тәзкирә ханыма күп сәлам. Безнең шәҗәрәнең бик ерак кына бер тармагында бер генә «Уразай» бар. Син аңарга әйтерсең, Уразайның өске якка ата, баба, баба-бабалары; шулай ук аскы якка балаларның балалары – менә кемнәр билгеле; исемнәрен язып җибәрерсең. Ул үзе Уразайлар белән бик кызыксынган иде. Тикшереп карасын.

Менә бер гаҗәп, кем булмасын, Кичүчат кешесе күптән таныш, үз кеше шикелле

булды. Мин анда тумаган, авылда тормаган, гореф-гадәтләрен дә белми идем. Ә нишләп кичүчатлылар үз кеше булып күренәләр икән? Бәлки, син әйтерсең? Алардан әллә нинди кешелеклелек, йомшаклык тоела шикелле.

Рәфкать! Минем записканы Самдун әфәндегә бир дә, җавапны миңа язарсың. Ярый, хатым бигрәк зур булды. Әле Кичүчат якташларга да хат язасым бар. Исәнлек, эшләреңдә уңышлар теләп калам.

Әсма апа. 30/X – 1992

Исәнме-саумы, Рәфкать туган!

Бик күп сәлам сиңа, әниеңә, әтиеңә, Әлфиягә, кунак абыстайларга! Мин аларның һәркайсын гел исемдә тотам, ничек сездә кунак булганнарым да күңелемдә. Бу арада сиңа озын хат язып газетадагы Риза Ишморатның мәкаләсен салган идем. Сиңа төрле сораулар да бар иде. Вакытың бик тар булса да, җавап язганыңны көтеп утырам. Өйгә кайтканнан бирле исем китә: Кичүчат та, андагы кешеләр дә беренче күргән шикелле түгел, әллә кайчан күргән, танышкан шикелле якын кешеләр булып тора. Үзем дә гаҗәпләнәм. Әткәйнең үткән гомерен күңелем белән якын иткәнгә, аның туган җирендәге яңа буын да шулай якын була икән. Аның яшьтәшләре әллә кайчан үлеп беткәннәр, әткәйгә дә бит 133 яшь. Күрәсең, аның заманындагы халыкның тәрбияле, тәүфыйклы, кешелекле гадәтләре, күчә-күчә, яңа буынга да йогынты ясагандыр. Инде сиңа Марсель Әхмәтҗановның мәкаләсен җибәрәм. Бәлки, үзе дә салгандыр.

Миннән Әнвәр әфәнде (чыбык очы) белән апасы Нурсинә ханымга сәлам. Инде син аңардан сора, Әсма апа үзләренең нәсел-нәсәпләре белән бик кызыксына. Аңарда (Әнвәрдә) үзенең ата-бабалары – ерак бабалары турында берәр язмалары бар микән? Булса син күчермәләрен җибәр. Мин дә эзләп карармын. Тирәннән тикшергән, кызыксынган кешеләр булмагандыр, чөнки караңгы, куркыныч елларда Р.Ф.ка катнаштырмак булганнардан куркып, яшереп тә торганнардыр. Язучылар да (сатлык җаннар) язмаларында аның зур галимлеген югалтып, «мөфти» булганы өчен кимсетеп, хурлап язып, безне Зәйнәп апам белән нинди кара хәсрәткә салалар иде. Безнең бүтән хәсрәтләр дә, кайгылар да баштан ашкан чак иде. Мөфти булып, аның ислам тарихын бөтен тирәнлеген, философиясен белгән кеше дип тә түгел, гади намаз әһеле дип кенә яздылар. Хәтта бервакыт Тукай да кайдадыр язган: «Хәзерге көнне ислам дине тарихын тирәннән белгән Риза Фәхреддиннән бүтән кеше дә юк әле, дип уйлар идем», – дигән.

Инде Юлдаш бабабыздан килгән бабаларыбыз – хәзрәтләр барысы да Кичүчатта туганнар. Шунда гомер иткәннәр, барысы да укымышлы, дин әһелләре булып гомер иткәннәр, шунда вафат булып, дәфен кылынганнар. Ничә гасыр гомер үткән, нихәтле нәсел-нәсәп дөнья иткән. Менә бөтен буыннар имам хезмәтен үтәгәннәр, кызлары да имам кешеләргә кияүгә чыкканнар. Шулхәтле күбәүләр! Шул Юлдаш бабай үзенең үткән бабалары белән башта Болгар җире, соңра Казан ханлыгында гомер иткәннәр. Үткән тарихлар барысы да без балаларына әткәйнең искә төшереп, бала чагын, Кичүчатны сагынып сөйләгән эшләре – болар «әкият» түгел, булган хәлләр. Тарихтан билгеле, Казан ханлыгын усал патша алгач, мөселман халкын чукындырып христиан халкына коллыкка ала башлагач, күп мөселман качып, ташлап китә башлаган. Әллә Юлдаш бабабызга бөтен токымы яшәгән илләрен ташлап, бөтен кардәшләре белән, авылдашлары белән дөньяга кирәк нәрсәләр, мал-туарларны төяп, йорт җирләрен, зыяратларын ташлап китү җиңел булганмы?! Билгеле түгел – кайда ничек тормыш корачак. Хәзерге заманда бер квартирадан күчү дә мәшәкать. Менә шулай дөньяга килгән, салынган Кичүчат. Шуңадыр инде, миңа үзем күргәч якын булып күренде. Юкса, мин авылда тумагач, тормагач, барып йөргәнем дә булмагач, хәбәрем дә булмаган. Инде,

миннән зур ихтирамлы рәхмәтемне әйтерсең Таһир әфәндегә. Үзенең тырышлыгы, һәвәслеге аркасында вакытында саклап кала алган Кичүчатны. Бу, һичшиксез, зур батырлык, тырышлык булган. Әзме авыллар шулай «акыллы башлар» сүзе белән юкка чыкты? Шул саклану аркасында безнең бөтен ыруг җыелып торып калган, учак булып, шушы көнгә хәтле. Риза Фәхреддин туган-үскән, ата-бабалары яшәгән Кичүчат, дип, ихтирамлы булды. Тагы бер зур рәхмәтем, үзе теләп, ниятләп, тырышып, ярдәмчеләрне үзенең зур ихтыярына ышандыра алып, иске урынга шундый матур, мәһабәт яңа мәчет булдыра алган өчен. Зур рәхмәтем Самдун әфәндегә! Һәркөн фоторәсемен карап сокланам шул тышы да, эче дә матур, күркәм мәчеткә. Бигрәк тә манарасы сокландыра. Ул Шәрекъ дөньясындагы данлы мәчетләрнекенә охшаган, һәрьягы килгән. Именно Кичүчатта шундый мәчет булганы шатландыра да! Рәхмәтләр әйтәсе килә. Инде тагын бер сүзем: бик яхшы булды, Әнвәрнең апасы – Нурсинә килеп, танышып, күрешеп чыкты. Рәхмәт аңар. Ә менә Әнвәр ерактан гына исәнләште дә, күрешеп-сөйләшергә килмәде, нигә? Сөйләшерлек сүзләр булыр иде. Хатларым бик озын була – бәлки, сиңа кызыксыздыр да. Әткәйнең әткәсе – минем бабам Фәхреддин хәзрәт турында, кирәк булса, киләсе хатта язармын. Син ничек тә вакыт табып мин сораган нәрсәләргә җавап язсаң иде. Ярый, шуның белән бетерергә кирәк инде, укырга да вакытың юктыр. Мине сораган һәммә кешегә (әбиләргә, бабайларга) сәлам әйтерсең. Әйтергә онытканмын, мәчеттә бер агай-эне (пенсионер) минем белән күрешеп-танышкач, сөйләде: әткәй Кичүчатка килгәндә ул аны күргән, үзләренең зурлар артыннан, әткәй артыннан йөргәннәрен бик яхшы хәтерли. Әткәй сөйләгән иде: балаларның (көтүләп) ияреп йөргәннәрен. Үзенең исемен сорарга исемә килмәгән, бик тыгыз, кеше күп җирдә сөйләгән иде. Әткәгез Риза хәзрәтне бик хәтерлим, диде. Ул да миңа шатлык.

Барыгызга да исәнлек, тынычлык теләп калам. Үзеңнең укуларың ничек? Кайчан Казанга килергә кирәк? Әгәр сездәге газеталарда әткәй турында булса, салырсың.

Сәлам белән, Әсма апа.
Арсланнан барыгызга да күп-күп сәлам.
9/XI

***

Хөрмәтле дуслар – Шаһиевлар гаиләсен килеп җиткән Яңа 1993 ел белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Барчагызга сәламәтлек, эшләрегездә уңышлар, гаилә тормышыгызда дуслык, бәхет теләп калабыз. Яңа еллар уңышлы, тыныч, мул тормыш китерсен иде. Булган авырлыклар шушы високосный елда калсын иде. Яхшы теләкләр. Кичүчатта безне сораганнарга сәлам.

Әсма Шәрәф

Исәнме-саумы, Рәфкать дус!

Үзеңә, әниеңә, әтиеңә, әбиеңә, апаңа күп сәлам. Шулай ук Әнвәрләргә, гаиләләре белән, туганына сәлам. Үземнең хәлем шөкер булмаса да, бик кирәк булгач, язарга туры килә. Үзеңне бик көткән идек. Ахры, вакытың кысандыр, килә алмадың. Сөйләшәсе, сорашасы сүзләр бар иде. Кайчан киләчәгең дә беленмәде. Үземнең хәл һаман авыр хәлдә. Урысча газетага язганда: «Длительно тяжело болеющий», – дип язалар бит. Инде кирәк сүзләрем, иң беренче: икебезнең дә хәтердә юк – без әткәйнең 1 том басылган китабын Әнвәргә биргәнбезме, юкмы? Шул турыда, вакыт табып, эш арасында, язып сал. Җавап көтәм. Мин бер хәл – Арслан оныткан. Әгәр бирсәк – бик яхшы, бирмәгән булсак – син килгәндә алып китәрсең, аңарга дигәне әзер. Икенчесе: бөтен кешегә «особо» ошаган фоторәсем 2 шт. Арслан белән без икәү (яңа фото), берсе – үзебездә, берсен – Ташкент, әниләре вафат Фәхретдиневләргә җибәрдек. Уфага Фәхретдиневләргә – ике,

Р.Фәхреддин гаиләсе белән. 1 рәттә (сулдан уңга): Нурҗамал, Әсма, Ризаэддин, Сәгыйть; 2 рәттә: Габдрахман, Габдерәшит, Зәйнәп, Габделәхәт

һичшиксез, ә аларга юк: 0. Мондагы туганнар сорасалар «юк» дип кенә әйтәм. Марсельгә дә юк. Солтанбәков та бик сорый, тоже юк. Инде бигрәк тә: музейга дип, Арсланны зыяратта Зәйнәп апа һәм этисе ихаталары (каберләре. – Р.Ш.) янында төшергән рәсемнәр – бигрәк тә яхшы, академически чыккан. Ә бездә – юк, бик кирәк бит Арсланга истәлек. Алла гына белә, минем сурәтләр, бәлки, актык истәлекләрдер дә. Инде үтенеч: музейга бар төшергән фотолар да куелмасын иде. Нигә? Кемгә? Особо эткәйгә якын – балалар, туганнар булсын иде. Үзегез сайлап алырсыз. Минем теләк шул.

Хәерче заман, язарга каләм дә юк бит. Көчкә язам. Синнән бүтән берәүгә дә язганым юк. Үзең кайчан киләсең?

Ничек булса да 5-10 минут вакыт өзеп язарсың, дип уйлыйм. Өметләнәм. Әнвәргә татлы күчтәнәче өчен рәхмәт тә әйтергә оныттым, ахры, әйтерсең. Минем исемнән – ничек тә булса.

Үзебездән берегезгә дә Казан күчтәнәчләре җибәреп булмый бит. Марсельне күреп фотоларын бирә алдыңмы? Р.Ишморат биргән «Шура» журналын музейга бирәме, әллә үзендә калдырамы?

Газетада басылган язмаларны сакларсың. Ярый, хәзергә сау булыгыз. Кызык хәбәрләр булса, яз. Минем бер күзгә пыяла кирәк (+7), һич юк!

Сәлам белән, Әсма апа. 20/IX

Исәнме-саумы, Рәфкать... дус буласың инде!

Бөтен гаиләгезнең һәрберсенә бездән күп сәлам! Җайсыз булды бу юлы, сине күрә алмадым. Бердән, звонокларны ишетмәгәч, хәлем начарланып киткәндә гел ятып торганга, күрми калдым. (Әсма апа звонокны ишетми башлагач, Арслан абый кыңгырауга басуга кызыл ут кабына торган итеп көйләде. – Р.Ш.). Арслан үзе бикләп, үзе ачып йөри иде. Бу юлы өйгә керүчеләрдән куркып, цепочканы эләктергәнмен, ул ача алмаган, мин каты ятканмын. Син, көтмәгәндә генә, тиз генә килеп киткәнсең. Сиңа зур рәхмәт, фотоларны алып килгәнсең. Самдунга нинди рәхмәт әйтергә белмим инде. Шулхәтле яхшы, ямьле, матур, ачык, күптөрле рәсемнәр булган. Менә «мастер высшего класса», специалист! Мондыйны күргәнем дә юк иде. Бу юлы бигрәк матур, изъянсыз булганнар, хәтта мин үземнең фотоларымны яратып кабул иттем. Ә ул бит сирәк була – үзеңнең кыяфәтең белән килешкән булу. Хәтерендәме, бергә төшкән фотографиядә мин нинди ямьсез булган идем, карыйсым да килмәде. Тик бер генә үтенеч бар: кай-

бер фотоларның артыграк булуы кирәк иде. Билгеле, ул берәрне генә эшләмәгәндер. Без аларның кайберләрен Ташкент Фәхретдиневләргә (оныклар), кайберләрен Уфа Фәхретдиневләргә (оныклар) җибәреп шатландырыр идек. Бу елларда үзебез дә бара алмадык. Матур фотоларыбызны карарлар иде. Алар барысы да безне бик яраталар. Әгәр дә аңарда артыклар булса, бигрәк зур рәхмәтле булыр идек. Мәсәлән: 1) Мин ялгыз аксыл чуар күлмәктән, икесе дә; 2) Арслан белән икәү бергә; 3) Мин балконда, бөтен урам матур күренә; 4) Без дүртәү бергә утырып кына төшкән (син, мин, Самдун, Арслан) – эткәйнең Кичүчатында туып үскән якыннары белән. Биреп эшләтсәң, бозып кына бетерерләр, кирәкми, диде Арслан. Самдун шикелле оста ничек була икән? Ишетмәү дә бик авыр хәл. Эткәйнең актык фотосы шундый (китаптан алып эшләгән) матур, күркәм. Стенага беркетеп куйды Арслан. Икебезгә дә бик ошый. Язуларым бигрәк начарланган инде, гаеп итмәссең.

Бик озакка киткән авырулар да җәфа чиктерә, кайчакларда бик авыр була.

Хәзергә шуның белән бетерәм. Барыгызга да исәнлек, эшләреңдә уңышлар теләп калабыз икәүләп.

Сораганнарга сәлам. Кучтәнәчеңә рәхмәт.
Әсма апа. 3/VIII

Исәнме-саумы, Рәфкать туган!

Сәлам соңында яхшы теләкләр. Синең ике хатыңны алдык, рәхмәт. Газетаны алганга шактый вакыт җавап килмәгәч, әллә бармады микән, дип шикләнгән идем. Хәзер почта да озак эшли торган. Әүвәл 2-3 көндә килә торган хатлар атна-ун көннәр йөри. Үзем дә тиз генә җавап яза алмадым. Тәрәзәдән (ачык форточкадан) салкын тиеп, каты гына авырып алдым. Өйдә утырган кешегә шулай буладыр инде.

Танышлар да, таныш булмаганнар да килгәләп торалар. Барсының да белмәгән нәрсәне беләселәре килә. Менә хәзер бөтен язылган, сөйләнгән хәбәр 21/III – Референдум турында. Безнең шәһәрдә мәркәзне (сүз Мәскәү турында. – Р.Ш.) яклаган усал кешеләр, безнең халыкка бик каты тискәрелек белән, газеталарда прокламацияләр (басылган мәркәздә) белән безнең халыкны бик каты сүзләр белән тиргәп, куркытып «Да»ны сызып, «Нет»ны калдырырга дигән бик каты сүз алып баралар. Сез Казан телевидениесен карыйсызмы?

Әле ай башында мине эзләп тагын бер Миңлебай авылы кешесе килде. Монда санаторийга килгән. Хәзер пенсиядә, әүвәл мәктәп директоры булган. Кичүчатта музей ясамакчылар дигәч: «Анда барам әле», – дип, синең адресыңны алып китте. Алар Кәримовларга музей ясамакчы булалар. Әле эткәй турында ул яңа гына танып, сораша башлаган. Эшләгәндә андый эшләр белән булышмаган кебек.

Үзеңдә нинди яңалыклар бар? Сессиягә килеп, кермичә киттеңме әллә? Укулар барамы? Музейга дип төшкән фотоларда мин бигрәк әшәке чыкканмын, борчылдым. Тагын борчылдым: газетада минем «истәлекнең» иң кирәк әһәмиятле урыннарын кыскартып, басмыйча, кертмичә калдырганнар. Эткәмнең хезмәтендә бик мөһим эшләр иде. Кызганыч...

Ярый, хатым озын булды. Әниеңә миннән сәлам әйт, исән-сау булсын. Вакытың булганда, хәбәрләр булса язгала.

Эшләреңдә уңышлар теләп калам.
Әсма апа. 20/III

Исәнме-саумы, Рәфкать туган!

Бездән Сезгә – әниеңә, этиеңә, әбиеңә, барча туганнарыңа – мин күргәннәргә дә, күрмәгәннәргә дә сәлам! Хатыңны алдык, рәхмәт. Мин ул хатны бик көткән идем.

Синең вакытың юк булса да, һәртөрле эшләр башыңнан ашкан булуын бик яхшы белеп торсам да, бер 10 гына минут табып язар әле, дип көттем. Әле һаман, шушы көнгә хәтле, Кичүчат истәлеге белән яшим. Күргән-күрешкән кешеләр, күрмәгәннәрен дә белгән шикелле. Гаҗәп хәл! Күптән танылган, күрелгән җирләр, кешеләр шикелле – бу инде әткәй һәм бабайлар йогынтысыдыр. Синең килүең, эзләп табып танышуың бөтен эшнең башы булды.

Мәчет ничек гомер итә, баручылар буламы, әллә йозак астылармы? Сиңа киңәш: син мәктәптәге бөтен эшне үзең генә «өстерәмә»! Кулыннан килгән укытучыларны да вак-төяк булса да актив эшкә катнаштыр. Ул файдалы түгел, бөтен йомышка үзең генә йөгерү. Әнә, булган зур хуҗа ике төрле зур эшне алып барган иде, ни булды, берсен сразу бушатырга кирәк иде.

Үзеңнең сабак эшләре ничек? Кайчан Казанга килергә була?

Сиңа әманәт: Самдун абыеңа әйт, аның безгә килеп, минем белән күрешеп сөйләшеп утырганына мин бигрәк тә шатландым. Әгәр шулай булмаса, әткәйнең кешелеген зур ихтирам иткән кеше белән танышмыйча китсәм күңелемнең бер почмагы китек булыр иде (син беләсең).

Әткәйнең исемен хөрмәт белән истә тоткан кичүчатларга рәхмәт. Әгәр сездәге газеталарда хәбәр чыкса, җибәрерсең. Мине белгән, сораган кешеләр булса, сәлам әйтерсең. Белгән кешеләргә (алар бар иде) әйтерсең: Салих абзыйның Асия исемле кызы вафат булды, шушы арада җидесе дә үтте инде. Ике ел бик авырган иде инде, кызы Рәисә тәрбияләде. Нәрсәгә икәнен белмәдем, Җәүдәт (Салих абзый) сорарга кушты: Әнвәрнең хатынының исемен, атасының исемен, нинди фамилиядә. Нигә кирәк булгандыр, белмим.

Бүтән хәбәрләр юк бугай. Килгән кешеләргә фотоларны күрсәтәм дә, менә Кичүчат мәчете [дип] (мактанып) куям. Күргән кешеләр бик ошаталар. Вакытың булса язарсын әле. Барыгызга да исәнлек, тыныч гомер, эшеңдә уңышлар теләп калам.

Әсма апа.
8/XII

Рәфкать туган!

Барыгызга да күп сәлам. Бу арада хат язган идем. Бу хатым кыска гына. «Ватаным Татарстан» газетасында басылган Самдунның мәкаләсе бик тә ошады, шундый оста яза белә икән. Газетаны сезгә җибәрә алмыйм, үзебезгә дә бер кеше үзенекен «бүләк итте». Кайчан, нәрсә чыгасын алдан белмәгәч, күрми дә каласын. Мең газетага языла булмый бит, ә хәзер инде бөтенләй укудан мәхрүм булабыз. Үземнең язманы да очраклы гына күреп алып калдык. Татарчада 2-3 нәрсә ята, басмыйлар. Шуңа күрә урыс газетасына, урысча язарга туры килә. Дуслар ярдәм итәләр. Кайчан киләсеңне язмадың. Яңа елдан соңдыр инде. Кичүчатлылар нинди эшләр бетереп яталар? Мәчет ничек яши? Сораган кешеләргә бездән сәлам. Бездә әллә нинди яңа хәбәрләр юк.

Һәр эшләреңдә уңышлар теләп калам.

Сәлам белән, Әсма апа.
15/XII

Ахыры киләсе санда ■

Казиле мәчете һәм мәдрәсәсенең тарихы

Энҗе Гайнетдинова, Лилия Закирова*

Казиледә гомер кичергән Солтан абзый Гыйлфанов 1970 нче еллар азагында мәктәп укучыларына менәниләр сөйләгән: «Авылыбызда гаҗәеп бер корылма – авыл җирендә сирәк очрый торган таш мәчет бар. Татар халкының архитектурасы хакындагы фәнни хезмәтләрдә бу корылма турында әле моңарчы берәүнең дә язганы юк. Бары тик авыл халкының буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән хикәяте мәчетнең салыну тарихын онытмаска ярдәм иткән. Казиле мәчете XIX гасыр азагы-XX гасыр башында корылган; архитектурасында Казан осталарының кулы сизелә; кирпечне дә губерна каласыннан ташыйлар, витражлар өчен төрле төстәге пыялаларны да шуннан китертәләр; авыл җирендә агач мәчетләр җиткерү стилен дә читләтеп үтмиләр – иркен зал булдырып, манараны төньяктагы очына ук чыгарып утырталар; осталарны мишәр якларыннан да, Балтач белән Чүтидән дә чакырталар. Әллә ни бизәкләп тә эшләнмәгән инде югыйсә, шулай да мәчет гаҗәеп мәһабәт күренә. Аның кирпечтән сырлап салынган диварлары да, михраб ягында төрле төстәге пыяладан корылган витраж тәрәзәсе дә бер күркәмлек биреп тора. Мәчет бинасы яхшы сакланган һәм анда хәзер авылның культура йорты урнашкан. Бары тик 1978 елгы җил-давыл гына мәчет манарасының очындагы айны очыртып төшергән һәм хәзер ул (бакырдан өрдереп тутырылган) мәчет каршындагы бер өйдә саклана. Казиле мәчете үзенең оригинальлеге белән дәүләт тарафыннан саклана торган тарихи биналар исемлегенә кертелергә, шулай ук Татарстанга багышланган альбомнарда һәм архитектура басмаларында һичшиксез урын алырга лаеклы».

Казиле мәчете. Бу бинада урнашкан башлангыч мәктәптә хәзер өч бала белем ала

*__Энҗе Гайнетдинова__ –Татарстан Республикасының Милли архивы хезмәткәре.
Лилия Закирова – Арча районының Түбән Мәтәскә урта мәктәбе укытучысы.

Солтан Гыйлфановның хыялы соңрак кына гамәлгә аша. ТССР Министрлар Кабинетының 1991 елның 31 июнендә кабул ителгән 337 нче карары нигезендә, Казиле мәчете һәм аның янындагы мәдрәсә бинасы җирле әһәмияткә ия булган тарихи архитектура һәйкәлләре исемлегенә кертелеп, дәүләт тарафыннан саклауга алына.

Мәчет 1899 елның маенда Казан губерна идарәсе тикшергән һәм раслаган проект буенча, шул ук елда янган мәчет урынында төзелә. ТР Милли архивында әлеге проект һәм авыл халкының аны төзү турындагы җыен карары саклана. 1899 елның 21 маенда язылган беркетмәгә губерна инженеры Хризоновичъ, губерна архитекторы вазыйфаларын башкаручы Малиновский кул куйган.

Казан губернасының Казан өязе Кармыш (хәзерге Казанбаш) волостендагы Казиле авылы җыенының карары 1899 елның 16 мартында язылган. 125 хуҗалыкта тавыш бирү хокукына ия булган 270 кеше исәпләнгән. Авыл җыенына халыкның өчтән икесе – 85 кеше килә. Җыен авыл старостасы Камалетдин Сәйфетдинов һәм волость старшинасы Мөхәммәтҗан Хәйбуллин катнашында уза.

Карарда агач мәчетнең 1899 елның 8 февралендә нигезенә кадәр янып бетүе һәм дини йолаларны башкару өчен яңа мәчет кирәклеге искәртелә. Шунда ук Мамадыш өязендәге Әсән Елга волостеның Кәчемир авылы крестьяны Хисмәтулла Нигъмәтулла улы Әмировның аны төзергә матди ярдәм итәчәге әйтелә. Иганәче үзенең таләпләрен куя: мәчет таштан һәм аның планы буенча төзелергә тиеш. Бинасы озынлыкка – 38 аршын, киңлеккә – 14 аршын, биеклеккә – 9 аршын һәм төзелеш уставы кагыйдәләре буенча манарасы булуы шарт.

Мәчет өчен авыл уртасындагы ачыклыктан урын билгеләнә. Бу җир кечерәк булу сәбәпле, ике хуҗалык – крестьян-азанчының тол хатыны Газиниса Хөсәенова йорты һәм Хәбибулла Гыйбадуллин йорты сүтелеп, мәйдан киңәйтелә. Авыл җыены

Мәгсумов Ильфирның йортында саклана торган XIX гасыр шамаиле. Казиле авылы

Хисмәтулла Әмиров планы буенча таштан мәчет төзергә һәм аның өчен җиргә рөхсәт бирүне сорый. Мәчет төзелгәннән соң, аны җылыту, карап торуны да авыл халкы үз өстенә алырга вәгъдә бирә. Бу документта җыенга килүче 85 кешенең дә исем-фамилиясе теркәлгән. Бәлки кайберәүләр үз бабаларын табар, дип, исемлекне сезнең хозурга тулысынча тәкъдим итәбез: Сабит Насыйбуллин, Рәхимулла Бәдретдинов, Шәмсетдин Дәүләтшин, Гыйльметдин Бикмөхәммәтов, Бикмөхәммәт Мөхетдинов, Лотфулла Бикбаев, Әхмәтҗан Муллаҗанов, Гыйлаҗетдин Мифтахетдинов, Миңнулла Вәлиев, Әхмәтша Гадершин, Шәрәфетдин Шәмсетдинов, Шәрип Шәмсетдинов, Гыйлаҗетдин Фәхретдинов, Заһидулла Бәдретдинов, Гыймадетдин Нәҗметдинов, Закир Нәҗметдинов, Мөхәрләм Минияров, Нәҗметдин Абдрахманов, Зайнулла Сәмигуллин, Шаймулла Илсанов, Баһаветдин Исмагыйлев, Гыйбадулла Зәйнуллин, Гобәйдулла Сәйфуллин, Җәләлетдин Сәйфетдинов, Шәйхетдин Нәҗметдинов, Мифтахетдин Сираҗетдинов, Баһаветдин Нәҗметдинов, Гыймадетдин Йөзлекәев, Ильяс Нәҗметдинов, Шаһи Миңнияров, Хәйрулла Сәйфуллин, Галиәхмәт Бикмөхәммәтов, Нигъмәтдин Муллаәхмәтов, Хәйрулла Галиәкбәров, Хәбибулла Исмәгыйлев, Шәрәфетдин Фәизов, Фәтхулла Сәлимов, Шаһвәли Галиев, Низаметдин Мөхәмәтдинов, Вәлит Халидов, Әхмәтша Дәүләтшин, Вәлиулла Бәдретдинов, Гайфулла Фәйзуллин, Җиһанша Мөхәммәтшин, Шаһимәрдән Рамаданов, Әхмәтҗан Мөхәммәтов, Дәүләтша Вәлитов, Гайнетдин Халитов, Камалетдин Нәҗметдинов, Надырша Әхмәтшин, Юсупов, Сабирҗан Сәйфелмөлеков, Баһаветдин Фәхретдинов, Закир Юсупов, Сәмигулла Гатауллин, Гатаулла Фәхретдинов, Сәгъди Сәйфетдинов, Таҗетдин Вахитов, Әүхәди Абдрахимов, Гимадетдин Ибатуллин, Мөхәммәтгалим Мөхәммәдиев, Ибраһим Шәрәфетдинов, Бикбай Биккенин, Шакирҗан Биккенин, Насыйбулла Сабитов, Галләм Абдрәшитов, Фәхретдин Әюпов, Гыйльметдин Байтирәков, Җамалетдин Сәйфетдинов, Имаметдин Хисаметдинов, Нәбиулла Галиуллин, Нигъмәтҗан Әхмәтҗанов, Сафиулла Исмәгыйлев, Галәветдин Исмәгыйлев, Фәхретдин Нәҗметдинов, Кәлимулла Галиуллин, Кәлимулла Галиев, Минһаҗетдин Мифтахетдинов, Сәйфелмөлек Сәйфуллин, Кәрим Сабитов, Сибгатулла Сәмигуллин, Хәмит Салихов, Хәбибулла Гыйбадуллин, Газиз Абдрәшитов һәм староста Камалетдин Сәйфетдинов. Приговор азагында Арча мещаны, волость писаре Дмитрий Федорович Кустовның кулы куелган.

Казиле мәчетенең проекты. ТР МА, ф.2. Оп.14. э.168.



Авылда мәчет төзү турындагы җыен карары. Документ ТР Милли архивында саклана

Элгәреге мәчетләр турында мәгълүмат

Таш мәчетнең тарихы билгеле булса да, янып көлгә әйләнгәненеке яки беренче мәчетнең төзелү тарихы билгесез, дияргә була. Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» исемле китабының икенче томында Татар ратушасында тәрҗемәче булып эшләгән Рәхмәтулла бине Әмирхан бине Имәнколый бине Нурсәед әл-Кишетинең (1875 елда вафат) *Казиле авылында мәчет* салдыруы турында язып калдырган.

Авылда мәчетнең XVIII гасырда һәм аңа кадәр үк булганлыгын раслаучы тагы бер чыганак бар. Бу – 1742 елгы «Экстракт в Правительствующий сенат из Казанской губернской канцелярии о татарских мечетях» исемле документ. Аны галимнәр Фәйзелхак Ислаев һәм Рәшит Галләмовлар Мәскәүдәге Россия дәүләт борынгы актлар архивы документлары арасыннан табып, җентекләп өйрәнеп, саллы фәнни мәкалә белән «Гасырлар авазы» журналының берничә санында бастырды. Чыганакта урыс булмаганнарны чукындыру сәясәте вакытында Казанда һәм өязендә 536 мәчетнең 418е җимерелгәнлеге, Арча юлындагы Казиле авылын да бу афәт читләп үтмәгәнлеге теркәлгән.

«458. В деревне Казамбаше три мечети при пятидесят[и] пяти дворах. Рас[с]тоянием до **Казыльской мечети** в четырех верстах. Из оных одна сломана. Новокрещен во оной деревне не имеетца. От пригорода Арска в пятнатцети верстах. А скаскою той деревни жители показали: мечет[ь] их построена в котором году — не упомнят.
459. В деревне **Казылях мечеть** сломана при тритцети дворах. Рас[с]тоянием до Верхней Метескинской мечети в семи верстах. Новокрещен во оной деревне не

1872 елда төзелгән мулла йорты. Хәзер бу йортның хуҗасы - Ильфир Мәгсумов

имеетца. До пригорода Арска в двенатцети верстах. А скаскою той деревни жители показали: мечеть их построена в котором году — не упомнят».

Имамнар

ТР Милли архивында мәчетнең имамнары турында мәгълүмат XIX гасырның 30 нчы елларыннан башлана. 1833 елның 1 ноябрендә мәхәлләнең имам-хатыйбы итеп **Таҗетдин Габделҗәлилев әд-Дөбъязи** (1806-1886) билгеләнә. Бәрәскә, Мәчкәрә һәм Ташкичү авылларының мәдрәсәләрендә белем алган хәзрәт Коръәнне гаять матур итеп көйләп уку сәләтенә ия булган. Ш.Мәрҗани дә тәҗвид, кыраәт серләренә Таҗетдин Габделҗәлилевтән өйрәнә. Таҗетдин хәзрәт гомеренең ярты гасырдан артык өлешен Казиле халкын һәм тирә-яктан килгән шәкертләрне аңлы-гыйлемле итүгә багышлый. Аның хакында Ризаэддин бине Фәхреддин «Асар» исемле мәшһүр хезмәтендә менә нинди мәгълүмат язып калдырган:

«Таҗетдин бине Габделҗәлил бине әл-Хөсәен бине Сафакол бине Ката әс-Сәрдәви. Казан нахиясе (төбәге) Казый Иле карьясендә имам булып, 80 яшеннән узып, өч йөз өченче (1303/1886) ел тирәсендә вафат булды. Остазлары: Габдерәхим бине Бикчәнтәй әл-Бәрәскәви, Ягъкуб бине Яхъя әл-Кышкари, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртуши, Таһир бине Сөбханкол әл-Адайидыр. Кыйраәт гыйлемендә маһарәтле (сәләтле) булуы берлә шөһрәте бар».

1884 елның 30 маеннан имам хезмәтен авыл җыены чакыруы буенча килгән **Габделхак Гарифҗанов** башкара. Ул Лаеш өязенең Олы Кибәхуҗа волостендагы Теләче авылы крестьяны булган, шунда ук имам вазыйфасын да үтәгән. 1892 елның 7 июлендә

*Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар»ендә Габделхак хәзрәтнең әтисе, Олуг Кавал, Нурма һәм Курса авыллары имам һәм мөдәррисе, тулы нәсел-нисбәсе белән әйткәндә, Гатаулла бине Мөхәммәд бине Фәйзулла бине Габдулла бине Йосыф бине Уразмәт бине Шамша бине Шауша бине Йосыф әл-Курсавиның да гомеренең азагын Казиле авылында, улы тәрбиясендә уздырганы турында мәгълүмат бар.

Казиле авылының мәчет манарасыннан күренеше. 2018 ел, сентябрь

аны Казан өязенең Югары Аты кешесе **Габделхак Гатаулла улы Фәйзуллин** алыштырган. Нәкъ менә Габделхак мулла булган елда Казиленең агач мәчете яна да инде. Янә Р.Фәхреддиннең «Асар»енә мөрәҗәгать итик:

> «Габделхак Казый Иледә имам вә мөдәррис булып, 1323-1906 тарихында дөньядан үтте. Яше 41дә генә иде. Шәкерде күп иде, диләр*».

Габделхак хәзрәтнең вафатыннан соң, авылга имам итеп Түбән Мәтәскә авылының указлы мулласы **Мөхәммәтфатыйх Мөхәммәтшакир улы Яхин**ны чакыралар. Үзе килергә риза булса да, Түбән Мәтәскә авылы халкы аны җибәрергә теләми. Бу хакта Мөхәммәтфатыйх мулланың Казан губерна идарәсенә 1906 елның 17 апрелендә язган гаризасыннан белергә мөмкин.

1907 елның 2 сентябреннән авылда имам-хатыйп вазыйфаларын 1866 елның 16 июнендә туган **Сабирҗан Габделбадыйков** башкара. Казилегә килгәнче ул Мәмсә волостендагы Байчура авылының икенче җәмигъ мәчетендә указлы мулла булып хезмәт иткән.

Казиле мәдрәсәсе һәм аның шәкертләре

Казиле авылы XX гасыр башында мәгарифнең яңа, алдынгы ысул-алымнарына нигезләнгән җәдиди мәдрәсәсе белән дан казана. Сабакка барлыгы иллеләп шәкерт

Казиле мәдрәсәсе бинасының 2008 елгы янгыннан соңгы күренеше

йөреп, гыйлем йорты мәхәллә кешеләренең иганәсе хисабына тәэмин ителгән. XIX-XX гасырлар чигендә бу уку йорты өчен махсус, кирпечтән бер катлы бина салына. Заманында үзенең күркәмлеге, уңайлылыгы ягыннан бөтен өяздә иң яхшылардан саналган уку йорты хәзерге көндә, мәчетләрне исәпкә алмаганда, районыбызда революциягә кадәрге бердәнбер тарихи мәдрәсә бинасы булып тора.

Аның ачылу тарихы безгә билгесез, бу турыда документлар да сакланмаган. Әлегә кадәр авыл мәдрәсәсендә кемнәр укып чыкканлыгы турында да тәфсилле мәгълүматыбыз юк. «Балтач энциклопедиясе»ннән бередә белем эстәгән бер шәкертне таптык. Ул – мәгариф ветераны, Ленин ордены кавалеры Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтзариф улы Мөхәммәтзарифов (1891-1967). Тарих фәннәре докторы, профессор Айдар Хабетдинов «Влияние бухарской образовательной традиции на татарскую элиту в XVIII – первой половине XIX века» дип аталган мәкаләсендә имам һәм мөдәррис Сәгыйть бине Әхмәт бине Мөхәммәт әш-Шырданиның Казиле һәм Казаклар мәдрәсәләрендә укуы турында әйтә. Алда язып үткәнебезчә, Шиһабетдин Мәрҗани дә Казиле мулласы янына килеп, тәҗвид, кыраәт һәм мәкам гыйлемен камилләштергән.

***

2009 елда мәчет реставрацияләнеп, капиталь төзекләндерү үткәреләде. Хәзерге вакытта бинаның ярты өлеше гыйбадәтханә, бер ягы башлангыч мәктәп буларак хезмәт итә. Бу эшләрне башкарганы өчен, Казиле кияве Сәлихҗан Закировка авыл халкы бик рәхмәтле.

Мәдрәсә бинасында 1918 елдан бирле башлангыч мәктәп эшләп килде. Кызганыч, аңа терәп салынган янкормада 2008 елда янгын чыгып, гыйлем йорты файдалануга яраксыз хәлгә килде, таш диварлары гына калды. Гасырдан артык аң-гыйлем үзәге булган мәдрәсә бинасы җимерелеп беткәнче, якын арада түбәсен ябып, киләчәктә реставрация-төзекләндерү эшләре дә башкарылса, республикабыздагы тагын бер тарихи-мәдәни һәйкәлгә яңа сулыш өрелер иде. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Татар дөньясын яктырту: мәгърифәтчелектән – электр энергиясенә

Зөлфәт Мингалиев[1]

XIX йөзнең икенче яртысы-XX гасыр башы – дөнья тарихында, Россия империясендә, шулай ук татар-мөселман тормышында зур үзгәрешләр барган еллар. Техник прогресс, фән казанышлары берсе артыннан берсе җәмгыять файдасына эшкә куела. Электр энергиясе, суүткәргеч, канализация, телефон, граммофон, лифт, кинематограф, вентиляция, трамвай, асфальт, тимер-бетон – шул вакытның иң танылган техник яңалыкларын куллану өчен көннән-көн уңайлырак шартлар туа. Уңайлыкларга мөкиббән киткәнлек, электр энергиясен кулланып, сәнәгать өлкәсендә җитештерүне үстерергә тырышу җәмгыятьне зур адымнар белән алга этәрә. Икътисад өлкәсендә яңадан-яңа күренешләр

Электр энергиясе кертелгән Печән базары мәчете һәм урамы. XX йөз башы

[1] Зөлфәт Мингалиев – «Ислам динен кабул итүгә мең ел» исемендәге мәдрәсә мөгаллиме. Мәкалә басмага 7 мартта Болгар шәһәрендә узган «Кулатки укулары»нда ясаган чыгышы нигезендә әзерләнде.

Романовларның 300 еллыгы уңаеннан Казандагы кайбер йортлар менә шулай бизәлгән. 1913 ел

өстенлек ала, капиталистик мөнәсәбәтләр сәүдә, эш йөртү өлкәләренә үтеп керә, банклар, биржалар, эре заводлар һәм ширкәтләр барлыкка килә. Бу чорда капитализмның үсеш алуы белән бергә, шуның нәтиҗәсе буларак, мәгарифтә дә алга китү күзәтелә. Техник прогресс белем алу белән никадәр тыгыз бәйләнгән булса, алга китеш, искечә әйткәндә, тәрәккыят тә аң-гыйлем белән шулай ук нык багланышта.

XIX гасырның 70-80 нче елларында беренче татар фирмалары барлыкка килә. Аларның оештыру капиталлары йөзәр мең сумнарга җитә. Рәсми мәгълүматлар күрсәткәнчә, татар эшкуарлары төрле зурлыктагы 141 ширкәткә ия була. Аларда 12 мең кеше эшли. Бу фирмалар Русиянең төрле төбәкләрендә урнашсалар да, күбесе татар-башкорт күпләп яшәгән Идел-Уралда була.

Милли тәрәккыят, беренче чиратта, җәдитче дин әһелләре һәм алдынгы карашлы яшь татар интеллигенциясе, милли буржуазия белән бәйле. Бу катлау вәкилләре, дәүләтнең бернинди финанс ярдәменә өмет итми, милли вакытлы матбугат, китап басу, төрле мәдәни-мәгърифәт структуралары төзегән, замананың техник казанышларын актив кулланган, яңа технологияләр керткән, чит ил базарларына чыккан, шифаханәләр, ятимнәр йортлары, мәдрәсә-мәктәпләр ачкан, төрле өлкәләрдә хәйрия фондлары төзегән.

XIX гасырның икенче яртысында татар җәмәгатьчелегенең үсешенә зур йогынты ясаган шәхесләребезнең иң олысы, әлбәттә, күренекле дин белгече, фәлсәфәче, тарихчы, дини реформатор һәм мәгърифәтче Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани булды. Ул татар җәмәгатьчелегенә дин белән фәннең янәшә тыныч яши алуын исбатлый алды. Мәржани фәнни белемне, замана техник казанышларын халык арасында тарату зарурлыгын алга сөрде. Аның фикеренчә, фәнне зурлау, дөньяви фәннәрне өйрәнү җәмгыятьнең социаль-икътисади, матди ягы үсешенә ярдәм итсә, динне өйрәнү җәмгыятьнең рухи яктан камилләшүенә китерә. Ул мәгърифәтчелекне милләтне прогресска илтүдә иң көчле корал дип саный[2].

[2] Юзиев А. Милли идеологиягә нигез салучы // Казан утлары. – 2008. – №1.

«Красная Заря» исемле 1 нче электр станциясе. Казан

Дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист, нашир Гатаулла хәзрәт Баязитовны да без төрле дини дәреслекләр, ислам тәгълиматына багышланган берничә җитди китапның авторы буларак беләбез. Гатаулла хәзрәт «Эрнест Ренан телмәренә каршы төшү» (1887) китабында «ислам нигезләре белән фән-гыйлем яраша алмый», дигән фикер әйткән француз галиме белән бәхәс алып бара. «Ислам һәм тәрәккыят» (1897) китабында Коръән кануннарының заманча тәрәккыят кануннары белән ярашуы тәгълиматын алга сөрә. Автор, ислам дине фән үсешенә каршы түгел, ә киресенчә, фәнне өйрәнергә, үстерергә өнди, дип белдерә.

Завод-фабрикаларда, сәүдә һәм финанс учреждениеләрендә эшләр өчен укый-яза белгән эшчеләр һәм хезмәткәрләр әзерләүгә ихтыяҗның арта баруы милли мәгарифкә дә реформа үткәрүне көн тәртибенә куя. Мәктәп-мәдрәсәләрдә рус телен өйрәнүгә омтылыш көчәя, табигать фәннәре, тарих, география һ.б. предметлар кертелә. Татарларда дөньяви белем алуга омтылышның көчәя баруына Казан университетының мөгаллимнәре Ибраһим Хәлфин, Мөхәммәдгали Мәхмүдов, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри һ.б. да зур йогынты ясый.

К.Насыйри тарафыннан 1873 елда татар телендә арифметика буенча беренче «Хисаплык» дөнья күрә. 1895 елда ул, геометрия буенча сызымнар, циркуль һәм транспортир куллануны аңлатып, «Геометрия фәне» китабын бастырып чыгара. 1900 елда аның «Ювелирлык һәм слесарьлык эше турында» исемле китабы киң тарала. Бу китапта аерым алымнар химия һәм физика законнарына таянып аңлатылган. К.Насыйри графит, фосфор, гипс, зәһәр калий, күкертле водород, бакыр һәм тимер купоросын, цинк, сода, бакыр оксидын һ.б. кулланырга өйрәткән. Аңа, ярдәм сорап, мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның да мөрәҗәгать итүе мәгълүм[3].

Галимҗан хәзрәт Баруди, беренчеләрдән булып, милли мәгариф кануннарына кыю рәвештә үзгәрешләр кертә башлый: 1891 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, аның артыннан 10 нчы мәхәллә мәдрәсәсе «Якубия» дә аваз ысулы белән яңача укытуга күчә. Галимҗан

---

[3] Мәгариф фәлсәфәсе һәм тарихы: югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы / Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Р.Р.Насыйбуллов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. – 372 б.

хәзрәт 3-4 ел эчендә 30дан артык дәреслек төзи. Алар арасында «Нәмунәи хисаб» («Үрнәк хисап»), «Бәдә әл-мәгариф» («Белемнәрнең нигезе») һәм башка хезмәтләр бар. Ул китапларның күпчелеге мөселман мәктәпләре өчен кулланмага әйләнә. Галимҗан хәзрәтнең шәкертләре, дини белем белән бергә, гарәп, төрек һәм рус телләрен, арифметика, физика, геометрия, психология, география, педагогика, Русия тарихы, төрки халыклар тарихы һ.б. фәннәрне дә үзләштергән.

Аның энесе, 10 нчы мәхәллә мәдрәсәсе мөдәррисе Салихҗан Галиев-Баруди астрономия белән кызыксынган. Галимнең бу фән буенча фәнни-популяр китабы «Әл-гыйльмел-мансур фил-гамәли бәробгыль-дәстүр» дип атала. Әлбәттә, астрономияне ул үз шәкертләренә дә укытмый калмаган. Хәсән Туфан «Давыллы еллар лирикасы» җыентыгында болай дип яза: «Безнең авылның мулласы Хәсәнҗан Әхмәров абый («Якубия» мәдрәсәсен бетергән имам, шагыйрьгә беренче дин сабакларын биргән) безне кояш тирәсендә әйләнүче планеталар һәм Галәмнең төзелеше белән дә таныштырды».

XIX гасыр ахырларында астрономия, физика, география буенча мөдәррисләр төзегән башка дәреслекләр дә күренә башлый. Мәсәлән, шундыйлардан Ш.Күлтәсинең «Мөфассәл һәйәте җәдидә» китабы, Иж-Бубый мәдрәсәсе мөгаллиме Г.Бубыйның «Кыйраәте фәнния», «Мохтәсар җәгърәфия гомуми» дәреслекләре билгеле. Мөхәммәтзыя Бәхтияри әл-Мәмдәлинең Түнтәр мәдрәсәсендә укыган вакытта арифметика һәм астрономиядән кулъязма дәреслек язуы, аны 1898 елда Казанда бастыруы да мәгълүм[4].

«Механик Халик Садри» электрны куллану турында киң мәгълүмат биргән мәкаләләре, китаплары белән танылган. Габделхалик Садри – Хөснулла ахун Баһаветдиннең шәкерте, «Галия» мәдрәсәсен бетергәннән соң, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм уйлап табучы дәрәҗәсенә күтәрелә, фәнни-техник темаларга уннан артык хезмәт яза. Алар арасында: «Электромонтер», «Электромагнит», «Электрик һәм аның кешеләргә хезмәте», «Электрик серләре», «Динамо-машиналар һәм алмаш агымлы генераторлар» исемлеләре дә бар.

Мәдрәсә мөгаллиме Габдулла Сабир улы Ибраһимов-Шенасины да телгә алмый мөмкин түгел. Ул язган «Мохтәсар кимия» – химия буенча татар телендәге мөстәкыйль дәреслекләрнең беренчесе булып санала[5]. Галим татарча физика дәреслекләренең авторы буларак та яхшы билгеле. «Хикмәте табигыя дәреслеге» исә берничә мәртәбә басылып чыга.

Техник алгарыш татар әдәбиятына да үтеп керә. Мәҗит Гафуриның «Милләт мәхәббәте» җыентыгындагы электр фонарена багышланган шигыре – моңа дәлил:

«Нурың илә якты була бөтен кала,
Бу нурыңнан һәрбер кеше файда ала.
Утсыз яныр якты булган нәрсә булгач,
Узган халык хәйран булып күзен сала...»

Шагыйрь, бу заманның казанышларына сокланып, аларның халыкка җиңеллек китерәчәгенә ышана[6]. 1905 елда чыга башлаган «Сөембикә» журналы да техник казанышларны, шул исәптән электрны да кулланып, хатын-кыз көнкүрешен җайлау турында махсус мәкаләләр биреп бара.

Техник казанышлар дин әһелләре тарафыннан да хуплана. Татар мәгърифәтчесе, танылган дин әһеле Ризаэддин Фәхреддин электр приборлары һәм электрик эшен үзенең

[4] Ләлә Мортазина. «Шенас» – кызыксынучан акыл // Бенең мирас. – 2016. – №4.
[5] Мифтахова Н.Ш. Химия буенча татар телендәге беренче китаплар // Фәнни Татарстан. – 2005. – №3/4. – 11б.
[6] Гафури М. Электрик фонарена хитаб / Әсәрләр. 4 томда Т.1. – Казан, 1980. – Б.88.

«Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә: *«...станцада булган электрик бөтен шәһәрдәге фарларны эшләткәне кабиленнән...»* – дип яза[7]. Мәшһүр галим шул чорда: *«Дөнья елдан-ел үзгәрә, тереклек көннән-көн башкача, кичәге һөнәрләр бүгенгә ярамый, бүгенге кәсепнең иртәгәгә хаҗәте калмый. Авылларда чалгы һәм ураклар машиналар белән алышына, чалгы чүкү урынына машина йөртә белү, бозылса, төзәтә алу һөнәре кирәк була. Әгәр синең шуларга көчең җитмәсә, дөньяны һөнәрле адәмнәргә тапшырып бер тарафка кит, комачаулап йөрмә»*, – ди[8].

Казанда 1896 елда беренче даими агымлы электр станциясе ачылу энергетика үсешенә этәргеч була. 1897 елның июнендә Казан шәһәре электр белән яктыртыла башлый. Шәхси электростанцияләр ачылу инде яңалык булмый. XX гасыр башында бик күп татар гаиләләре өйләренә электр кертә. Казанда, мәсәлән, Казаковлар, Айтугановлар, Үтәмешевләр, Галикәевләр, Сагадиевләр... 1902 елда Юнысов мәчете электрлаштырыла[9]. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган шагыйрь Миргазиз Укмасый ул еллар турында болай дип язган: *«...Безнең мәдрәсәдә ул вакыт электр юк иде. Бервакыт Ф.Әмирханнар укый торган бүлмәгә барып кердем: электр чыбыгы үткән һәм лампасы куелган, ләкин ут кына җанмый, моны да эшләткән кеше Фатих Әмирхан иде. Мин моңарга зур таңлану белән карап тордым»*[10].

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте М.Галиев истәлекләренә караганда, дүртенче сыйныфта укыганда, Н.Заһитов исемле хәлфә, электр кулланып, суны кислород белән водородка «аера»[11]. Мәдрәсә гыйлеменең әлеге елларда нинди дәрәҗәгә җиткәнен күрсәтер өчен, тагын бер мисал китерик: Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең оныгы Гайшәнең хәләл җефете Габдулла Мостафин да Салихҗан хәзрәт Баруди шәкерте булган. Мәдрәсә тәмамлагач, ул атаклы Акчуриннарның Гурьевкадагы (Барыштагы, Иске Тимошкинодагы) фабрикаларында механик булып эшләгән. Абдулла Мостафин – дистәләгән рационализаторлык (уйлап табу) тәкъдиме керткән мәшһүр зат.

Казан Шәһәр Думасы XX гасыр башында, Мөхәммәтҗан Сәйдәшев җитәкләгән мөселман фракциясе йогынтысында, Иске татар бистәсен электрлаштыру турында карар кабул итә[12]. Аның этисе Әхмәтҗан Сәйдәшевнең дә мөселман кварталларын электрлаштыру, су белән тәэмин итү челтәрен үткәрү, медицина хезмәтен оештыру эшләре белән шөгыльләнүе билгеле. Алдынгы татар милләте вәкилләре узган гасыр башында электр җиһазларын төзелештә куллана башлый. Мәсәлән, 10 нчы мәхәллә мәчетен 1906 елда яңадан корганда шул эшнең хәйриячесе, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең күп кенә эшләрендә ярдәмчесе Мөхәммәдсадыйк Галикәев электр приборларын арендага ала. Казаков мәхәлләсе халкы 1914 елда губернаторга ошбу эчтәлектәге гариза биргән: *«...Сез җәнаплардан, 1 нче – Казаков мәсҗиде янына, 2 нче – Юныс Рәхимбаев йорты янына, 3 нче күпер янына электр фонаре куйдыру хакында шәһәр идарәсенә тәклифләрдә булынуларыгызны [әмер итүегезне] үтенәбез»*[13].

Татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә дә техник алгарыш киң колач җәя. 1906 елда Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе өчен өч катлы заманча электрлаштырылган бина

---

[7] Гафил бине Габдулла (Р.Фәхреддин). Әсма, яки Гамәл вә җәза. – Оренбург: Мөхәммәдфатыйх Гыйльман углы Кәримев матбагасы, 1903. – 130 б.
[8] Ризаэтдин бине Фәхретдин. Җәвамигуль-кәлим шәрхе. – Әлмәт, 2008.
[9] Моя Казань. Исторический и архитектурно-художественный очерк. – Казань, 1984. – С.48-49.
[10] Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар. 2 нче чыгарылыш. – Казан. 2016. – Б.188-189.
[11] Равиль Амирханов. «Медресе «Мухаммадия»: учебные предметы, преподаватели, выпускники» / POSREDI.RU - http://posredi.ru/medrese-muxammadiya-uchebnye-predmety-prepodavateli-vypuskniki.html
[12] Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р. Р. Республика Татарстан. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII-начало XX века). – Казань, 1994. – С.56.
[13] «Кояш» газетасы. – 1914. – №431. – 6 июнь.

Электр белән тәэмин ителгән Мәскәү урамы. XX гасыр башы

салына[14]. Хөсәеновларның Мәкәрҗә ярминкәсендәге кунакханәсе дә электр белән яктыртылган, кайбер номерларга телефон кертелгән була[15]. 1909 елда алар Эдисон фирмасыннан зур булмаган электростанция кайтарта һәм аны «Хөсәеновлар сәүдә йорты» подвалына куя[16]. Троицк купецлары Яушевлар үзләренең 4 катлы пассажлары өчен электростанция коралар һәм лифт куялар[17]. Акчуриннар үз фабрикаларында пар машиналарын, электр җиһазларын киң кулланган. 1908 елда Санкт-Петербург җәмигъ мәчетен проектлаштырганда электр белән яктырту, пар белән җылыту системасы, вентиляция булдыру күздә тотыла[18].

Электр фонарьлары Ватан сугышының 100 еллыгын һәм Романовлар идарәсенең 300 елллыгын бәйрәм иткәндә дә киң кулланыла. Казан полицмейстеры А.И.Васильев 1912 елның 17 сентябрендә Казан губерна идарәсенә: «Магометане же своим счетом иллюминировали весь левый берег озера Кабан...» – дип яза[19].

XX гасыр башында җәдитче дин әһелләре, алдынгы карашлы яшь татар интеллигенциясе, татар эшкуарларының күпчелеге европача яши. Аларның өйләрендә – телефон, электр энергиясе кертелгән, лифт куелган, рояль һәм башка музыка уен кораллары, картиналар була. Зыялылар машина һәм велосипедта бик яратып йөргән. Сәнәгать оешмалары, мәдрәсәләр дә электрлаштырыла, заманча казанышлар белән кораллана. Ә шул ук вакытта зыялыларыбызның күбесе – намаз әһеле, милләтпәрвәр шәхесләр булып, көнкүрешләрендә – затлылык, үз-үзләрен тотышында гадилек һәм тыйнаклык өстенлек иткән. ■

[14] Амирханов Р. Система конфессионального образования у татар // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье. – Казань, 2001. – С.147.
[15] Габдрафикова Л.Р. Татарское буржуазное общество: стиль жизни в эпоху перемен (вторая половина XIX - начало XX века) – Казань, 2015. – С.66-67.
[16] Оренбургские купцы / сост. М. Рахимкулова. – Оренбург, 1996. – С.17.
[17] Мусульмане города Троицка // Мир ислама. – СПб., 1913. – Т. II. – Вып. IX. – С.632.
[18] Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар. 2 нче чыгарылыш. – Казан. 2016. – Б.41.
[19] ТР МА, ф.2, оп.2, э.12810, Б.108-110.

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Муса БИГИЕВ: *«Киләчәк – исламиятнеке»*

Айдар Хәйретдинов[1]



Соңгы берничә дистә ел дәвамында булып узган тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә, XX йөз азагыннан башлап, татар дини һәм иҗтимагый фикере яңа сулыш алды, аның офыклары кинәт кенә киңәеп китте. Моның белән беррәттән, күптән онытылган шәхесләрнең рухи мирасы да өйрәнелә башлады. Үз вакытында бөтен ислам дөньясында дан казанган дин галиме Җаруллаһ углы Муса Бигиевнең (1875-1949) мирасы да – әнә шундыйлардан. Тора-бара, Муса Бигиев мирасының, шәхесенең хәзерге фәндә мәгълүм булган диниҗтимагый фикер юнәлешләренең кайсысына караган булуын ачыклау мәсьәләсе дә мәйданга чыкты. Ләкин бу эшне җиңел генә бер шәкелдә хәл итеп булмады. Моның үз сәбәпләре бар, шуларга күз салып, берәмләп барлап чыгыйк.

Муса әфәнде үзенең күп санлы хезмәтләрендә ислам шәригатенең гамәлдән чыгарылуына риза булып фикри торгынлыкта, иҗтиһадсызлыкта гомер сөргән, акылларында вә җаннарында булган иҗади көчләрне файдаланмаган дин әһелләрен, галим-голәмәне, ягъни хәзерге вакытта безнең тарафтан кадимчеләр дип аталган иҗтимагый катлам вәкилләрен кискен сурәттә тәнкыйтьләгән. Аның фикеренчә, борынгы заман голәмәсе нәкъ менә иҗтиһад иреген тыйганнан соң, Исламият, ислам дөньясы Көнбатыштан артта кала башлый, соңрак дәверләрдә исә тәмам аның колына әйләнү хурлыгына төшә, Муса әфәнденең сүзләре белән әйткәндә, *«коллык камытын үз муенына үз куллары белән тага»*. Шуңа күрә, Бигиевнең фикеренчә, тештырнаклары белән иҗтиһадка каршы торган кадимчеләр табигый сурәттә Исламиятнең дә, мөселманнарның да тәраккыятенә, үсешенә, куәтле булуларына каршы торучылар булып чыга. Шулай икән, Муса әфәндене һич тә кадимчеләр сафларына кертеп булмый.

Югарыда күрсәткәнемчә, татар дини һәм иҗтимагый фикере тарихында урын алган фикер агымнары әлегә кадәр бик гади сурәттә динне һәм яшәешне ислах кыйлуны күздә тоткан җәдитчелек белән боларны элекке хәлендә саклап калуны яклаган

---

[1] **Айдар Хәйретдинов** – ТФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

кадимчелеккә бүленеп өйрәнелә иде. Шуны истә тотканда, кадимче булмаган Муса әфәнде җәдитче булган икән, дигән нәтиҗә чыга кебек.

Олуг дин галиме буларак танып, мөселман дөньясының һәр төбәгендә дә кадер-ихтирам белән каршы ала торган булсалар да, Муса Җаруллаһның ХХ йөз кысаларына сыймаган фикерләренә һәм табышачышларына бәя бирә, аларның кадерен белә алырлык затлар ул чорда булмаган диярлек.

Әмма, Муса әфәнденең хезмәтләреннән күренгәнчә, ул үзенең һичбер фикерен, һичбер карарын, бер генә дә шәргый хөкемен дә дини ислах, ягъни динне реформалауны, үзгәртүне дәгъвалап чыгармаган: *«Һичбер мәсьәләне ... реформаторлык һаваланулы белән язмадым»*, – дип яза Муса әфәнде[2]. Киресенчә, ул исламны ислах кыйлу теләге белән саташып йөргән ислахчыларны тәнкыйть утына тоткан, җай чыккан саен үзен дини реформаторлардан аерып күрсәткән: *«Минем җанымның гыйззәтенә реформаторлык кушаматлары зиннәт-бизәк була алмый»*[3].

Әгәр Муса әфәнде җәдитчеләрнең бер тармагын тәшкил иткән дини реформаторлардан булмаган икән, бәлки ул шул ук җәдитчеләрнең башка бер тармагының вәкиледер? Миңа калса, ул җәдитчелекнең һичнинди тармагына да керми. Гомумән алганда, Муса әфәнде җәдитчелекне тәнкыйтьләгән, бу иҗтимагый фикер агымы тарафдарларын дини мәгариф эчтәлеген яхшы якка үзгәртүдән баш тартуда, җәмгыятьне бары тик көнбатышча яшәү юлына этәрүдә гаепләп чыккан булган.

Шулай итеп, Муса әфәнде Бигиевнең кадимчеләрне, дин ислахчыларын гына түгел, гомумән алганда, җәдитчеләрне дә хупламаган булуын күрдек. Болай булганда, ул дини мәгърифәтче Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗаниләр иҗтиһады белән барлыкка китерелгән, Галимҗан Барудилар, Ризаэддин Фәхреддиннәр тырышлыгы белән дәвам иттерелгән, үстерелгән дини фикер агымы вәкиле булып чыга түгелме соң? Искә алынган затларның да бит фикерләре ни кадимчелек, ни җәдитчелек калыпларына салына алмый. Муса әфәндегә кадәр иҗат иткән, яки иҗат итә башлаган байтак кына шәхесләр татар халкын ислам даирәсендә зыялы, мәгърифәтле, гыйлемле, гомумән, алга киткән бәхетле халык дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләсен хәл итү белән мәшгуль булганнар.

«Иҗтиһад булырга тиеш», – дип башлаган Курсавидан соң, алдынгы дини фикер кырында уңышлы һәм эзлекле рәвештә Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, Г.Буби, Р.Фәхреддин һәм алар кебек үк, акыл куәте белән иман көчләрен бер максатка юнәлтеп эш итүче күп кенә башка фикер ияләре булган. Болар барысы да, миңа калса, мөҗәддитләр, ягъни яңартучылар төркемен тәшкил итәләр. Алар – диннең рухына таянулы рәвештә исламның җәмгыятьтә тоткан урынын, аның рухи кыйммәтләрен яңартып, шәхес тормышын, гаилә вә җәмгыять яшәешен Аллаһ хөкемнәренә туры китерергә омтылучылар. Болар, «иҗтиһад кыйлу мөмкин һәм тиешле эштер», дигән шигарь белән коралланып, ислам диненең әлегә кадәр ачылмый калган, яки махсус рәвештә яшереп тотылган мөмкинлекләрен уятып, аларны эшкә җигеп, шуның нигездә кеше һәм җәмгыять тормышының һәр өлкәсен, һәр катламын яхшы якка таба, үсешкә таба юнәлдерергә тырышканнар.

Мөҗәддитләр исламның асыл, чын, мәңге үзгәрми торган рухи кыйммәтләрен тергезеп, динне бозган һәм аның рухын томалаган һәртөрле ялган вә уйдырмалардан арындыруны, борынгы галим-голәмәнең абруй вә дәрәҗәләренә мөкиббән китмичә, шәргый мәсьәләләрдә акыл үлчәве, пакь күңел белән эш итүне максат итеп куйган булалар.

Минем фикеремчә, Муса әфәнде әнә шундый мөҗәддитләрнең берсе булган. Ул гына

---

[2] Бигиев М. Бөек мәүзугъларда уфак фикерләр. – СПб., 1914. – Б.95

[3] Бигиев М. Мөлахәзә. Петроград, 1914. – Б.53.

Безнең мирас №10 октябрь 2018

да түгел, Муса әфәнде әлеге дини фикер агымының алга таба теоретик һәм практик үсешен, куәтләнүен тәэмин иткән, аны яңа баскычка күтәргән мөбарәк зат булып тора. Бу фикеремнең нигезсез булмавын раслап күрсәтәсем килә.

Мәгълүм булганча, гомумкешелек, ягъни бөтен кешелек дөньясына аталган булу, барлык кешеләрнең дә дөньяви һәм ахирави мәнфәгатьләрен кайгырту исламиятнең асыл иҗтимагый табигатен, аның аерылгысыз үзенчәлеген тәшкил итә. Исламиятнең максаты – ул аерым алган бер шәхесне дә, милләтне дә, күпмилләтле җәмгыятьне дә, гомумән, кешелек дөньясын да Аллаһ әмерләренә ятышлы рәвештә тормыш-көнкүреш иттерүдер. Ләкин гасырлар дәвамында исламиятнең бу мөһим максаты беренчелеген югалткан, мөселман җәмгыятьләре, явыз ниятле мәкерле бәндәләр тарафыннан алданып, адаштырылып, күпкә тар булган бөтенләй башка максатлар, омтылышлар белән яшәргә күнектерелгәннәр.

Муса әфәнде Бигиев, үзеннән элегрәк иҗат итә башлаган фикердәшләреннән аермалы буларак, беренче мәртәбә кыю сурәттә Исламиятнең әлеге асыл максатын күтәреп ала һәм иҗтимагый фикер мәйданына, бәхәс үзәгенә «ислам һәм кешелек дөньясы» дигән олы мәсьәләне чыгара. Ул болай дип язган: *«Исламият җир йөзендә гомумилеккә ирешәчәк, кешелек дөньясы Исламиятне кабул итү бәхетенә ирешәчәк... ислами халәт, әлбәттә, барлык кешеләр тарафыннан кабул ителәчәк»*[4].

Болай булганда, Муса әфәнденең иҗади мирасы, аның «киләчәк – Исламиятнеке», дигән шигаре дини яңарыш вәкилләренең иҗади-фикри алгарышларының иң югары ноктасын, табигый бер нәтиҗәсен тәшкил итә. Моны танырга кирәк. Исламиятнең асылын, Аллаһның күздә тоттыгы максатын һәм вәгъдәсен тәшкил иткән хак дин глобализмын күтәреп алган Муса Бигиевне чын мөҗәддит дип атамыйча, тагын кем дип атап була? Мөҗәддит, сүз дә юк. Әмма, Муса әфәнденең мирасы мөҗәддитлек кысаларына да сыймый.

Совет хакимияте органнары тарафыннан кулга алынганнан соң, Муса әфәнде сорау алулар дәвамында менә нинди сүзләр язган була: *«Я не дипломат, я очень убежденный исламист-мусульманин, не знаю хитрости, не привык лгать»*[5].

Галимнең ошбу сүзләреннән чыгып, аны исламчы дип атап була. Ул гына да түгел, Муса әфәнде әлеге дини-фикер агымын башлап җибәрүче, аңа исем бирүче дә булып чыга. Ислам динен киләчәктә барлык милләт вә халыкларны үз даирәсенә җыеп алачак гомумкешелек бер дин дип игълан итү белән генә чикләнмичә, Муса әфәнде бар тырышлыгын әлеге хакыйкатьне дәлилләп, аны дөнья халыкларына ирештерү өчен куйган. Шуңа күрә Муса Бигиевнең шәхес, җәмгыять, милләт һәм, гомумән, кешелек галәменә хас булган мәсьәләләрнең һәммәсен дә ислам күзлегеннән карап тикшерүе гаҗәп нәрсә булып тоелмый.

Киләчәккә карап динне алгарыш юлларына чыгарырга омтылган бу кадәр кыю фикерләре, кеше акылын чиксез галәм белән тиңләве, гомумкешелек дөньясы кадәр төшенчәләр белән эш итүе сәбәпле, Муса әфәнде гомеренең азагына кадәр ялгыз булган. Аны олуг дин галиме буларак танып, мөселман дөньясының һәр төбәгендә дә кадер-ихтирам белән каршы ала торган булсалар да, Муса Җаруллаһның XX йөз кысаларына сыймаган фикерләренә һәм табыш-ачышларына бәя бирә, аларның кадерен белә алырлык затлар ул чорда булмаган диярлек. Бу да гаҗәп түгел, чөнки XX йөз башында Көнбатыш дөньясы хакимлек иткән, ул иҗтимагый тормышның һәр өлкәсендә Исламиятне дә, башка мәдәниятләрне дә кысрыклап, җиңеп, басып килгән. Әлеге басым

---

[4] Бигиев М. Халык назарына берничә мәсьәлә. – Казан, 1912. – Б.66.
[5] ЦА ФСБ РФ. Архивно-следственное дело №Р-46032. Протокол допроса от 14.11.23.

Муса әфәнде Бигиев – татар ислам фикерен Советлар дәвере тәмугыннан коткарып калучы олуг зат.

хәзер дә дәвам итә, әмма аның никадәр куркыныч нәтиҗәләргә китерәчәге инде тәмам ачыкланды. Шуңа күрә, Көнбатыш мәдәниятенең бу авыр, үтергеч басымы дәвамлы булсын өчен, аны үткәрүчеләр үзләренә каршылык күрсәтә алырлык һәр көчкә, һәр тәгълиматка каршы көрәшәләр, аларга яла ягалар, пычрак аталар. Мәсәлән, исламчылык тәгълиматы белән дә шулай булды. Бүгенге көндә аны коточкыч бер тәгълимат, кешеләрне Урта гасырлар дәверенә тартучы бер идеология итеп күрсәтәләр. Моның шулай булуына дөньяны ышандыру өчен, аңсыз-белемсез мөселманнарны корал итеп кулланалар, аларның куллары белән кан коялар, җинаять кылалар. Кыскасы, исламчылыкның эчтәлеген һәм максатларын Муса Бигиев мирасында бәян ителгән исламчылыкның капма-каршысы итеп күрсәтергә тырышалар.

Бигиев иҗат иткән дәвердә ислам дөньясында, аерым алганда, мөселман җәмгыятьләренең югары катламнарында Көнбатышка иярү, көнбатышча яшәү шаукымы көчле булган. Муса Бигиев сүзләре белән әйткәндә, ул заман – Көнбатышның олуглыгы каршысында ислам дөньясының «күзләре камашкан» заман булган: *«Караңгы төннәрдә Көнбатыш мәдәниятенең бик кечкенә йолдызларын күрдек тә: «Ошбудыр безнең Раббыбыз!» – дип, сәҗдәгә киттек»*[6].

Мөселман дөньясының Көнбатыш мәдәниятенә шулай мөкиббән китүен Муса әфәнде, исламда борынгыдан килгән «тәкълид кыйлу» исемен йөрткән яман гадәткә охшатып, «яңа тәкълид» дип атаган. Биредә аның менә бу сүзләрен китерәсе килә: *«Дини яки иҗтимагый мәсьәләләргә багышлап бер мәкалә яки китап язу мәртәбәсенә ирешсәк, һәр сүзебез Исламиятне, шәригатьне... төзәтү, ислах кыйлу сүзләре белән бизәлгән була. Телебез – үз телебездер, баш та, бәлки, үз башыбыздыр, ләкин иҗтимагый хәлләребезгә күз салганда, күзебез – ятлар күзе була. Бу азатлык гасырында без һәрнәрсәдә ятларга иярдек... милләтебезгә гел ятларның күзе белән югарыдан карый торган булдык; Исламияткә ятларның күзе белән карап дәвалануны таләп иткән авыруларны да күрә башладык. Һәр фикеребезгә «дини ислах» исемен биреп... «чирле» Исламияткә ул сүзләребезне, ул фикерләребезне «дәва» буларак ... бирә башладык»*[7].

Шулай итеп, ислам бинасы Көнбатыш басымына чыдый алмыйча ишелеп төшәргә торган катлаулы болгавыр дәвердә Муса әфәнде Аллаһ сүзенә, Аның илаһи вәгъдәләренең хакыйкыйлыгына чын күңелдән инануын туктатмаган, динен, иманын нык хәлдә саклаган. Ислам башына килгән дәһшәтле, куркыныч олы афәтләр каршысында Муса Бигиев башкаларга ияреп, өендә бикләнеп маңгаен намазлыктан аермыйча ятмаган, киресенчә, актив эшчәнлеген үстергәннән-үстерә, киңәйткәннән-киңәйтә барган. Бер-бер артлы язылып басылып килгән һәр хезмәтендә ул ислам диненең олуглыгы, аның матур киләчәге турында, дөрес яшәүнең бары тик исламча яшәүдә генә гәүдәләнә алуы хакында сүз йөртергә курыкмаган.

Нәтиҗә буларак, мондый фикерне әйтәсем килә: Муса әфәнде Бигиев – татар ислам фикерен Советлар дәвере тәмугыннан коткарып калучы олуг зат. Галим башлаган эш, аның фикерләре бөтен дөнья буйлап сибелгән алдынгы мөселман хәрәкәтләрен тукландырып тордылар һәм торалар. Инде чират безгә дә килеп җитте. Муса әфәнде Бигиевнең мирасы, үзенең никадәр кыйммәтле булуын гына түгел, Исламиятнең дә бөеклеген барлык халыкларга танытачак. ■

[6] Бигиев М. Бөек мәүзугъларда... – Б.107.
[7] Бигиев М. Бөек мәүзугъларда... – Б.5.

Безнең мирас №10 октябрь 2018

СӘХНӘ – *аның тормыш аренасы!*

Данил Салихов әдәби иҗатка сәхнә аренасы аша килде. Хәер, татар драматургиясенә көчле авторларның байтагы сәхнә аша килгәннәр, ягъни артистлык тәҗрибәсе аларга күренекле язучылар дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм иткән. Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Габдулла Шамуков, Гамир Насрый, Риза Ишморат, Сәет Шәкүров, Хәй Вахит, Рәйсә Ишморатова, Туфан Миңнуллин, Рабит Батулла, Рәдиф Сәгъди, Юныс Сафиуллин, Гафур Каюмов – нәкъ шундыйлар. Шулар арасында драматург, бер үк вакытта прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе дә булган Данил Салихов татар театр сәнгатендә лаеклы урын алып тора.

Дөрес, татар драматургларының аерым бер зур катламы әдәби иҗатка театр сәхнәсеннән түгел, ә халкыбызның иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнашып, әдәбиятыбызның башка жанрлары аша килгәннәр. Әйтик, Мирхәйдәр Фәйзи, Фатих Әмирхан, Юныс Әминов, Шамил Шәһгали кебек драматурглар сәхнә әсәрләрен театр белгечләре буларак иҗат итәләр. Әдәбиятыбызның проза жанры аша драматургиягә Шәриф Камал, Шамил Усманов, Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов, Диас Вәлиев, Фоат Садриев, Әхәт Гаффар килә. Поэзия жанры Һади Такташ, Гадел Кутуй, Илдар Юзиев, Рөстәм Мингалим, Разил Вәлиев, Зөлфәт Хәкимнәрнең драма әсәрләрен сәхнәгә менгерә. Ә менә күренекле галимебез, фольклорчы, шагыйрь Нәкый Исәнбәт сәхнә әсәрләрен, нигездә, татар халык иҗаты, фольклорга таянып иҗат итә. Язучыларыбызның Ризван Хәмид, Мансур Гыйләҗев кебек бер өлеше әдәби иҗатларын турыдан-туры драматурглар булып башлап җибәрәләр.

Әлбәттә, драматургларыбызның әдәби иҗатын шушы рәвештә төркемләп карау күпмедер дәрәҗәдә символик бүленештер дә, әмма монда шактый гына хаклык та бар, дип уйлыйм. Бу урында шунысын да әйтеп китәргә кирәк –Данил Салиховның драматургия жанрындагы иҗатын теге яки бу дәрәҗәдәге әлеге бүленешнең һәрберсенә дә диярлек кертеп була. Беренчедән, ул – әдәби иҗат эшенә сәхнә аша килгән шәхес, икенчедән, Данил Салихов бүгенге көндә шактый тәҗрибәле прозаик та: аның «Казан утлары» журналында басылган (2016 елның 11-12 нче саннарында) «Чукрак» исемле романы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителүе шул хакта сөйли. Шунысы да бар, күренекле татар язучысы Аяз Гыйләҗев, Данил Салиховның «Чукрак» дигән әсәре буенча куелган спектакльне карагач, авторга: «Чукрак» – әзер роман, аны киләчәктә үзгәртеп язарсың әле»,– дип киңәш биргән булган. Роман басылып чыккач, Аяз Гыйләҗевнең бу гөманы расланды.

Данил Салихов – публицистика жанрында да актив эшләүче әдип.



Данил Салихов Кәрим Тинчурин исемендәге театрда Туфан Миңнуллинның «Гармун уйный беләсеңме?» әсәре буенча куелган спектакльдә Наил ролендә

***

Шулай да, әйткәнебезчә, Данил Салихов драматургия жанрына, нигездә, театр сәхнәсе аша килгән язучы. Аның язучылыкка илткән иҗат юлы Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры һәм Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәләрендә куелган спектакльләрдә уйнаган артист буларак башланып китә. Бу сәхнәләрдә ул татар, рус, чит ил драматурглары һәм үз әсәрләрендәге егермеләп рольне башкаручы булып таныла.

Шушы чордан соң инде аның бөтен гомере Татарстанның, Башкортстанның, Россия Федерациясендәге башка рус һәм милли театрларның иҗади тормышына тыгыз бәйләнештә дәвам итә.

Шулай итеп, театр сәхнәсе Данил Салиховны олуг әдәбиятка, драматургиягә, язучылык иҗатына алып чыга – ул теше-тырнагы белән үҗәтләнеп (һәм, әлбәттә, үзенең әдәбиятка сәләтлелегенә нигезләнеп) сәхнә әсәрләре иҗат итә башлый. 1988 елда инде тәҗрибәле актерның һәм яшь драматургның «Туй күлмәге – соңгы бүләгем» дигән әсәре Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсенә менә.

Бүгенге көндә Данил Салихов – Россиянең 11 дәүләт театры сәхнәләрендә 38

Чыңгыз Айтматов укуларында. Кыргызстан, 2017 ел

Данил Салихов күренекле театр белгече Рәүф Игъламовны искә алу кичәсендә чыгыш ясый

спекталь куйдырган тәҗрибәле драматург. Бу урында шунысын да ассызыклап үтәсе килә: Россиядәге төрле дәрәҗәдәге дәүләт театрларында әсәрләрен сәхнәләштергән драматург беркайчан да үзенең туган Актанышындагы үзешчән драма коллективлары белән иҗади бәйләнешен туктатмый. Әйтик, 2004 елдан алып 2012 елга кадәр генә дә Актаныш районының утыздан артык үзешчән театры сәхнәләрендә аның 65 әсәре куела. Һәм аларның сәхнәдә уйналуы инде йөзләрчә, ә бәлки меңнәрчә мәртәбәдер.

***

Әмма Данил Салихов дигән ир-егет, чып-чынлап театр һәм әдәби иҗат дөньясына кереп киткәнче, шактый бай биографик тәҗрибә туплый.

Ул 1958 елның 7 октябрендә Татарстанның көнчыгышындагы Актаныш районында дөньяга килә. Актаныш ягы республикабызның татар милләтенә иң хас булган, халкыбызның тарихи традицияләрен бүгенге көнгә кадәр саклап килүче төбәкләрнең берсе. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевне Аллаһы Тәгалә һәм табигать юкка гына Актанышта тудырмагандыр. Безнең язучылар, аның эшчәнлеге хакында сүз чыкканда, Минтимер Шәймиев президентлык иткән елларны «Татар хал-

Төрле илләрдән җыелган каләмдәшләр белән. Әзәрбайҗан

«Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелү турында таныклык алган көн. Татарстан Президенты Сарае. 2000 ел

кы тарихының алтын чоры» дип бәялиләр. Данил Салиховның кендек каны Актаныш төбәгенең әнә шундый иҗтимагый һәм уңдырышлы туфрагына тама!

Территориаль яктан төгәлрәк әйтсәк, Данил Актаныш районының Киров исемендәге совхоз бистәсендә дөньяга аваз сала. Шул авылда чын татар моңнары, татар рухында тәрбияләнеп, шунда урта белем алган Данил Салихов 1976 елда, ягъни 17 яшендә, күңеленә җыр-музыка корты кереп өлгергән егет буларак, Казан музыка училищесының вокал бүлегенә укырга керә. Тик туган авылында һәм районгдагы үзешчән сәнгать түгәрәкләре аша җанына сеңгән театр дөньясы егетне үзенә тарта һәм ул 1979 елда Казан театр училищесына күчә. Данил анда киләчәктә күренекле сәхнә әһелләре булачак яшь артистлар, шул исәптән Галиәсгар Камал театрының бүгенге баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев белән бергә укый.

Училищены тәмалагач ук, 1983 елдан Камал театрында актер булып эшли башлый, ә 1985-91 елларда – Тинчурин театры актеры.

1992-95 елларда ул «Салават күпере» журналының баш мөхәррир урынбасары булып эшләде.

1966-2006 елларда, инде Татарстанда һәм Россиядә билгеле язучы булып өлгергәч, Данил Салихов Россия әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры вазыйфаларын башкарды. Бу елларда ул СССР һәм РСФСР Язучылар берлекләренең әдәби фондлары эшчәнлегенә якыннан катнашты, татар язучыларының көнкүреш һәм финанс хәлләрен яхшыртуда зур эшчәнлек күрсәтте.

2003-2008 елларда исә Данил Салихов Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген җитәкли. Яңадан Казанга кайткач, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшли.

Бүгенге көндә ул – Татарстан Язучылар берлеге рәисе.

Күрәмсез, аның бөтен хезмәт юлы Россиядәге дәүләт театрлары һәм Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлеге, аларның иҗади тормышы белән бәйләнгән.

***

Татар театры үзенең тарихы белән Россиядәге иң бай милли сәхнә сәнгатеннән санала. Ә театры бай булган халыкның драматургия жанры да бай була. Тарихи татар театры үзенең сәнгати сыйфаты белән дә бик бай. Шуңа күрә яңа, үзенчәлекле пьеса

Хатыны Рәмзия ханым белән

иҗат итү өчен, татар драматургыннан гаять зур интелектуаль көч сорала. Бүгенге сәхнә татар авторыннан яңадан-яңа алымнар, үзенчәлекләр, кабатланмас сюжетлар көтә. Драматург һәр әсәрендә яңадан-яңа ачышлар ясарга тиеш. Сәхнә, тамашачылар, режиссерлар көн дә шуны сорый, шуны таләп итә. Бүгенге үзенчәлекле сәхнәгә яңалык алып килүче драматург гаять тә җаваплы каләм иясе ул. Ярый әле театр тамашасының иҗади алымнары чиксез төрле. Шуңа күрә дә һәр драматургның үзенә генә хас иҗади йөзе, иҗади юлы була. Әйтик, бер драматург тирән фәлсәфи чараларны алга сөрә, ә икенчесе юмор-сатира белән алдыра, кайберәүләр мелодрама төрен алга этәрә, тирән лирик драматурглар, әкияти-фантастик пьеса язучылар да бар. Ә менә мин Данил Салиховны театраль сюжет остасы дип санар идем. Ул драматургиядә бөтенләй көтелмәгән сюжетлар иҗат итәргә маһир. Үзе әйтергә теләгән вакыйгаларны автор шундый көтелмәгән борылышлар белән баета ки, күп вакытта тамашачы мондый кинәтлектән гаҗәпкә кала, аерым мизансценаларда, үзе дә сизмәстән, гөрләтеп кул чаба башлый.

Мондый көтелмәгән, ләкин бик тә театраль сюжет борылышлары Данил Салиховның бөтен драматургиясендә кызыл җеп булып сузылып бара. Шундый спектакльне авторын әйтмичә генә куйсаң да, тамашачы, бу бит Данил Салиховныкы, дип кычкырачак. Сюжетның көтелмәгән борылышларга бай булуы Данил Салиховның бары тик үзенә генә хас булган драматургик алымы, иҗатының яңалыгы булып тора.

Әлбәттә, «Безнең мирас» кебек олпат журнал өчен язылган бер мәкаләдә генә тәҗрибәле драматургның бөтен иҗади үзенчәлекләренә, гомум иҗатына тулаем бәя биреп бетереп булмый. Ләкин мин замандашым, иҗади хыялларыбыз һәм иҗади мөмкинлекләребез уртак булган, меңьеллык язма әдәбиятыбызда бер чорда яшәп иҗат иткән каләмдәшем Данил Салихов шәхесенә һәм иҗатына үземнең тыйнак кына бәямне биреп калдыруыма канәгать булып калам.

Шунысы хак: сәхнә – аның бөтен тормыш аренасы!

Гәрәй Рәхим,

Татарстанның халык язучысы ■

Фоторәсемнәр Данил Салиховның шәхси архивыннан һәм «Кәрәз-клуб» тупланмасыннан алынды.

Редакциядән:

Мөхтәрәм каләмдәшебезне күркәм юбилее белән ихластан котлыйбыз! Аңа сәламәтлек, иминлек, тамашачы һәм укучыларын киләчәктә дә яңа әсәрләре белән сөендерүен телибез.

Эмил ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ:
«Яшьлеккә? Юк! Кире кайтмас идем...»

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль ага Җәләлетдиновка быел җәй 85 яшь тулды. Җитди юбилей. Йорты белән Татар дәүләт филармониясе арасын велосипедта җилдереп узган, гәүдәсен әлегәчә шәм кебек төз тоткан, җырлаганда тавышы һаман гөбердәп чыккан, Тукайның барлык әсәрләрен яттан белгән һәм, кирәк чакта, төрле сорауларга шагыйрь сүзләре белән җавап кайтара алган елгыр ир-ат өчен туры килеп бетми кебек бу яшь. Әйтерсең егермеләп елга арттырып язганнар. Соңгы елны тырышып роликларда йөрергә өйрәнүен дә исәпкә алсаң, бу сан каршында бөтенләй дә аптырап каласың.

Эмиль Җәләлетдинов буыны җырчылары – күз өстендәге каш, сайланган асылташ, берсен-берсе тамчы да кабатламаган, күптиражланып бәһаләрен җуймаган чын сәнгать осталары алар. Зәвык, интеллект, зирәклек, мәгънә аларда. Мактаулы исем-дәрәҗәләре чын сәнгать, «тере» иҗат өчен бирелгән.

Язмабызның затлы герое Эмиль Җәләлетдиновның күңелендә ниләр бар? Борчулары булса, сәбәпләре нинди? Шатлыкларын кем белән бүлешә ул? Гаме нидә, «их, моны эшлисе иде» дип корып куйган планы бармы?

Зимфира Гыйльметдинова

ШАТЛЫКЛАР

«Иң зур шатлыгым – музыка өлкәсендә булуым, сәнгатькә хезмәт итүем. Әгәр мин сәхнәдә, музыкада булмасам, белмим, ничек яшәр идем. Үз хезмәтеңдә булу, яраткан эшеңне эшләү – аннан да зур шатлык була да алмый. Дәүләт минем хезмәтемә, иҗатыма югары бәя бирде. Бу да шатлык. Эшләгән вакытта күп илләрне күрдем, бөтен Советлар Союзын йөреп чыктым, меңләгән тамашачы, минем җырыма җавап итеп, үзенең алкышларын бүләк итте. Бу шатлык та – сәнгать кешеләренә генә тия торган шатлык бит. Тукай иҗаты белән якыннан «аралаштым», күпме классик композиторлар, шагыйрьләр, музыкантлар белән очраштым. Бәһасез аралашулар иде алар! Тагын бер зур шатлыгым – һаман да филармониядән аерылмый яшим. Анда мине: «О, Эмиль абый!» –дип шатланып каршы алалар, кичәләргә, концертларга чакыралар. Сәхнәдән әле дә аерылмыйм».

ҮКЕНЕЧЛӘР

«Балаларым тәрбиясендә аз катнаштым, чөнки чын күңелдән, бар булышым белән иҗатка, хезмәтемә бирелгән идем. Инде хәзер балаларымның үз балалары да үсеп, алар да оныклар тәрбияләр яшькә җиткәч, шул хакта уйланам да – күңелемне борчу, үкенеч били. Быелгы җәй гаиләмә зур кайгы алып килде. Бердәнбер кызым 40 яше туларга бер көн кала вафат булды, ике яше дә тулмаган кечкенә баласы ятим калды. Балаңны югалткач, үкенечләр тагы да көчәя икән...

Репертуарым бик зур, үзем язган җырлар да, классик авторлар әсәрләре дә... Ләкин аларны халыкка җиткерү хәзер авыррак. Концертлар күп түгел, ә һәр көн, һәр сәгать җырлыйсы килә.



Эмиль Җәләлетдинов телестудиядә Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге ансамбль белән чыгыш ясый. Саксофонда – Рөстәм Үтәй. 1965 ел

Эмиль Җәләлетдинов. 1971 ел

Консерватория тәмамлагач, Мәскәүдә калу мөмкинлегем бар иде. Ләкин мин Казанга килдем, биредә мине яхшы кабул иттеләр, юллар һәрчак ачык булды. Кайчак, «Мәскәүдә калсам, масштаб башка булыр иде», – дип уйлап куям. Бу үкенеч тә түгел инде, бары уйлану гына. Ләкин Казанга килгәнемә, юк, һич кенә дә үкенмим».

ДУСЛАР

«Мин, дуслык эшләгәндә туа, дигән фикердә. Җырчылар, концертмейстерлар белән дуслашасың. Ул иҗади дуслык була инде.Тормыш юлымда серемне сөйләгән, һәрчак ярдәмгә атлыгып торган дусларым булмады. Студент чагымда якын дустым бар иде. Дуслыгыбыз хакына, улы тугач, аңа хәтта Эмиль дип исем кушты. Кызганыч, ул дустым мәрхүм инде.

Кешеләр белән һәрчак яхшы мөгамәләдә булдым, сүзгә килмәдем, ямьсез сүзләр сөйләмәдем. Үзем белән эшләгән коллегаларымны хөрмәт итә идем. Ләкин алар минем якын дусларым булмадылар, юк. Якын дус ул – аерым. Ул бер генә була. Ярдәм сорап та кешеләргә бик сирәк мөрәҗәгать итәм, үзем җиңә торган проблеманы кешеләр

Эмиль Җәләлетдинов

Россия Композиторлар берлегендә. Назнинә Сабитовская, Рөстәм Яхин, Эмиль Җәләлетдинов, Алмаз Монасыйпов. Мәскәү. 1970 нче еллар

Эмиль Җәләлетдинов, Венера Шәрипова, Гөлшат Зәйнашева, Әлфия Авзалова, Заһид Хәбибуллин, Ирек Галимов. Уфа.1973 ел

җилкәсенә салмыйм. Сорау өчен, горурлыкны җиңү кирәк бит. Ярдәм сораганмын икән инде, димәк, үземнең генә көчем җитми».

НИЧЕК ЯРАМЫЙ

«Әгәр кемгә дә булса зыян салмый икән, ялганны да кабул итеп була. Кешеләргә зыян салган ялган – ярамый. Үз амбицияләрең өчен кешеләр башына «басып» яшәү

Татар филармониясе сәхнәсендә

Филармония бакчасында Эмиль Җәләлетдиновның истәлекле чыршысын утыртканда. 30 сентябрь, 2016 ел

Филармония бакчасында. Июль, 2018 ел

дә – катгый тыелган нәрсә. Үзем белән эшләгән кешеләрнең, минем хакта начар сүзләр сөйләп, миңа зыян салырга теләгәне булды. Кешеләр күңелен рәнҗетерлек гамәлләр кылырга ярамый».

ХӘТЕР

«Әти-әинемне еш искә алам. Әнием гаҗәеп чибәр ханым иде. Табибә. Бөтен көчен өч баланы тәрбияләүгә сарыф итте. Әтием агроном иде, ләкин гомере буе җырчы булырга хыялланды, берчак хәтта Казанга да барды. Гаиләне күбрәк әни карады, әти эштә, коммунист, күбрәк шунда иде».

КАМИЛМЕ?

«Хәзер капитализмда яшибез. Элек киләчәк хакында уйламый, кайгырмый яшәп була иде. Фатир кайгысы юк, эш күп булды. Кешеләр законнарны үтиләр иде. Хәзер – юк. Бу чор бик үк камил түгел».

ТЕЛӘК

«Яшьлеккә кире кайтумы? Ул бит мөмкин хәл түгел. Юк, кайтмас идем. Тормыш үз агымы белән ага. Исән-сау, әле җырлыйм. Шуннан да күбрәк ни сорыйсың тагын?! Хәер, күбрәк җырлыйсы иде. Иң көчле теләгем шул!»

ГОРУРЛЫК

«Иҗатымны халыкның яхшы кабул итүе, әле хәзер дә урамда очраган кешеләрнең: «Бик яратабыз Сезне!» – диюләре – минем өчен горурлык». ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



МОНГОЛИЯ

Бурятлар – монгол кавеменә караган кабиләләрнең берсе, яшәгән җирләре – Монголиянең бер чите, ләкин гаять мәшһүр төбәге. Моннан Тибетка кадәр өч айлык юл булса да, Урга шәһәреннән Тибетка елда ике тапкыр кәрван барып кайта. Кәрван юлы олы юл булып тора. Монголиянең һәр тарафыннан, көнчыгышыннан, көнбатышыннан, төньягыннан килеп Цинанфуда җыелалар, аннары Лобнор күленең көнбатышыннан Тибетка таба юл алалар. Бу кәрван бик мәшһүр, болар Будда диненең кыйбласы булып саналган Лас, яки Әлхамис җиренә барып кайталар. Ул җир Будда динендә изге җир булып санала.

Бөтен Монголиядә бу кәрван да изге дип санала һәм шул сәбәпле, Тибет кичүләрендә, Һималай мәгарәләрендә яшәүче юлбасарлар да әлеге кәрванга һөҗүм итмиләр. Тибетка ышанычлы юлдан, исән-сау барып кайтырга теләүчеләр бу кәрванны айлар буе көтәләр. Кәрван,

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.
[1] Урга – монгол телендә «сарай» дигәнне аңлата, 1924 елда Монголия Халык Җөмһүрияте төзелгәннән соң, бу шәһәрнең атамасы Улан-Батор итеп үзгәртелә (тәрҗ. иск.).

күбесенчә, елга ике тапкыр бу юлны үтә, кайбер елларда бары бер тапкыр гына барып кайта.

Мин хәзергә буддизм белән бәйле бу кадәр мәгълүмат бирү белән чикләнәм, ләкин шуның белән бергә, алга таба кабат әлеге хакта сүз алып барырга тиеш булачагымны да әйтеп үтәсем килә. Ник дисәгез, биредә искә алынган буддизм, Монголия буддизмы кебек үк, төп Будда диненең бер тармагы булып тора. Буддизм тармакларының күп булуы турында Хамба Ламадан ишетеп белгән идек инде. Бары тик Япониядә генә дә 35 тармагы бар, Кытайда тагын да күбрәк. Боларның һәрберсе турында җае килгән саен сүз алып бару гаять табигый булыр, дип уйлыйм.

ВЕРХНЕУДИН

Бурятлар арасында бераз йөргәннән соң, кабат Верхнеудин(ск) шәһәренә кайттым. Кәшшафулла әфәнде һәм кардәшләренең өенә кунак булып төштем. Бераз ял итеп алганнан соң, шәһәрчекне карарга чыктым. Башта туры мәчеткә бардым: кечкенә генә мәчет, манарасы-фәләне юк. Аннан мәдрәсәгә юл тоттым. Мәдрәсә дә гаять кечкенә, гаять аяныч, ләкин андагы берничә генә мөселман баласына булса да Ислам диненең нигез кагыйдәләрен өйрәтүе белән гаять бөек һәм горурланырлык мәктәп булып тора.

РУСИЯДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮЛӘР

Мин Верхнеудин мәктәбендә балаларның белемен тикшерү белән мәшгуль идем, шулвакыт ишектән рус киемнәре кигән бер кеше килеп керде, сәлам бирде, ике куллап күрештек. Аның тәрбияле, фикерле кеше булуы йөзеннән үк күренеп тора иде. Кем булуы, кайдан килгәнлеге турында соравыма болай дип җавап бирде:

– Мин – тумышым белән Харьковтан, чыгышым буенча – яһүди. Ләкин бүгенге көндә, әлхәмделилләһи, Ислам диненә килеп шәрәфле булдым.

– Ислам динен кабул итүегезнең сәбәбе ни? XX гасырда дингә битараф булу модага әйләнде. Бигрәк тә Сезнең кебек яшь кешеләр арасында.

– Гафу итәсез, мин инде бик яшь кеше түгел, нишләгәнемне беләм, файда һәм мәнфәгатьләремне аңлый алачак кадәр генә акыл көчем дә бар. Мин Сездән берни дә өмет итеп килмәдем. Шулай да бер гозерем бар, ул да Ислам дине белән бәйле. Мин Ислам динен кабул итеп шәрәфле булдым, Аллаһка хәмед булсын, кәлимә-и тәүхидне [лә иләһы иләллаһ] мәгънәсе белән беләм, ләкин, ни кызганыч, төрки телне белмим. Бүген миңа полиция идарәсенә чакыру килде, хәзер шунда барам, губернадан рәсми кәгазьләрем килгән дә шуның өчен чакырганнардыр, дип уйлыйм.

– Алай булса, тәбрик итәм, бу Сезгә Аллаһ тарафыннан һидаять, ягъни тугры юлны табу, бу – бик зур нигъмәт. Мин бик шат.

Бик гаҗәпләндем: мәгълүматлы, белемле бер яшь кеше Себернең иң читендә ни дип Ислам динен кабул иткән? Бик аптырап уйга талган идем, ул арада янымa килгән Кәшшафулла әфәнде болай диде:

– Моннан ике атна элек бер кеше бөтен гаиләсе белән мөселманлыкка күчте. Ике атналап бар инде, әйе, алар да рәсми кәгазьләрен алдылар. Ул кеше бик бай. Бүген Сезнең белән күрешергә киләчәк. Сез Дасанга киткәч, берничә тапкыр килде, Сезне сорады.

– Синең хикмәтләрең турында сорау бирелми, йә Раббым, – дидем.

Томск шәһәрендә ахун Хәмзә Хәмидов җәнаплары сөйләгән иде: бу рамазан аенда ике-өч студент килеп, Ислам динен кабул итәргә теләүләрен әйтеп, диннең нигезләрен өйрәтүен үтенгәннәр. Тик Хәмзә ахун, русларның ачуыннан куркып, яшьләргә дәрес бирергә риза булмаган.

Кәшшафулла әфәнде:

– Безнең Чита шәһәрендә соңгы ва-

кытларда бик күп кеше мөселман булды. Әле менә бу көннәрдә генә дә бер инженер гаризасын бирде, рәсми кәгазьләре генә әлегә килеп җитмәде, – диде.

Боларны ишетеп, гаҗәпкә калмау мөмкин түгел. Бу соңгы биш ел эчендә Русиянең эчке төбәкләрендә 86000 кешенең рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүе турында Уфада Гыйниятулла казыйдан ишеткән идем.

Очрашуга килгән яшь кеше миңа болай диде:

– Әфәндем, мин намаз укуны әлегә өйрәнә алмадым. Минем өчен намаз кайчаннан фарыз? Сезгә бу турыда сорарга дип килгән идем. Миңа шуларны аңлатып бирсәгезче. Бу көннәрдә намазны өйрәнәм. (Шулвакыт кереп, аның артында торган студентларны күрсәтеп, әйтте). Болар – минем дусларым.

– Син кайчан: *«Лә иляһы иләллаһ»,* дидең (мин моны әйткәндә, *Мөхәммәдән рәсулуллаһ,* дип өстәде), шул вакыттан башлап, намаз сиңа фарыз. Тик кайчан өйрәнә алсагыз, шулвакыт укый башларсыз.

Кыскасы, мин биредә Исламга күчкән кешеләр белән күрештем, үзләрен шактый гына өйрәттем. Һәммәсендә дә ихласлык һәм җитдилек күрдем. Чита шәһәрендә мөселманлыкка күчкән теге инженерның нәтиҗәдә кулга алынуын, басым ясалып, шактый азап чигүен дә ишеттем. Бик нык шаулаган, кычкырган, хөкүмәт түрәләренә тәслиснең – христианлыктагы өчлек төшенчәсенең – буш һәм ясалма булуын, ә тәүхиднең – Аллаһның берлегенең – хак булуын исбатларга маташкан, соңында мөселманлыгын раслаган рәсми кәгазен кулына тоттырып, моннан котылганнар. Вакытлар үткәч, Чита шәһәрендә бу кешене мин үзем дә күрдем, гаять мәгълүматлы, гаҗәеп кеше иде. Сөйләшеп утырганда, миңа болай диде:

– Мөселманлыкны кабул итүем белән үземне беркемгә дә бурычлы дип санамыйм, ләкин бу шәрәфкә ирешүемә бик канәгать һәм шат булуымны һәрвакыт, һәр җирдә горурланып сөйлим. Кулга алынганнан соң, төрмә миңа җәннәт булды. Кальбем һидаять (тугры юлга басу) нуры белән яктыртканнан соң, бөтен җиһан каршы килсә дә, мине юлымнан кире бора алмас. Мин мөселманлыгымны яшерә алмыйм...

Мондый хәлләрне күреп, мондый сүзләрне ишеткән саен, безнең арабыздагы, инде күптәннән инанган мөселман булуларын икърар итеп тә, Исламиятне даими рәвештә тәнкыйть итү белән шөгыльләнүче кайбер кешеләргә карап шаккатмыйча мөмкинме соң?!

БАЙКАЛ ДИҢГЕЗЕ

Моннан 20-30 еллар элек Байкал диңгезе гаять мәшһүр һәм зур диңгез иде. Байкал диңгезендә каекларда һәм көймәләрдә йөзгәндә, һәр ел берничә кеше батып үлә, кыш көннәрендә боз өстеннән җигүле атлар белән үткәндә, бик күп кеше һәм хайван боз астына китеп үлә торган иде. Ул вакытларда Байкал диңгезе чынлап та куркыныч иде. Бигрәк тә кыш көннәрендә, боз өстеннән юл йөргән очракта, һава суык, тирә-юньне томан баскан була, көнбатыш кайда да, көнчыгыш кайда – билгеле булмый. Карлы бураннар да башланса, кешеләр бөтенләй дә юлны югалта, атналар буе боз өстендә адашып йөри иде. Барып сыенырлык урын юк, хайваннар өчен хәзерләнгән азык җитәрлек булса, бик яхшы, булмаса, бөтенесе бергә һәлак булалар. Байкал диңгезендә шул рәвешле юлларын югалтып боз өстендә гомерләре өзелгәннәр һәр ел булып торды. 60 чакрым арада юлны таба алмыйча атналар буе адашып йөргәннән соң, юл табып, ярга, җиргә чыгып баса алучылар үзләрен чиксез бәхетле тоя торган булганнар. Шулай булса да, Кяхта юлында кәрван

---

[2] Мил – якынча 1,6 км га тигез булган ераклык үлчәү берәмлеге (тәрҗ. иск.)

йөрми тормый, һәр ел берничә тапкыр барып кайтучылар була торган иде.

Бераздан Байкалда пароходлар йөри башлады. Күп тә үтмәде, бозваткыч пароход чыкты. Кайбер елларда декабрь ахырларына кадәр бозваткыч белән Байкал диңгезен үтеп-сүтеп йөрергә мөмкин иде. Бу пароход бозны вата һәм бер үк вакытта сәгатенә 10 мил юл үтә иде. Шул рәвешле, Байкал диңгезе аша барып кайталар иде. Бозның калынлыгы 1,5 аршын булганга кадәр пароход йөри ала, боз тагын да калынайгач, бозваткыч та үтә алмаслык була. Моннан соң тагын икеөч ай буе кешеләр элекке кыенлыкларга түзәргә мәҗбүр калалар иде.

Кем белсен, бу күл эчендә елда никадәр җан иясе, никадәр кеше гомерен югалта. Рус-Япон сугышында да Байкал диңгезендә меңләгән сугышчы һәлак булды.

Ләкин бу сугыш вакытында руслар зур тырышлык куеп, бөтен көчләрен җигеп, Байкал диңгезе буендагы тауларны тишеп, 244 чакрым арада нәкъ 46 туннель ясадылар, шул рәвешле тимер юлны төзеп, бу кадәр кешене әлеге зур кыенлыклардан коткардылар. Инде хәзер берәү дә кыенлык күрми, юл бер төн эчендә үтелә. Элекке заманнарда атналар-айлар буе үз эчендә әйләндереп йөрткән ул куркыныч Байкал диңгезенең инде ярларын да күрү насыйп булмый, төн караңгылыгында үтеп кителә.

ЧИТА

Никадәр генә кечкенә шәһәрчек булса да, Чита – Себернең иң читендә урнашкан булуы белән бик әһәмиятле. Биредә яшәүче мөселманнарның саны бик аз, аларның да бер өлеше каторжаннар нәселе. Биредә тагын да шул ук каторжаннарның тырышлыгы белән төзелгән бер мәчет бар. Бу мәчетне нәфис сәнгать әсәре үрнәге дип атарга мөмкин. Шулкадәр матур бина ки, Себернең чите булган Чита шәһәрчегендә түгел, хәтта Казан кебек Ислам үзәге булган зур шәһәрдә торган булса да, күренеше белән игътибарны җәлеп итәр иде. Бу мәчетнең аскы катында бер матур мәктәпләре дә бар. Биредә иллеләп балага белем һәм тәрбия бирелә, Ислам диненең нигезләре өйрәтелә. Себернең иң читендә мондый мәктәп булу белән никадәр горурлансалар да урынлы. Бу шәһәрчектә русларның да әллә ни артык берниләре дә юк. Бары тик биредә солдат казармалары урнашканга, гаскәриләрнең бер клублары һәм төз атуны өйрәтә торган бер мәктәпләре генә бар.

Мин Читада ике көн кунак булдым, мөселманнар белән күрештем, берничә тапкыр вәгазь сөйләдем. Мәчеткә кушылып ук салынган бер йорт бар һәм анда бер карт яши. Кайчандыр каторжан булган бу кеше, билгеләнгән сөрген вакыты тулганнан соң, монда яшәп калган. Мал тапкан, бераз баеганнан соң, башка мөселманнарның да ярдәме белән биредә бу матур мәчет бинасын салдыруга ирешкән. Бик мөлаем карт. Аның белән күрешергә өенә баргач, миңа: «Безгә бирегә бер йөз ел элегрәк килергә кирәк булган. Патшалык игълан итәргә дә көчебез җиткән булыр иде», – диде. Картның бу сүзләрен бик ошаттым, хәтта бүгенге көнгә кадәр исемнән чыкмаган һәм шуңа күрә биредә язып та куярга уйладым. Әлеге сүзләрне бөек сүзләр дип әйтеп булмаса да, укый-яза белми торган каторжан тарафыннан бераз күпертелеп әйтелгән булсалар да, болар кыйммәтле сүзләр иде.

Читадан кузгалып киттем. Бу җирләр – инде Русия мәмләкәте булган бөек Себернең чиге. Биредән Карымск дигән җиргә килдем. Карымскида төп Русия Амур тимер юлы аерылып китә. Биредә туктап тормыйча, Манчжуригә таба юлыбызны дәвам иттек.

Дәвамы бар

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

НУРИХАН ФӘТТАХНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ!

ҮЗЕМ ГЕНӘ ТҮГЕЛ *

Нурихан Фәттах

Иң беренче шигыремне мин өченче класста укыганда яздым. Кыш көне иде. Дәрестән соң елга аръягында, чыршылыкта чаңгы шуып, туңып-ачыгып кайттым да күңелне биләгән шатлыклы тәэсирләрне кәгазьгә төшермәкче булдым.

Шигырьне мин «Кыш» дип атадым һәм Яңавыл районында чыга торган «Октябрь юлы» газетасына җибәрдем. «Шигырь»не, билгеле, басмадылар. Авторга хат-фәлән дә килмәде бугай. Шулай да Яңавылда редакциядә гарип куллы бер абый каршысында нидер тыңлап утырганым хәтердә калган.

Яңавылда бишенче класста укыганда, инде мин кыш турында гына түгел, җәй, көз, яз турында да шигырьләр яза башладым. Кичләрен өстәл почмагына, пыскый (сукыр лампа) каршысына утырам да бармак белән иҗек саный-саный сүзләр чүплим. 1940 елны, ахрысы, «Яшь ленинчы»да минем өч-дүрт юллык хәбәрем басылды. Ул чактагы куанычны хәзер инде сөйләп торуның кирәге юк дип уйлыйм. Тик шунысын әйтмичә мөмкин түгел: бөтен мәктәптә бу үзенә күрә бер вакыйга булды. Олы тәнәфестә бик күп укучыларны линейкага җыеп, завуч Баямый Мөслимов абый мәкаләне кычкырып укып чыкты.

Минем түбә күккә тиде. Ничектер бер җаен табып, кыюланып, мин Баямый абыйга моңарчы беркемгә күрсәтмәгән шигырь дәфтәремне бирдем. Мөслимов абый олы классларда татар әдәбияты укыта иде. Әдәбият мәсьәләсендә ул, күрәсең, иң зур авторитет булган. Шигырьләрне укып чыккач, ул минем белән сөйләшеп утырды, киңәшләр бирде. Шуннан башка берни хәтерләмим. Ләкин шунысы истә: Баямый абый кара чәчле, ягымлы, чибәр һәм шат күңелле кеше иде. Укучылар да, укытучылар да аны бик яраталар иде.

Сугышның беренче көннәреннән үк диярлек Мөслимов абый, башка яшь укытучылар белән бергә, үзе теләп фронтка китте.

1941 елның көзге шомлы көннәрендә аларның төркем-төркем булып Яңавыл читендә марш атлап йөрүләре әле булса күз алдымда тора. Баямый абый да, башкалар да киткән җирләреннән кире кайтмадылар. Авыр туфраклары җиңел булсын. Беренче тәнкыйтьчемә, беренче киңәшчемә һәм шулай ук һәлак булган башка укытучыларга мин хәзер бүтән берни әйтә алмыйм.

Сугыш турында күп язылды. Ләкин, күпме генә язылса да, ул елларның дәһшәтен,

*Нурихан Фәттах: альбом / төз. Р.Фәттахова, Ч.Фәттахова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 155-160 б.



кайгысын-сагышын беркайчан да тулы итеп тасвирлап булмас кебек. Безнең буынның исәеп, ачылып килгән чагы шул чорларга туры килде. Бездән өлкәннәр еракта турыдан-туры дошман белән якалашканда, монда, туган җирдә калучылар көн-төн дип әйтерлек төрле кыенлыклар белән, хәтта үлем белән көрәш алып бардылар. Минем яшьтәшләрнең, кордашларның кайберләре, авыр сынауларга түзә алмыйча, бик иртәли кабергә керделәр. Без менә, нишләптер, чыдамрак булып чыктык.

Бу хакта мин еш уйланам. Бит минем дә кыл өстендә калган чакларым күп булды. Егылмаска, бирешмәскә безгә ул чакларда киләчәккә булган ышаныч һәм яхшы, шәфкатьле кешеләр ярдәм итте. Шундый яхшы кешеләрнең беренчесе итеп мин Баямый абыйның әнисен – ул вакытта атап йөрткәнчә, «Әби»не телгә алмакчы булам. Миңа карата гына түгел, безнең бик зур ишегалдындагы барлык балаларга, барлык күршеләргә карата ул һәрвакыт ягымлы, һәрвакыт ачык күңелле һәм юмарт булды. Тирә-якта ул бердәнбер сыерлы кеше иде. Шуңа күрә дип әйтимме, кайчан кермә, синең алдыңа сөтен-катыгын китереп куя, ничек тә синең күңелеңне күтәреп, тамагыңны туйдырып чыгара. Ә мин аларга шактый еш керә идем. Әле Казанда укып йөргән чакларда да, юл өсте төшеп, «Әби»ләрдә кунып, ял итеп чыга торган идем.

Үзем укыган Яңавыл татар урта мәктәбе укытучыларыннан да мин заманында күп яхшылык күрдем. Шул ук «Әби»нең кызы, Баямый абыйның сеңлесе Гайшә апа Дусметова миңа карата әнисе кебек үк ягымлы һәм киң күңелле булды. Авыр елларда мине аякка бастырган, һәрьяклап миңа булышкан укытучыларымнан Шәрәфел Зәйнуллина, Шәмсенур Шәфиева апаларны, сугышта бер кулын өздереп кайткан Гали абый Хисамовны, Шиһабетдин абыйны, аеруча Шамил абый Дускаевны мин һәрвакыт рәхмәт хисләре белән искә алам.

Әгәр дә мәгәр ул вакытларда укытучылар һәм башка кайбер кешеләр «шагыйрь булырга» хыялланып йөргән малайга гамьсезлек, битарафлык күрсәткән булсалар яисә берәр төрле ялгыш сүз-киңәш биргән булсалар, күрәсең, беркайчан да миннән язучы чыкмаган булыр иде.

Менә бер генә мисал. Унынчыны бетереп, инде нишләргә диебрәк йөргәндә, «Октябрь юлы»ның җаваплы секретаре Сәгъдә апа миңа университетның татар бүлегенә керергә киңәш итте. Редакциягә Казаннан «Кызыл Татарстан» газетасы килә. «Кызыл Татарстан»да университетка укучылар кабул итү турында белдерү басылган иде. Сәгъдә апаның киңәше минем күңелгә хуш килде. Бернинди икеләнүсез мин документларымны Казанга, университетка җибәрдем.

Шулай итеп без Казанга килдек.

Университет укытучылары арасындагы «яхшы кешеләр»не дә, мәсәлән, Рәбига апа Хәкимованы, Латыйф абый Җәләйне һәм Мөхәммәт абый Гайнуллинны әйтеп китмәкче булам. Безнең өчен алар укытучы гына түгел, шулай ук тәрбияче дә, киңәшче дә булдылар. Мин, мәсәлән, бик тиз арада Җәләй абыйның «коткысына» бирелдем һәм, каникул вакытларында авылга кайткач, халык җырлары, халык сүзләре җыю белән мавыга башладым. Бу эш миңа бик ошады. Бик күп еллар дәвамында, бертуктаусыз дип әйтерлек, мин җырлар, бәетләр, табышмак кебек нәрсәләр җыеп, язып бардым. Халкымның телен, гореф-гадәтләрен, дини-мифик карашларын аңлауда, үзләштерүдә моның файдасы әйтеп бетергесез зур булды. Халык иҗаты белән кызыксыну миндә шулкадәр көчле иде, университетны тәмамлагач, мин хәтта фольклор буенча аспирантурага калырга да исәпләп йөрдем. Ләкин шулай да әдәби иҗат юлын сайладым.

1955 елда мин беренче зур күләмле әсәремне тәмамладым. Романны иң элек Габдрахман Әпсәләмов укып чыкты. Ниндидер бер җыелышта ул мине мактап телгә алды.

Якташлар (сулдан уңга) – Нил Юзиев, Риза Ишморат һәм Нурихан Фәттах. 1993

Шуннан соң яшь иптәшнең беренче романын башкалар да укыдылар, яраттылар, мактадылар, ләкин... бастырырга бик үк ашыкмадылар. Ни өчен дигәндә, романның телендә-стилендә «фольклор материаллары» кирәгеннән артыграк булып чыккан иде. Аннан соң авыл тормышын да автор үзенчәрәк тасвирлаган. Авторга романның телен беркадәр үзгәртергә, кайбер нәрсәләрне сызып ташларга киңәш иттеләр. Ләкин яшь иптәш бернәрсәне дә үзгәртергә теләмәде. Журнал редакторы Гази Кашшаф та алай артык күндәмнәрдән түгел иде. Романны бастырудан ул бөтенләй баш тартты. Нәкъ менә шунда Язучылар союзының ул чактагы председателе Гомәр абый Бәширов, бар җаваплылыкны үз өстенә алып, романны шул көенчә бастыруга иреште.

Шулай итеп, минем алда зур әдәбият ишеге ачылды. Дөрес, беренче ишек ачылу белән барлык ишекләр дә җиңел генә, үзеннән-үзе генә ачылган икән дигән сүз түгел. Минем бер генә зур әсәрем дә бәхәссез, каршылыксыз дөнья күрмәде, дисәм, һич тә ялгыш булмас. Мисал өчен «Сызгыра торган уклар» романының басылу тарихын искә төшерергә була. Роман «Казан утлары»нда инде китте дигәндә тоткарланып калды. Мәсьәләне ачыклау өчен, ягъни редактор белән автор арасындагы бәхәсне хәл итү өчен Язучылар союзына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Кульъязманы Союз идарәсе һәм редколлегия әгъзалары укып чыкты. Романны тикшерү өчен махсус утырыш җыелды һәм, бер-ике кешене исәпләмәгәндә, барлык язучылар авторны яклап чыктылар.

Монда шуны да әйтергә кирәк, язучыларның күпчелеге бездә татар әдәбиятының, татар культурасының үсүе өчен чын күңелдән янып яшәүче кешеләр. Уртак кайгыны, уртак мәнфәгатьләрне алар үз кайгыларыннан өстен куялар һәм, кирәкле әсәр турында сүз барганда, ныклык, принципиальлек күрсәтә беләләр. Моның шулай икәнлеген миңа берничә мәртәбә «үз җилкәмдә татырга» туры килде. Миңа өлкән буын каләмдәшләр дә, кордашлар да, шулай ук яшьләр дә күп булышлык күрсәттеләр. Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Әмирхан Еники иҗатымда, тормышымда минем чын мәгънәсендә терәк һәм таянычыч булдылар. Алар белән бергә, бер чорда яшәгәнгә, иҗат иткәнгә мин үземне, әлбәттә, бәхетле саныйм һәм минем хезмәттә аларның да күпмедер өлеше бар дип исәплим.

Бөек Болгарга сәяхәт. 1981

Иң ахырда мин үземә бары уңай яктан гына тәэсир иткән тагын бер-ике кешегә тукталып китмәкче булам. Икенең берсе – Шәйхи Маннур, икенчесе – Хәмит Ярми.

Гаделлек, дөреслек өчен теләсә кем белән якалаша ала торган Шәйхи Маннур туры сүзле һәм шактый нык характерлы иде. Язган әсәрләрем өчен ул мине якын күрде, җыелышларда, киңәшмәләрдә һәрвакыт мине яклап чыкты. Ләкин кайчагында ул миңа үтемле генә тәнкыйть сүзләре дә әйткәләде. (Мәсәлән, Нурихан ничектер аңа эч серен ачып, хатын белән килешә алмыйбыз, һаман каршылык килеп чыга, дип зарлангач, ул: «Син шәхси тормышта характерыңны чүплек башына чыгарып ташла!» – дип киңәш биргән. Ш.Маннурның бу сүзләре Нуриханның көндәлегеннән алынды. – Р.Ф.)

Фольклор белгече, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми белән мин университетта укуымның беренче елларында ук таныштым. Бу танышу Җәләй абый аркасында булды. Минем халык иҗаты белән кызыксынуымны күреп, 1948 елның җәендә Хәмит абый мине үзе белән бергә фольклор экспедициясенә алып чыкты. Шуннан бирле без аның белән әледән-әле очрашып, аралашып тордык.

Хәмит Ярмине Шәйхи Маннурның капма-каршысы дип әйтергә булыр иде. Йомшак күңелле, ягымлы, һәркем белән уртак тел таба белә. Әгәр, әйтик, сиңа берәр киңәш бирергә теләсә, беркайчан шулай ит, болай ит дип вәгазь укымас. Бөтенләй сиңа катнашы юк кебек итеп, үз башыннан үткән, йә булмаса кешедән ишеткән берәр гыйбрәтле хикәя сөйләр. Аңласаң – аңлыйсың, аңламасаң, анысы инде синең эш. Кайбер әдәп, культура кагыйдәләреннән хәбәрдар булмаган авыл малаена аның гыйбрәтле хикәяләре тәэсир итми калмагандыр дип уйлыйм.

Бервакыт, пенсиягә чыккач, ул мине өенә чакырып алды, миңа үзенең күпьеллык хезмәтен – халык иҗаты җыентыкларын бүләк итеп бирде. Һәм тагын да, болай гына, сүз арасында гына гыйбрәтле хикәя сөйләде.

Хәмит абый үзе Себердә, Төмән ягында туган. Шунда, алар ягында Нигъмәтулла хаҗи Карымшаков дигән бер бай булган. Бай үзе укый-яза белмәгән, ләкин шуңа да карамастан, аңлы, прогрессив карашлы булган. Якын-тирәдәге ятим балаларны

Нурихан Фәттах хатыны Руфина ханым белән

Нигъмәтулла хаҗи үзенә тәрбиягә ала торган булган. Ятим бала бераз аягына баскач, бай моның кулына өч сум акча тоттырган да Казан, Уфа якларына укырга җибәргән. Хәмит абыйның әтисе дә ятим булган, әлеге Нигъмәтулла хаҗида тәрбияләнгән. Бай моңа да өч сум акча тоттырып укырга җибәргән. Хәмит абыйның әтисе Эстәрлетамак, Мәчкәрә мәдрәсәләрендә укыган. Шуннан соң үзләре ягына кайтып мулла булган, балалар укыткан. Хәмит абый үзе беренче ике елын әтисе мәдрәсәсендә белем алган.

Нигъмәтулла байның тагын шундый бер яхшы ягы булган. Түмән тирәсендәге авылларда ул таштан мәчетләр, мәдрәсә-мәктәпләр, мосафирханәләр, китапханәләр салдырган, читтән кыйммәтле китаплар алдырган, мәдрәсәләргә «Галия»дән укытучылар чакырткан. Себер юлы өстенә салынган мосафирханәләрдә шундый тәртип булдырган: сөргеннән кайтучы юлчыларны бушка ашатып, яхшы, җылы урында кундырып чыгарганнар. Ләкин бушка кунак булу икенче көнгә китсә, «монысы инде ялкаулык», дип, юлчыны чыгарып җибәргәннәр.

– Менә нинди кешеләр булган безнең татарда! Шулар турында да язарга иде, – диде Хәмит абый миңа. – Минем әтине Карымшаков алып тәрбияләмәсә, укытмаса, әти кем булыр иде – әйтеп булмый. Мин, бәлки, бөтенләй булмас та идем. Һәм беркайчан да бу дәрәҗәгә ирешә алмас идем.

Чыннан да, безнең халыкта элек-электән үк Карымшаков Нигъмәтулла кебек, «Әби», Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким кебек аңлы, ярдәмчел һәм киң күңелле кешеләребез булмаса, без, күрәсең, бүгенге көнебездәге күп нәрсәдән мәхрүм булган булыр идек.

Язучы булу өчен күп нәрсә таләп ителә. Иң әүвәл табигый талант һәм тырышлык кирәк. Ләкин сине аңлаучы, кирәк чакта сиңа ярдәм кулы сузучы халкың – әйе, халкың! – булмаса, ялгыз талант белән генә әллә ни ерак китеп булмый.

2003 ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Хәсән Туфан фатихасы белән...

Илгизәр Фазлуллин

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе 1934 елда Казан авиация заводының «Алга» гәҗите редакциясе каршында оештырылган иҗат түгәрәгенә җитәкче итеп, инде шул елларда ук үзенең иҗаты белән киң катлау укучыларга яхшы таныш булган шагыйрь Хәсән Туфанны билгели. Шулай итеп, эшче-иҗатчылардан торган иҗат түгәрәгенең беренче утырышы 1934 елның 11 июнендә уздырыла. Анда түгәрәк бюросы да сайлана. Хәсән Туфан түгәрәк эшенә даими җитәкчелек-булышлык итеп торуны үз җаваплылыгына ала. Түгәрәк утырышлары айга 3 тапкыр үткәрелә башлый.

Редакция каршында оештырылган әдәби түгәрәкнең беренче утырышы 18 июньдә була һәм анда эшче авторлар иҗаты карап тикшерелә. Аларның нәрсә турында иҗат итүләре шигырь һәм хикәяләренең исемнәреннән үк яхшы аңлашыла кебек: «Машинаңның серен, телен бел!», «Үрнәк төзелеш өчен», «Алга барабыз», «Бурыч итеп алдык без бүген»...

Ә инде еллар узу белән, әдәбият-иҗат түгәрәгендә прозаик һәм шагыйрьләрдән С.Хәким, Г.Әпсәләмов, Г.Ахунов, Г.Хуҗи (соңрак әдәбият-иҗат берләшмәсе җитәкчесе), Р.Гәрәй, М.Садри, З.Нури, И.Юзеев, Ш.Галиев, Н.Дәүли, Б.Камалов һәм башкалар хөрмәтле кунаклар булып катнашып килделәр, эшче-авторлар иҗатын игътибар үзәгеннән төшермәделәр, һәркемгә дә үзләренең төпле уй-фикерләрен җиткереп бардылар. Шулай итеп, «Алга» гәҗите битләрендә эшче-авторлар иҗаты даими игътибар үзәгендә булды, әлеге мөхтәрәм әдипләр һәркемгә дә үзләренең фикерләрен ирештерделәр. Нәтиҗәдә, «Алга» гәҗите битләрендә эшче-авторлар иҗатыннан оештырылган әдәбият-сәнгать сәхифәләре чыгарыла башлады. 1965 елдан башлап, мин бу әдәбият-иҗат түгәрәгенең бюро рәисе идем...

Р.Гәрәй авылда туып үсә. Шунда чишмәләр моңын, тургайлар җырын тыңлап, таңны уяткан зәңгәр офыкларга сокланып, бик яшьтән шигырьләр, җыр текстлары яза башлый. Авылда шыткан поэтик талант аны, бәйгеләргә әзерләнгән аргамактай, шигъри Сабан туена алып чыга: авыл егете Рәшит башкалабыз Мәскәүнең мәшһүр пролетар язучысы М.Горький исемен йөртә торган Әдәбият институтына кабул ителә. Биредә ул, илебезнең күпмилләтле яшь талантлары белән бергә укып, югары белем ала...

Рәшит Гәрәйнең «Беренче хисләр» дип аталган тәүге китабы 1952 елда басылып чыга. Моннан соң аның «Шинель җылысы», «Сагынылган җирләрдә», «Җырчы камышлар», «Тальян гармун», «Җырлап яшәр чагыбыз», «Һаваларда йолдыз», «Рәхмәт сезгә» һәм «Төнге учаклар» исемле китапларын да укучылар җылы каршылый. Берүк вакытта ул үзенең «Уйланган минутларда» исемле җыентыгын да төгәлли.

Рәшит Гәрәйнең шигырьләрен яратып укыйм, чөнки тыныч кына калдыра алмыйлар алар мине. Гаҗәеп бай лирикасымы, яисә аның шул тикле гадилеге һәм сабырлыгымы – кайсы күбрәк тартадыр үзенә, өзеп кенә әйтүе дә кыен. Тик бернәрсәне беләм: Рәшит шигырьләрен укып чыктым исә, ул шигырьләргә салынган барча хисләр йөрәгем тибешенә күчә. Шунысы аеруча кадерле аның миңа. Шул ягы белән яратыла да ул.

Очрашуларның берсендә, Рәшит Гәрәй редакциябездә үзенең берничә шигырен дә калдырып киткән иде. Алар шул вакытта гәҗит битләрендә басылып чыктылар. Шагыйрьнең портреты да бирелде. Мин исә шигырьләргә кереш сүз яздым.

Әйе, чыннан да шулай шул: яхшылык йөрәктән шытып чыга бит ул.

Рәшит Гәрәй шигырьләре

САГЫНДЫМ

Бик сагындым авыл юлларын,
Юл буена үскән урманын;
Шул урманның яшел аланын,
Аланында пешкән баланын,
Баланына кунган кошларын
Бик сагындым, якын дусларым!

Юлларыннан җырлап барасың
Узган чакта урман арасын.
Аткайларның алҗып, кичексәң,
Аланында куна каласың.
Сәламлисең балан куагын,
Ул сәламли якташ кунагын.

Танышларын ул да сагына:
Дәшә сине үзе янына.
Салкын җилләр өрсә чак кына,
Иелә дә шунда сак кына
Яфракларын яба өстеңә,
Иркәң булып керә төшеңә.

Әткәң булып коча, юата,
Әнкәң булып назлап уята.
Атларыңны җигеп бетүгә,
Хәерле юл теләп озата.
Үзе кала җилдә тирбәлеп,
Дусларыңа сәлам җибәреп.

...Соры шинель киеп өстемә,
Күпме җирне җәяү урадым!
Онытып булмый һаман: төшемдә
Эзләп кайтам балан куагын.
Ятам, имеш, аның төбендә,
Бер җыр туа шулчак күңелдә:

– Туган җирем! Нинди матур син,
Үзең ерак, үзең якын син...
Кавышканда мине юатма,
Күз яшемне тыя алмасам.
Елмаермын сине кочаклап,
Аланыңа ятып аунасам.

ӘТКӘМ КИҢӘШЕ

Әткәм минем җырчы булмаган,
Тик ул миңа бер җыр өйрәткән:
– Кешеләргә дигән яхшылык
Шытып чыга, улым, йөрәктән.

Тапламыйча сакла син аны
Авыр юллар аша үткәндә.
Өлешеңә тигән кайгыңны
Суза күрмә, берүк, бүтәнгә...

Кайгыларга азмы юлыктым?!
Йөзләремә чыкты сарысы...
Бакчаларда сафлык... яшеллек...
Башкаларга калсын анысы.

ЮК, АҢЛАМАС ДИМӘ

Әтисезләр хәлен аңлый микән
Пар кочакта үскән балалар?
...Зурлар да бит әле ятимнәрнең
Җаннарына яра салалар.

– Әтиең кайда? – диеп сорама син
Тик әнисен белгән баладан.
Юк, аңламас димә... Сораган булсаң,
Килеп гафу үтен аңардан.

Сиңа күзен тутырып карар да ул,
Сөйләп китәр айкап хисеңне:
– Әтием хат җибәрсә, почта абый
Белә микән минем исемне... ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Хәйретдин Мөҗәй
(1901-1944)

Хәйретдин Мөҗәй (Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов) Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, гвардияче полк командиры буларак, үзенә йөкләнгән сугышчан бурычларны үтәүдә, гитлерчыларның сугыш башында өстенлек иткән гаскәри көчләренә каршы оборона һәм һөҗүм операцияләрен башкаруда күп тапкырлар кыюлык һәм шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтә.

Ләкин 1942 елның җәендә, Харьков юнәлешендә һөҗүм хәрәкәтләре барышында Мөҗәй командалык иткән полк дошман чолганышында кала һәм айдан артык сузылган авыр бәрелешләрдән соң, полктан исән калган авыр яралылар, шул җөмләдән полковник Хәйретдин Мөҗәй дә фашистлар кулына әсир төшә.

Хәйретдин Мөҗәйне, башка әсирләр белән бергә, Алманиягә озаталар. Ул әсирлектә дә фашизмга каршы көрәшен туктатмый: Мюнхен шәһәрендәге совет хәрби әсирләре лагеренда төзелгән интернациональ антифашистик яшерен оешма җитәкчеләреннән берсе була. Әсирләр Алманиягә көчләп куып китерелгән совет гражданнары һәм немец эшчеләре арасында фашизмга каршы пропаганда җәелдерү, листовкалар,

прокламацияләр язу һәм тарату буенча актив эш алып бара. Яшерен оешма, пропаганда һәм соботажлар белән генә чикләнмичә, баш күтәрү өчен, әсирләрне коралландыру чарасына да керешә. Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагерена яба һәм, озак газаплаулардан соң, үлем җәзасына хөкем итә; 1944 елның 4 сентябрендә үлем карарын гамәлгә ашыра. Фашист палачлары ул көнне җәзалап үтергән (әүвәл газ белән агулыйлар, аннары крематорий мичендә яндыралар) туксан ике Дахау тоткыны арасында шагыйрь һәм язучы, полковник Хәйретдин Мөҗәй дә була.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.143.

Шамил Гәрәй
(1916-1946)

Ватан сугышы башлангач, Шамил Гәрәй фронтка китә. Мәскәү янында барган каты сугышларның берсендә ул, сугышчан иптәшләре белән чолганышта калып, фашистлар кулына әсир төшә һәм фашизм коллыгының бөтен авырлыгын башыннан кичерә. Инде Җиңү көне килеп, әсирлектән йолып алынса да, Шамил Гәрәйгә Казанга кайтып яшәргә һәм әдәби иҗат хыялларын тормышка ашырырга насыйп булмый, ул 1946 елның 22 мартында Польшаның Гливице шәһәрендә әсир тоткыннарны тикшерү лагеренда вафат була.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б. 392.

***Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Халык музыка уен коралларында уйнау остасы,
артист Фәйзи Биккининның тууына 120 ел

Халык музыка уен коралларында уйнау остасы, ТАССРның атказанган артисты (1963) Фәйзи (Фәйзерахман) Бикмөхәммәт улы Биккинин 1898 елның 1 октябрендә туа. 1915 елдан башлап сәхнәдә скрипка һәм гармун белән чыгыш ясый башлый.

1930-1937 елларда Татарстан радиосында солист булып эшли.

1937 нче елларда исә Татарстан филармониясендә хезмәт куя.

Ул 70 яшендә 1968 елның 23 мартында Казанда вафат була.

Күренекле музыкант, композитор
Заһидулла Яруллинның тууына 130 ел



Музыкант, композитор Заһидулла Ярулла улы Яруллин 1988 елның 10 октябрендә Татарстанның хәзерге Мамадыш районы Кече Сөн авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Ун яше тулгач, өяз шәһәре Чистайга еш йөри торган күршеләре Заһидулланы шәһәргә алып китә. Анда ул бер гаиләгә хезмәт итеп көн күрә башлый.

1901 елда ул Чаллыга күчеп килә һәм анда бер чәйханәгә аш өләшүче малай булып урнаша. Шул ук елның көзендә аңа Минзәлә ярминкәсендә булырга туры килә. Монда ул чын җырчыларны, гармунчыларны, скрипкачыларны, гомумән, төрле уен коралларында уйнаучы артистларны күрә. Шушында алган тәэсирләр йогынтысында, Заһидулла музыкага юл эзли.

Татар шагыйре Габдулла Тукайның үлемен ул бик авыр кичерә. Заһидулла шул вакытта шагыйрь истәлегенә иң тәэсирле, тирән мәгънәле көен багышлый. Башта бу әсәр «Тукай истәлегенә» дип атала һәм инструменталь әсәр буларак иҗат ителә. Аннары аңа Тукайның иң әйбәт элегик шигырьләреннән берсе булган «Өзелгән өмид» (1910) шигыре сайлап алына.

Шул чорда алдынгы татар зыялылары Галиәсгар Камал, Гафур Коләхмәтов, Габдулла Кариев белән еш очрашулар да Заһидулла Яруллинның рухи үсешенә зур йогынты ясый. «Сәйяр» труппасының музыка ансамблендә ул пианист һәм җитәкче булып эшли.

Казанда Заһидулла Яруллин педагогик эшчәнлек белән дә шөгыльләнә. Татар классик композиторы Салих Сәйдәшев беренче музыкаль белемен Заһидуллла Яруллинда ала.

Заһидулла Яруллин 1964 елда 75 яшендә вафат була. Аны туган авылы – Мамадыш районының Кече Сөн авылында җирлиләр.

Язучы Әсрар Галиевнең тууына 80 ел



Язучы Әсрар Әбрар улы Галиев 1938 елның 16 октябрендә Татарстанның Әлки районы Түбән Биктимер авылында дөньяга килә.

Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, диңгезче формасын да салмаган егет, 1958 елда Лениногорск каласына килә һәм «Ильич васыятьләре» газетасында хәбәрче булып эшли башлый.

Ерак җирләр, дөнья күрү теләге аны 1959 елда шахтага алып китә. Сигез ел күмер чапкач, кабат бу якларга кайта. Аның тормышы һәм барлык хезмәт юлы Лениногорск районында һәм шәһәрендә үтә: Түбән Чыршылы урта мәктәбендә укыта, спорт яратучылар, көрәшчеләр әзерли. Ул үзе дә – Сабан туйларында бил алышып, җиңүче булып калган батыр.

1971 елда Казан дәүләт университетын тәмамлый, балалар укыта, шахтада эшли.

Әсрар Галинең әдәби иҗат итү сәләте елдан-ел арткаңнан арта бара. 1980 елда аның «Төнге җыр» повесте Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. 1987 елда «Асыл кошым минем» повесте, 1992 елда «Көн яктысы» романы, 1998 елда «Айлар биек» очерклар җыентыгы, алты томнан торган «Гали батыр» трилогиясенең дүрт томы дөнья күрә. Күптомлы әсәрнең һәр китабында язучының үзен һәм тормышын ачык тоеп, белеп була.

1992 елда ул, «Көн яктысы» романы өчен, Ш.Бикчурин исемендәге премиягә лаек булды.

1984 елдан Татарстан язучылар берлеге әгъзасы иде.

Әсрар Галиев 1998 елда алтмыш яшьлек юбилеен уздырырырга әзерләнеп йөргәндә кинәт бу фани дөньядан китеп барды. Лениногорск районында җирләнде.

Актёр һәм режиссёр Камал I нең тууына 125 ел

Актёр һәм режиссёр Камал I (Габдулла Галиәкбәр улы Камалетдинов) 1893 елның 26 октябрендә (кайбер чыганакларда 20 октябрь, дип күрсәтелгән) Казанда туа.

Кече яшьтән үк байларда хезмәт итә. Габдулла 17 яшендә инде приказчик була. 1910 елда Казанда «Шәрык клубы» ачыла. Шунда режиссер булып эшләүче Галиәсгар Камал энесе Габдулланы да театрда уйнарга җәлеп итә. Шулай итеп, читек-кәвеш кибете приказчигы 17 яшендә сәхнәгә чыга һәм бер-ике елдан профессиональ артист булып китә.

1912 елдан «Сәйяр» труппасында Габдулла Кариев кул астында 8 ел эшләп чыныгу алган Габдулла Камал үзенең иҗатын төрле шәһәрләрдә дәвам иттерә. 1918 елда Газиз Айдарский белән Буа театрында (хәзерге Буа дәүләт драма театры) бер сезон эшли. Ташкент шәһәрендә үзе татар театры оештыра, үзбәк халкының театр сәнгатенә юл яра, таҗик, төрекмән театрларына да булыша. Новосибирск, Әстерхан, Ырынбур, Царицын шәһәрләре театрларында да хезмәт куя. Татарстан АССР хөкүмәте чакыруы буенча, Камал I, 1931 елда Казанга кайтып, радиодрама коллективының баш режиссеры була һәм гомеренең соңгы көненә кадәр шунда эшли.

1933 елда вафат. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Аһәңи ләззәт чыганагы

Риф Гатауллин

Нәрсә ул халыкчан башкаруның үзенчәлеге? Бөек Тукаебыз бу сорауга да күптән инде җавап биргән: «Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы, вә иреннәрнең дә мөмкин булган кадәр аз ачылуы мәъгкуль вә мөстәхсән күрелә... (1).

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта һәр шәкертнең хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде». (1, 173-174 б.).

Халыкчан башкару үзенчәлекләре бигрәк тә озын көйләрне башкарганда ачык чагыла. Озын көйләр башкару техник яктан да, мелодик яктан да бик катлаулы. Алар җырчыдан киң диапазон, иркен сулыш, көчле тавыш мөмкинлекләрен таләп итә.

Риф Гатауллин

Озын көйләрдә башкаручы өчен импровизациягә киң мәйдан ачыла, аңа үзеннән төрле бизәкләр, яңа төсмерләр өстәргә мөмкинлек бирелә. Татар көйләре башкаручыдан үзенә бертөрле аерым төгәллек белән җиренә җиткереп башкаруны, мелизмнарны югалтмыйча тыңлаучыга илтеп җиткерүне таләп итә.

Дөрес итеп сулыш алу, атап әйткәндә, сулышны күкрәк куышыннан чыгарып корсак куышына кадәр төшермичә җырлау нәтиҗәсендә катлаулы булган фраза интонация ягыннан чиста итеп башкарыла. Җырчылар гадәттә тавышны күкрәк һәм борын куышлыгы ярдәмендә көчәйтүгә ирешәләр. Түбән ноталарны җырлаганда – күкрәк, ә югары ноталарда борын куышлыгы резонаторына өстенлек бирелә, нәтиҗәдә, тавыш ачык, кысылмыйча чыга. Ләкин алар аерым-аерым түгел, ә бербөтен булып яңгырарга тиеш.

Фориатур бизәкләрне башкарганда аваздан авазга күчү тиз, хәрәкәтчән, шул ук вакытта җиренә җиткерелеп башкарылуы сулышны диафрагманың аскы өлешенә таянып алып җырлау нәтиҗәсендә ирешелә.

Тиз ритмлы җырларны башкару принциплары башкачарак. Мондый төр җырлар өчен тигез темп, төгәл ритмик хәрәкәтләр, башкару импровизациясе чагыштырмача азрак булу хас. Җырны уенчак, хәрәкәтчән башкару бер авазданикенчесенә күчкәндә зур төгәллек сорый. Әгәр дә аваз саен иҗек туры килсә, бер тавыштан икенче тавышка җиңел генә, өзелмичә күчелә. Иҗек берничә авазга тартылып катлаулы ритмик фигурация тудырып җырланганда исә эш башкачарак тора. Бу очракта сүзләрне аңлаешлы итеп әйтү һәм интонация төгәллеге һәрбер ритмик кисәкне сизелер-сизелмәс итеп йомшак кына, басым ясамыйча гына сулышны этәрү ярдәмендә ирешелә. Көйнең темпы никадәр тизрәк булса, этәрү шулкадәр көчлерәк. Темпның тизләнеше арткан саен ул сүрәнәя, әйтерсең лә җырчы алдан ук көйләнеп куелган тавыш кылларына орынып-орынмас кына кагылып уйный. Читтән караганда тыныч кына кебек тоелса да, бу җырчыдан тавыш һәм сөйләм аппаратын бик зур, игътибар белән куллануны таләп итә.

Халыкчан җырлауның тавыш төре, тавышның киңлеге һәм матурлыгы белән бәйле башка үзенчәлекләре дә бар.

Хатын-кыз тавышлары арасында калын яңгырашлы түбән (меццо-сопрано) тавышлар (Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова) белән беррәттән йомшак, нәфис (лирик сопрано) (Фәридә Кудашева) һәм әлбәттә, җиңел, хәрәкәтчән (колоратур сопрано) тавышлар (Галия Гафиятуллина) киң таралган.

Ир-ат тавышлар арасында урта һәм биек тавышлар өстенлек итә. Түбән ир-ат тавышы татарларда юк диярлек дәрәҗәдә һәм түбән регистрда җырлау бик сирәк очрый. Бу күренеш татар халык көйләренең табигатеннән килә. Түбән тавышлардан Сөләйман Йосыпов (бас), урта тавышлардан Илһам Шакиров (баритон), биек тавышлардан Рәшит Ваһапов (драматик тенор), Габдулла Рахимкулов (лирик-драматик тенор), Таһир Якупов (лирик тенор) исемнәрен атарга була.

Әгәр дә җырчыларның көй бизәкләренә бай татар халык җырларын башкаруларын дикъкать белән тыңласаң, тавышның ничек оста итеп көйнең бормалы-сырмалы бизәкләре буйлап агылуын сиземләргә була. Көй бормаларының иркен-импровизацион характерда булуы башкаручыдан ул бормаларны һәм аларның темпын дөрес итеп тоя белүне таләп итә. Артык тиз, ашык-пошык башкару көйнең дөрес агышын бозса, артык әкрен башкару фразаны суза, музыкаль фикерне тарката, көйнең төп сызыгын тоныгайта.

Көй бормаларын иркен импровизацион җырлау манерасы озын халык җырларын нотага салуны кыенлаштыра.

Озын көйләрнең бормалары кыска йә сузынкы булырга мөмкин. Ләкин бу очракларның һәркайсында да да халык җырчыларына башка лад авазларына кагылмыйча пентатоника баскычларын интонацион төгәл итеп башкаруга омтылыш хас.

Халыкчан җырлау манерасын, вокал сәнгате сүз белән бәйле булганлыктан, төрле халык вәкилләренең барчасында да иң әүвәл телнең фонетик үзенчәлекләре аныклый. Халыкчан башкару манерасы аларның күбесендә тавышны опера-концерт кануннары таләп иткәнчә куярга комачаулый. Бу үзенчәлек бер телнең вокал мөмкинлекләре икенчеләренә караганда күбрәк дип санарга сәбәпче булып тора. Вокал мөмкинлекләре иң күп булып итальян теле, азрак булып тамак төбе белән сөйләшүче Урта Азия халыклары теле санала.

Татар халкында, башка милләтләрдәге кебек, гореф-гадәтләре җыр-моңга әверелеп буыннан буынга күчеп гасырлар буе җыелып килгән үзенә генә хас үзенчәлекле башкару манерасы, гадәте бар.

Татар әдәби теле өч төп диалектка нигезләнеп формалашкан. Болар: Татарстан, Башкортстан һәм Россиянең кайбер өлкәләре җирлегендә таралган урта; Горький,

Ульяновск, Пенза, Саратов, Самара өлкәләре, Мордва һәм Чуашстан Республикалары, Татарстанның көньяк-көнбатыш өлешләре җирлегендә таралган көнбатыш; Көнбатыш Себер җирлегендә таралган көнчыгыш диалектлары. Көнбатыш диалект – араларында вокал мөмкинлекләре иң зур булганы.

Тамак төбе белән сөйләгәндә ул – күкрәк резонаторы, ул инде киң диапазонга комачаулый. Бу – Казан татарларына хас сөйләм, шуңа күрә җырлау манерасы тамак төбе белән җырлау. Мишәрләрдә сөйләм манерасы – авызның алгы тешләргә һәм борын куышына якын сөйләм. Борын куышлыгы резонаторына якынайган саен тавыш киңлеге (диапозон) арта бара. Күкрәк резонаторы драматизм бирсә, борын куышлыгы резонаторы лиризмны өсти. Сулыш киң, гаҗәеп көчле иң югары нокталарда да иркен, табигый яңгырый тавыш. Табигать үзе үк яхшы вокал өчен мөмкинлекләр тудыра. Итальян һәм украин халыклары вокал сәнгате буенча дөньякүләм танылган этнос санала. Аларның сөйләм теле яхшы вокал үзләштерү өчен мөмкинлекләр бирә. Үземнең күпьеллык күзәтүләремнән чыгып әйтәсем килә: татар теле диалектлары арасында вокал өчен тавыш мөмкинлеген, диапазонының киңлеген мишәрләрнең сөйләм манерасы арттыра. Чынлап та халык арасында танылган матур, киң сулышлы көчле тавышлы татар җырчылары – чыгышлары буенча мишәрләр. Мәсәлән, Рәшит Вагапов, Габдулла Рәхимкулов, Хәйдәр Бигичев.

Татар халык җырларына моң хас. Нәрсә соң ул моң? Моң төшенчәсе – гомумән шактый катлаулы, каршылыклы күренеш. Без бу сүзне еш ишетәбез, еш кулланабыз. Моң ул җырны гына, башкару үзенчәлеген генә сыйфатлый торган төшенчә түгел, моң ул – иң элек тирән психологик кичерешләрне үз эченә алган эчке рухи хәл-халәт.

Моң – татар җырының төп сыйфаты, татар җырларын башка халыклар иҗатыннан аерып торган төп үзенчәлеге. Хәтта: «Моң сүзе русчага тәрҗемә ителми», – дип тә әйтәбез. Моңлы җырларны матур, тыңлаучыга эстетик һәм рухи ләззәт бирерлек итеп башкара алу, әлбәттә инде, башкаручының һөнәри осталыгына бәйле.

Күп кенә татар җырчылары татар халык җырын халыкчан итеп башкару осталыгына ия. Мәсәлән, Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Вагапов, Габдулла Рәхимкулов, Галия Кайбицкая, Фәридә Кудашева, Зифа Басыйрова, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева һ.б. Җырны халыкчан башкару халык җырларын яисә композиторларның халыкчан стильдә язылган җырларын башкарганда уңышлы кулланыла. Һәрбер башкаручының – үз моңы, үзенә генә хас авазы, башкару үзенчәлеге. Аларның һәрберсе, халык җырларына үз моңын, дәртен салып, яңадан халыкка кайтара.

Рәшит Ваһапов

Филармониядә Р.Ваһаповка кадәр югары профессиональ дәрәҗәдәге кабатланмас тавышлы, моңлы, чын татарча рухлы эстрада җырчысы булмаган. Дөрес, аңа хәтле дә татар эстрадасында җырчылар булган. Шуларның иң күренеклеләре – күбрәк озын көйләрне башкарып, чын халык традицияләрендә иҗат итүче Фәттах Латыйпов һәм җиңелрәк жанрларга өстенлек биргән

Габдулла
Рәхимкулов

Камил Мотыгый. Күренекле музыка белгече, профессор М.Нигъмәтҗанов фикеренчә, «Рәшит Ваһапов шул ике юнәлешне уңышлы берләштергән, табигый рәвештә куша алган. Аның башкару сәнгате бик халыкчан, шул ук вакытта ул инде эстрада элементларын да шактый уңышлы файдалана. Рәшит Ваһапов сәхнәдә үзен бик иркен тота, әмма чама хисен һич тә онытмый, аның хәрәкәтләре бик табигый иде. Ул заманда татар сәхнәсендә андый җырчылар булмаган. Шулай итеп, Рәшит Ваһапов – татар эстрадасына нигез салучыларның берсе, дип әйтә алабыз». (2, 97 б.).

Рәшит Ваһапов халыкчан башкаручанлыкка аерата хас булган мелизмнарны оста файдалана. Аның өчен мелизматика югары вокал үзенчәлекләрен тулысынча файдаланырга мөмкинлек бирә торган уңышлы техник алым гына түгел. Борылмалар, бизәкләр җырчының эчке дөньясының, рухи кичерешләренең чагылышы булып тора. Ваһапов һәр җырга үзенең шәхси тойгыларын, эчке кичерешләрен сала, аларны төрле бормалар, бизәкләр аша бирә. Танылган музыка белгече профессор М.Нигъмәтҗанов фикеренчә, импровизациягә сәләт, табигый сиземләү Р.Ваһаповны аерым очракларда авторлык дәрәҗәсенә күтәрә. Мәшһүр «Урман» җыры – аның шәхси иҗаты, авторлык җимеше.

Габдулла Рәхимкулов – репертуарында татар халык җырлары зур урын алып торган җырчыларның берсе генә түгел, табигатьтән моң ияләре булган Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Рәшит Ваһаповларның халыкчан традициясен дәвам итүче җырчы да. Ул табигате белән халык моңын үзләштереп, халык җырларын тирән хискә төреп гаҗәеп зур осталык белән, моңлы итеп, бөтен күңелен, җанын биреп, көр тавыш белән сүзләрне төгәл әйтеп, тартык авазларга күбрәк басым ясап халыкчан җырлый. Габдулла Рәхимкуловның җырлаганын ишеткән һәркем аның ташып торган моңына, матур тембрлы тавышының көченә соклана. Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева үз истәлекләрендә болай ди: «Аның тавышы көчле, күкрәк түреннән яңгырап чыккан матур, моңлы, ягымлы аһәңле, халыкчан рухлы иде һәм гомере буена шул матур тавышы үзгәреп тоныкланмады». (3, 9 б.). Җырчы Миңгол Галиев Рахимкуловка багышланган истәлекләрендә гади халыкның Габдулла Рахимкулов тавышына мөнәсәбәтен күрсәтүче бик матур мисал китерә: «...әниемнең энесе Мәннәф абыйның: «Ай-яй моңлы җырлый, гөрләп тора тавышы! Ай-яй, вәт тавыш, вәт моң анда!» – дип, шулкадәр дә эчкерсез әсәрләнеп бөтен барлыгы белән тойган кичереше әле дә күз алдымда, таң калып, исе китеп әйткән сүзләре гомерем буе колагымда чыңлый һәм гомерем буе беркемнән дә, беркем хакында да аның дәрәҗәсендә эчкерсез сөйләвен ишетергә туры килмәде. Кеше авазының

тыңлаучыга тәэсир итәрдәй нинди сихри көчкә ия булуын шул чакта тагын да тирәнрәк аңлый башладым». (3, 5 б.).

Халкыбыз көйләрен дә, композиторлар җырларын да бердәй осталык белән башкаручы Габдулла Рахимкуловның тавышына, гади халык кына түгел, күренекле композиторлар да югары бәя бирәләр. Композитор Александр Ключарев: «Габдулла – халыкның үз арасыннан чыккан, халыкчан җырчы. Аның тавышы якты, чиста, моңлы», – ди (3, 9 б.).

Казан татарларының озын көе үзенең салмак тигез агылышы, көй хәрәкәтенең өзлексезлеге белән үзенчәлекле. Башкорт көйләреннән аермалы буларак, анда тавыш күләме киң булуга карамастан (бер ярым октавага кадәр), кискен интонацион сикерешләр юк, шулай ук инструменталь түгел, ә тавыш мөмкинлекләре файдаланыла. Көй агышында бер нотадан икенче нотага сикереш бизәкләр, бормалар ярдәмендә йомшартыла, нәтиҗәдә, мелодик юнәлеш бизәкләргә бай, сыгылмалы, нәфис килеп чыга.

Гөлсем Сөләйманова – халыкчан моңы, ягымлы тавышы белән гомерлеккә күңелләргә кереп калган җыр остасы. Аның тавышы тигез, матур, үзенчәлекле, бәрхет кебек йомшак, моңы тирәннән агыла. Җырлаганда авызын беленер-беленмәс кенә ача, алай да тавышы шулкадәр тигез, көчле яңгырый. Сәхнәдә үзен гади тота, залга туры карап җырлый. Аның бөтен максаты – халык үзе җырлаганча җырлау. Г.Сөләйманова тавышына хас тагын бер сыйфат – аның интонацияләргә гаять бай булуы. Аның дикциясе – ифрат ачык, матур. Шаян җырларны башкарганда бу бигрәк тә нык сизелә. Аларны да җырчы матур, йомшак, сүзләрне ап-ачык, аңлашылырлык итеп башкара. Мондый характердагы көйләрне башкарганда Сөләйманова йөзенә, күз карашына, хәрәкәтләренә бернинди артык шаянлык кыланулары чыгармый. Җыр эчке бер шаяру тойгысы белән сугарылып, дәртле, шаян булып ишетелә, ирексездән елмаю тудырып, тыңлаучыны җиңел сулата (4, 26 б.). Гөлсем Сөләйманова өчен көйнең мәгънәсе дә, халыкка моң белән ирешәчәк фикер дә мөһим.

«Үзенчәлекле, ягымлы, нәкъ татарга хас тавыш тигез һәм салмак агыла... Ул, артык нечкәреп, үтә югарыга да күтәрелми, бик калын, түбән авазларга да барып җитми, уртача тембрда агыла да агыла. Табигать бик сирәкләргә генә бүләк итә мондый тавышны. Өстәвенә, Гөлсем соклангыч ачык дикциягә ия. Ритмы да нык вә сизгер. Көйләр күтәренке рух белән җырлана» (4, 26 б.).

Башкортстан җирлегендә таралган урта диалектка мисал итеп Фәридә Кудашева иҗатын алырга була. Халыкның озын көйләрен башкарганда, Фәридә Кудашева көйне болгатып, төп мелодик юнәлешен боза торган бормалар (мелизмнар) белән мавыгып китми. Аның башкаруында һәр көй үзенең тиешле характерын ала һәм шул көйгә ябышып торган мелизмнар яңгырый. Халкыбыз көйләрен башкаручы буларак, ул халык артисткасы Гөлсем Сөләйманова традициясен дәвам итә. Бу ике җырчы өчен уртак булган гүзәл сыйфат – халык көйләре спецификасын тирәнтен аңлап, төгәл һәм бозмыйча, халыкның үзе кебек гади итеп башкару. Ф.Кудашева, нинди генә драматик характердагы яки җиңел юморлы җыр башкармасын, кирәксез мимика һәм хәрәкәтләр белән мавыкмый. Әсәрдәге бөтен кичерешләр аның күкрәгеннән бер пульс булып тибеп торалар һәм аның тавышында, күзләрендә чагылалар иде. Нәкъ менә шуның белән ул тыңлаучыны даими рәвештә теге яки бу җыр турында уйланырга мәҗбүр итә, игътибарны һәрвакыт үзенә тартып тора. ■

Файдаланылган әдәбият:

1. Г.Тукай. Халык әдәбияты. / Г.Тукай. Сайланма әсәрләр. 4 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985.
2. Фаттахов Р.А. Рәшит Ваһапов. Заман, иҗат, шәхес. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003. – 293 б.
3. Моңлы җыр булып. Татарстанның халык артисты Габдулла Рәхимкулов турында истәлекләр. – Төз. Ә.Сафиуллин. – Казан: «Раннур» нәшрияты, 2001. – 174 б.
4. Өммегөлсем. Гөлсем Сөләймановaның 100 еллыгына. – Казан: «Татарстан» журналы нәшрияты, 2006. – 133 б.

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

МУЗЫКАЛЬ МИРАСНЫ БАРЛАГАНДА

Атлаган алга китәр

Без халкыбызның үзенчәлекле җырлары, аның аһәңле көйләре турында төрле чорда иҗат иткән, эзләнгән галимнәр хакында беркадәр ишетеп беләбез. Шул ук вакытта халык музыкасы турында сүз чыктымы – башлап Бөек Тукаебызны искә алабыз. Ни дисәң дә, Тукай – халык җәүһәрләренең бар нечкәлеген шигъри җаны, табигый сизгерлеге, күңел нәзакатьлелеге белән беренчеләрдән тоя алган шәхес. Алга таба Тукай салган сукмактан, гомерләрен тулысынча диярлек татар көен, җырын өйрәнүгә багышлап, Солтан Габәши, Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи, Мәхмүт Нигъмәтҗанов кебек олпат галимнәребез кыю адымнар белән атладылар. Тора-бара бу сукмак шактый киң юлга да әверелде. Ходайның биргәненә мең шөкер, әлеге фәнни юлдан инде үз сүзләрен саллы гына әйтеп, шактый күп хезмәтләре, эзләнү җимешләре белән танылып килүче, Россиянең төрле төбәкләрендә сибелеп яшәүче милләттәшләребез белән үз ана телебездә сөйләшеп, татар җырының нечкәлекләрен тоя, төсмерли алучы берничә галимебез төпле адымнар белән атлый килә. Әлеге галимнәрнең берсе – ***Эльмира Ринат кызы Каюмова.***

Бу мәкаләдә без аның хакында язарбыз. Шушы араларда гомеренең иң матур бәйрәмен – 50 яшьлеген билгеләп үтүче Эльмира Ринат кызы – бүгенге көндә абруйлы этномузыка белгече, танылган фольклорчы. Ул – 120дән артык фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр авторы. Аның татар халык музыкасына кагылышлы эшчәнлеге турында республикабыз галимнәре генә түгел, дөньяның әллә кайсы төбәкләрендә дә

Эльмира Каюмова студент чагында консерваториянең Зур концерт залында «Казан алыну бәете»н башкара. 1990 ел.
Р.Галиев фотосы

хәбәрдарлар. Галимәнең тирән эчтәлекле мәкаләләре АКШ, Төркия, Казакъстанда басылучы фәнни тупланмаларда актив күренеп килә. Ул – Россиянең Фольклор берләшмәсе, Халыкара фольклорчылар ассоциациясе (SEEFA), ЮНЕСКО каршындагы Халыкара традицион музыка киңәшмәсе (ICTM) әгъзасы.

Эльмира Каюмова – тумышы белән Казан кызы. Кече яшьтән үк әби-бабасы, әти-әнисе белән татар телендә аралашып, халкыбыз көйләрен сабый вакытта ук яратып үскән кыз югары белемне Казан дәүләт консерваториясендә ала. Төпле белеме, таләпчәнлеге, тырышлыгы белән аерылып торган Эльмираны этномузыка фәне студент елларында ук үзенә тарта, алга таба бу юнәлештәге белемен ул Санкт-Петербург шәһәрендә тагы да тирәнәйтә төшә. Халкыбызның яшәп килүче «Тырышкан – табар, ташка кадак кагар» дигән мәкале нәкъ менә аның турында кебек. Галимәнең саллы гына фәнни фикерле диплом эшен консерватория профессорлары бик югары бәялиләр һәм аңа эзләнүен аспирантурада дәвам итәргә киңәш итәләр. Эльмира Ринатовнаның язмышы алга таба остазлары юраган юнәлештә язылa. Озак та үтми, Россия сәнгать тарихы институтында (Российский институт истории искусств, Санкт-Петербург шәһәре) ул, зур уңыш белән, кандидатлык диссертациясен яклый (2004 ел). Аның фәнни эшенә И.Земцовский, М.Кондратьев, С.Утегалиева, И.Нуриева, М.Хрущева

Галимә Э.Каюмова «Татар-информ» агентлыгына әңгәмә биргәндә. 2017 ел

кебек дөньякүләм танылган галимнәр югары бәя бирәләр. Ул вакытларда ук Э.Р.Каюмова үзен үзенчәлекле галимә, фәндә беркадәр үҗәтлек белән эшләячәк шәхес буларак таныта.

Кайбер галимнәрдән аермалы буларак аның фәнни тикшеренү кыры бик киң. Эльмира Каюмованы халкыбызның җырлары, бәет-мөнәҗәтләре дә, Коръән уку үзенчәлекләре дә, азан әйтүгә хас традицияләре дә, гөсләдә татарларга хас уйнау ысуллары һәм аны ясаудагы үзенчәлекләр дә, һәм тагын әллә ниләр кызыксындыра. Шунысы гаҗәп, һәр тикшеренү объектын да ул бар ваклыгын күзәтеп, бер генә детален дә төшереп калдырмыйча өйрәнергә тырыша, кирәк булса, бер генә детальне ачыклау, таләпчән акылын борчыгын соравына җавап табу өчен информантлары янына хәтта дүрт-биш тапкыр барып кайта. Эльмира Ринат кызының мәкаләләре, фәнни хезмәтләре мәсьәләгә тарихи һәм теоретик яктан җентекле якын киленгән булуы белән аерылып тора. Галимәнең фәнни даирәсендә татар милли музыкасы өлкәсенә үз өлешләрен керткән сәнгатькәрләргә бәйле эзләнүләр дә бар. Мәсәлән, ул «Тукай энциклопедиясе» өчен Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, җырчылар З.Сөнгатуллина, К.Хәйретдинова, галимнәр Р.Халитов, Г.Гобәйдуллина турында төпле мәкаләләр язды.

Эльмира Ринат кызы быел, гомер бәйрәме белән бергә, фәнни эзләнүләре башлануына 30 ел (!) тулуын да билгеләп үтә. Халкыбызның музыкага, татар көенә хирыс шәхесләре яшәүче авылларга сәяхәткә ул тәүге тапкыр 1988 елда студент вакытында ук чыга. Шуннан бирле Россиянең татарлар яшәгән дистәләгән төбәкләрендә (Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Мари Иле Республикалары, Киров, Түбән Новгород, Оренбург, Чиләбе өлкәләре һ.б.) берсеннән-берсе кыйммәтлерәк музыкаль фольклор үрнәкләрен туплауга ирешә. Кулына – диктофон, фото һәм видео камералар тотып, аркасына зур букчасын асып, Эльмира каккан капкалар саны дистә меңнәрдән, йөргән авыллары 200дән артып китә торгандыр. Галимәнең кыр шартларында эшләү тәҗрибәсе дә бик зур. Ул һәрвакыт халык музыкасына кагылышлы нечкәлекләрне күз алдында тотып, үзе махсус төзегән сораулыклар белән эшли. Бер генә авылда да аның авызыннан: «Материал аз табылды», – дигән җөмлә ишетмәссең. Аның өчен һәр авыл музыканты – зур хәзинә, тулы бер эпоха, халкыбызның музыкаль фикеренең бер глобаль факты. Ул һәр аралашкан кешесенең күңеленә үтеп керә белә, алай гына да түгел, шул арада туганлашып та өлгерә. Эльмира Ринат кызының телефон кенәгәсендә әллә кайсы авылларда яшәүче бәетченең, мөнәҗәтченең, мулланың, мәзиннең, гармунчының, җырчының номерлары әле дә теркәлгән килеш саклана. Ул, бер дә иренмичә, күбесе белән һәрдаим элемтәдә торып, хәл-әхвәлләрен белешә, басылып чыккан материаллары белән аларны да таныштыра, мөмкинлеге булган саен, аларга рәхмәтләрен ирештерергә тырыша. Болар барысы да – аның халыкны зурлавы, халык күңеленең бай, чиста, мәнле икәнлеген тануы, олы галим буларак формалашып бетеүенең мөһим күрсәткечләренең берсе.

Бик күп музыка белгечләреннән аермалы буларак, Эльмира Ринат кызы ике дәүләт

«Азан радиосы»нда кунакта. Алып баручы Илнур Фәйзрахманов белән. 2017 ел

телендә (русча да, татарча да) иркен яза, чыгышлар ясый. Ул – татар халкының музыкаль сәнгатен популярлаштыру, фәннең бу өлкәдәге казанышларын аңлаешлы итеп халыкка җиткерүдә иң актив эшләүче галимнәрнең берсе. Соңгы елларда гына да аның тырышлыгы белән биш компакт-диск җыелмасы дөнья күрде (CD, DVD). Алар арасында киң җәмәгатьчелек тиз арада үз иткән, югары уку йортларында хрестоматияләр, методик әсбаплар буларак кулланыла башлаган кыллы уен коралы – гөслә буенча өч чыгарылыш (Арча, Балтач районы һәм Мари Илендә үзе тарафыннан җыеп алган язмалар нигезендә эшләнгән), «Татар халкының йолалары һәм аларның сәхнәдә гәүдәләндерелеше» дигән видеоярдәмлек, Коръән уку буенча казан татарларының халык традициясе (беренче чыгарылыш) кебек кулланмалар да бар.

Эльмира Ринат кызы кабинетта утырып иҗат итүче галимә түгел, ул халык музыкасы традицияләрен саклау өлкәсендә дә армый-талмый эшли. Республиканың, Россиянең әллә кайсы төбәкләрендә мәдәният хезмәткәрләре белән даими очрашып, алар белән семинарлар үткәрә, экспедицияләр барышында үзе туплаган фольклор үрнәкләрен иҗат төркемнәренә даими рәвештә бирә барып, аларның репертуарларын баета. Бүгенге көндә халкыбызның музыкаль мирасын популярлаштыруга, актуальләштерүгә, саклауга йөз тоткан фестивальләрнең алыштыргысыз жюри әгъзасы, еш кына рәисе дә әле ул. Алар арасында танылган фестивальләр – «Түгәрәк уен», «Аһәңле Татарстан», «Төп йорт», «Этномириада», «Халкым мирасы» һ.б. бар. Нәкъ менә Эльмира Каюмованың инициативасы белән Бөтенроссия «Түгәрәк уен» һәм «Иске Казан түгәрәк уены» фестивальләренә балалар сәнгате, гөслә, борынгы чор фольклоры һәм такмак әйтеш буенча яңа номинацияләр өстәлде. Әйтергә кирәк, әлеге номинацияләр тиз арада фестивальнең иң матур бизәкләренә әверелеп, иҗади эшләүче өр яңа коллективларның барлыкка килүенә этәргеч бирде.

Эльмира Ринат кызы Каюмова – татар халык музыкасын өйрәнүче иң актив галимнәрнең берсе. Аның ел әйләнәсендә катнашкан халыкара, бөтенроссия күләмендә үткәрелүче конференцияләрдәге чыгышлары гына да дистәдән артып китә. Эльмираның тавышын, үзен без әледән-әле радио, телевидение челтәрләреннән ишетеп, күреп торабыз. Аның тырышлыгы, фәнни әзерлеге, белеме бәрабәренә Казан шәһәрендә (2016, 2017 елларда) халык уен коралларының төрлелеге турында сөйләүче күргәзмәләр дә

«Иске Казан түгәрәк уены» фестивалендә. Басып торалар: сулдан дүртенче кеше – Эльмира Каюмова, җиденче – Фәнзилә Җәүһәрова, соңгысы – шагыйрә Илсөяр Иксанова. Татарстан Республикасының Биектау районындагы Шәпше авылы. 2018 ел

оештырылды. Әлеге күргәзмә эшенә ул танылган галимнәрне, музыкантларны тарта алды, аларның шәхси фондларында сакланган инструментларын халык хозурына беренче тапкыр тәкъдим итүгә иреште. Күргәзмә эшен оештыру барышында «бу байлыкны балаларга да җиткерергә кирәк» дигән фикер туды һәм ул, озак уйламыйча, халык музыка уен кораллары турында балалар өчен китап әзерләү эшенә кереште.

Галимәнең эшчәнлеге даирәсен җыйнак күләмле бер мәкаләгә сыйдырып бетерү – шактый авыр гамәл. Эльмира Каюмова кандидатлык диссертацияләрен яклау вакытларында еш кына оппонент буларак та чыгыш ясый. Аның чыгышлары материалны төптән белүе, таләпчәнлеге белән аерылып тора. Мәсәлән, татар гармунын Америкадан килеп өйрәнүче галим П.Куйвинен диссертациясенең оппоненты да ул булды. Бүгенге көндә Эльмира Ринат кызының әлеге хезмәткә биргән югары бәясе инде үзен чын мәгънәсендә аклады.

Йомгаклап шуны гына әйтәсе килә: галимә даими эзләнүдә, ел саен экспедицияләргә чыгып үзенчәлекле материаллар туплавын дәвам итә, берсеннән-берсе кызыклырак проектларда катнашып, Г.Тукай әйткәнчә, халкыбыз җәүһәрләрен туплау, аларны саклау, популярлаштыру өлкәсендә зур эшчәнлек алып бара, аның адымнары нык, нәтиҗәле. Эльмира Ринат кызына исәнлек-саулык, иминлек, иҗат уңышлары телик. Гомере озын, бәрәкәтле һәм саваплы булсын, Аллаһы юлдашларының үзе кебек белемле, җитди, таләпчән, ышанычлы булуын насыйп итсен.

Фәнзилә Җәүһәрова,
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, филология фәннәре кандидаты.

Редакциядән: *Без дә даими авторыбызны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, күренекле галимәгә сәламәтлек белән хәерле озын гомер, иҗади эзләнүләрендә яңа табышлар һәм ачышлар теләп калабыз!* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЛМЫШ БИНЕ ШИЛКИ, АЛМЫШ ХАН – IX гасыр ахыры-X гасыр башында яшәгән. 895 елдан Идел буе Болгар дәүләтенең ханы. Чыганакларда *Алмас* варианты да очрый (ак. Мирфатыйх Зәкиев *Алмуш* дип әйтүнең дөрес түгеллеген кисәтә). Габдулла Җилкиның (Шилкиның) улы. Мөселманча исеме – *Җәгъфәр бине Габдуллаһ*. Чыганакларда *илтибәр* титулы белән дә телгә алына. Алмыш хан соравы буенча, Багдад хәлифәсе Мөкътәдир Биллаһ Болгар иленә зур илчелек җибәргән. Илчелекнең сәркатибе һәм фактта җитәкчесе Әхмәд ибне Фазланның (Фадланның) Идел буена бу сәфәре турында сәяхәтнамәсе бар. Шушы илчелек килгән вакытны (миляди белән 922 ел) Болгар илендә Исламның рәсми кабул ителү вакыты дип саныйлар, ләкин чынлыкта болгарлар моңа кадәр күптән мөселман булганнар инде.

Алмышның *Газан, Мал, Арбат, Ялкау* һәм *Микаиль Арслан* исемле уллары булган. Өлкән улы Арбат Хорысланда

Н.Хаҗиәхмәтов «Ибне Фадлан хәлифә әл-Мөкътәдирнең Алмыш ханга юлламасын укый». (Фрагмент)

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

балтавар Лачынга (Олег) хезмәт иткән («Җәгъфәр тарихы» буенча, ягъни мәгълүмат ышанычлы түгел). Алмыш һәм аның улы Арбат рус тарихында венгрлар буларак (*Альмуш* һәм *Арпад*), ә болгар тарихында болгарлар буларак сурәтләнә. Алмышның Мал исемле улы рус тарихында Добрыня дип исемләнә (И.Р.Мусина).

Ш.Мәрҗани үзенең Фәннәр академиясенә язган хатында Алмыш хан турында түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Чөнки аларның (Болгар мәликләренең. – *А.Т.*) иң элек мөселман булганнары, Алмасхан Сәлки хан углы, Габбасилардан Мөкътәдир Биллаһка буйсынуны бурыч итеп алып, Габбасиларны баш белеп, акчаларны алар исеменә, хотбәләрне аларга кылалар иде. Һәм бар эштә дә аларга охшауны үзләренә һөнәр итеп алганнар иде. Хәтта электәге гади «хан» титулын «әмир»гә, ә үзенең исемен Алмастан Җәгъфәргә алыштырып, «әл-Әмир Җәгъфәр» дип исемләнде, ә углына «әмир Әхмәт» дип куйды... Минем фикеремчә, аның нәселе Тимур һөҗүменә кадәр исән иде. Ләкин Чыңгыз нәселләренә буйсынуда иделәр. Болгар әмирләреннән Тимур тарафыннан үтерелгән әмир Габдулла шуларның соңгысы дип уйлыйм». Мәрҗани, гарәп галиме Мәсгудигә таянып, Болгар патшасы Җәгъфәр бине Габдуллаһның 943 елда илле меңле атлы гаскәр белән Константинопольгә каршы сугышка баруы турында яза.

АЛТЫН БӨРТЕК *тар.* – Борынгы Казан территориясендә, Архиерей дачасында табылган каберташындагы язмага караганда, миляди белән 1297 елның 27 сентябрендә (һиҗри 696 елда) вафат булган болгар бикәсе.

«АЛТЫН ТОБЧИ» – Галим лама Лубсан Данзан язган тарихи хезмәт (XVII гасыр). Бу ельязма Кытай иероглифлары транкрипциясендә генә билгеле булган «Монголларның яшерен тарихы»ның (1240 елда язылган) эчтәлеген сөйләп чыга.

АЛТЫН УРДА ЧОРЫ МӘЧЕТЕ *тар.* – Бу дәвер мәчетләрен без фәкать археологик тикшеренүләргә карап кына беләбез. 1971-1973 елларда археологлар Волгоград өлкәсенең Дубовка шәһәре тирәсендәге Белҗәмин шәһәрлегендә XIV гасырның беренче яртысында төзелгән мәчет хәрабәләрен казып тикшерделәр.

Мәчет 26 метрга 35 метрлы турыпочмаклык рәвешендә булып, төньяктан көньякка таба сузылган һәм михрабы белән көньяк – көньяк-көнчыгышка таба юнәлгән. Бинаның диварлары таштан балчык измәсе белән өелгән булган. Идәненә такта түшәлгән, ә төньяк-көнчыгыш почмагындагы түгәрәк манарасы яндырылмаган бөкре кирпечләрдән төзелгән. Аның тышкы өслеге фирүзә төсле ялтыравык плиткалар белән бизәлгән була.

Мәчет Алтын Урданы Аксак Тимер чирүе килеп җимергәнгә кадәр эшләп килгән.

Бинаның эчендә һәм аннан читтә 50 каберне казып тикшергәннәр. Бу каберләр мәчет эшләп килгән вакытка һәм, башлыча, аны җимергәннән соңгы чорга карыйлар. Аерым каберләр яндырылган кирпечтән төзелгән төрбә кебек. Мәетне такта табутка салып күмгәннәр. Кабер чокыры көнчыгыштан-көнбатышка таба юнәлдерелгән. Гүр әһелләре баш ягы белән көнбатышка куелганнар, йөзләре исә көньякка каратылган. Каберләрдә әйбер-мазар табылмаган диярлек. Алар өстендә таштан һәм кирпечтән төрле каберташлар калкып торган. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2018

Телебезне кадерләп саклыйк

Рүзәл Юсупов

Соңгы вакытларда туган телебезне кайгыртү зарурлыгы, татар телен саклау, өйрәнү-өйрәтү, үстерү өчен шартларның кыенлашуы турында борчылып сөйләү, язулар күп. Һәм телебезнең бүгенге хәленә, киләчәгенә кагылышлы проблемаларның арта баруында еш кына Мәскәүне, ягъни үзәк хакимият ияләрен гаеплибез. Мәсьәләгә мондый караш нигезсез түгел.

Мәгълүм ки, татар гаиләләренең күбесендә ата-аналар балаларын тумыштан ук үз телләрендә тәрбияләми, балалар бакчаларында татар телен махсус өйрәтү юк дәрәҗәсендә, мәктәпләрдә татар телен укытуның сыйфаты канәгатьләндерерлек түгел.

Шуның белән бергә, бүгенге көндә туган телебезне саклап үстерүгә куркыныч читтән генә түгел, үзебезнең тарафтан да яный. Без – татар телен дөрес куллану, аны яшь буынга тиешенчә өйрәтү өчен җаваплы кешеләр бу игелекле гамәлләрне нәтиҗәле итеп башкару өчен кулыбыздан килерлек эшләрнең барын да җиренә җиткереп эшләмибез әле.

Мәгълүм ки, татар гаиләләренең күбесендә ата-аналар балаларын тумыштан ук үз телләрендә тәрбияләми, балалар бакчаларында татар телен

махсус өйрәтү юк дәрәҗәсендә, мәктәпләрдә татар телен укытуның сыйфаты канәгатьләндерерлек түгел.

Шуның өстенә, телебезне куллану өлкәсендә дә җитди проблемалар бар. Бу язмада сүз шуларның берсе – татарча басма материалларда һәм сөйләмдә телебезне ялгыш куллану очраклары турында барыр.

Газета-журналларда, радио-телевидение тапшыруларында татар телен тупас бозып язу һәм сөйләү күренешләре елдан-ел, көннән-көн арта бара.

Узган гасырның туксанынчы елларыннан илдә һәм республикабызда башланган мәгълүм социаль-сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә, тиражлары зур булмаса да, татарча газета-журналларның, эфир каналларының һәм программаларының саны шактый артты. Шуңа бәйле рәвештә, аларны чыгаручы журналистлар да күбәйде. Тиешле органнар тарафыннан аларның эшен тикшерү, мәгълүмат чараларының эчтәлеге, теле белән кызыксыну, басылган материалларның югары сыйфатлы булуын таләп итү булмаганлыктан, шулай ук мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укып чыккан яшьләрнең белем дәрәҗәсе түбәнәюе аркасында, матбугатта, радио-телевидениедә көн таләбенә җавап бирә алмаслык язмалар һәм тапшырулар арта бара. Бигрәк тә аларның теленең сыйфаты борчуга салырлык хәлдә.

Барлык журналистларның да эшен бер калыпка салып үлчәргә ярамый, әлбәттә. Дөрес, матур, җанлы тел белән бай эчтәлекле, кызыклы итеп язучы һәм сөйләүче журналистлар да бар (хәлбуки, аларның барысы да шундый булырга тиеш). Ләкин андыйлар күп түгел. Газета-журналларда, радио-телевидение тапшыруларында татар телен тупас бозып язу һәм сөйләү күренешләре елдан-ел, көннән-көн арта бара. Матбугатта, радио-телевидениедә эшләүчеләр арасында гаиләләрендә, уку йортларында туган телләрен тиешенчә өйрәнмәгән һәм телләренең камил булмавына борчылмый да, аны яхшы итеп белергә омтылмый да торган кешеләрнең саны күбәя, дигән нәтиҗәгә киләсең. Газета-журнал, эфир материалларын әзерләгәндә, еш кына журналистлар тарафыннан аларның теле нинди булуына җавапсыз, битараф караш хөкем сөрә. Югыйсә, республика күләмендәге газеталарда, радио-телевидение тапшыруларында күзгә-колакка чалынган тупас тел ялгышларының күплеген ничек аңлатырга һәм бу күренешкә нинди бәя бирергә?!

Мәгълүмат чараларында еш очрый торган тел ялгышлары, дәрәҗәләре, үзенчәлекләре белән, бертөрле генә түгел. Аларның урынсыз кулланылган урыс һәм гарәп-фарсы сүзләре кебек телнең төзелешенә кагылмый торганнары да, туган телебезнең нигезен, төзелешен, грамматик системасын какшата, җимерүгә китерә торганнары да бар. Аңлашыла ки, бу икенче төре телебез өчен аеруча зарарлы.

Телнең табигый төзелешен боза торган ялгышларга татар телендәге сүз ясалышы кагыйдәләре буенча төзелмәгән лексик берәмлекләр, сүзләрнең сөйләмдә, текстта үзара мәгънәви (семантик) бәйләнешкә керү үзенчәлеге бозылган тәгъбирләр, әйтелмәгыйбарәне тәшкил иткән сүзләрне бәйләү чараларының дөрес кулланылмавы кебек күренешләр керә. Мисалларга күз салыйк: «Ул... Германиягә куып кителгән совет кешеләре белән элемтәләр урнаштырган». Бу җөмләдәге *куып кителгән* чын татарча түгел: аны газета журналисты урыс телендәге *угнанные* сүзе үрнәгендә ялгыш ясап кулланган (дөресе – *куып җибәрелгән*).

«Кышлаша салкын көз ямь-яшел килеш тә». Безнең телдә *кышлаша* дигән сүз юк, ул – авторның кирәкмәгән новаторлыгы нәтиҗәсе.

«Гомер китабымның синле битен ябам...», «Кәефемнең синле бу халәтен хәтеремә

уям...», «Булмый кайтып яшьлек төсе калган синле кичкә...». Бу шигырь юлларындагы *синле бит, синле халәт, синле кич* тәгъбирләре шулай ук татарча дөрес түгел: безнең телдә *синле* сүзе юк, *синсез яшәү* дип әйтеп була, *синле яшәү* дип әйтелми, *синең белән яшәү*, диләр. Рифмага, ритмга җайлыйм, дип, сүзләрне бозып кулланырга ярамый.

«Казан Сугышчан дан шәһәре исеменә лаек», – дип *ассызыклады* Людмила Олеговна». Бу җөмләдәге *ассызыклау* – урысчадагы *подчеркнуть* сүзенә ияреп, ялгыш ясалган шыксыз, мәгънәсез сүз, әмма шулай да безнең каләм ияләре аны яратып куллана. Хәлбуки, аның мәгънәсен *ди, дип әйтү* кебек сүзләр төгәл белдерә.

Безнең телдә иҗтимагый-сәяси эчтәлекле материалларда шактый күп кулланыла торган *дәүләтчелек* сүзе бар. Ул урыс телендәге *государственность* сүзеннән калькалаштырып ясалган. Әмма анда татар телендәге сүз ясалышы тәртибе (кагыйдәсе) бозылган. Хикмәт шунда: безнең телдә, тамыр сүзгә билгеле бер кушымча ялганып, икенче төрле лексик мәгънәле сүз катгый кагыйдәгә буйсынып кына ясала, теләсә кайсы сүзгә теләсә нинди кушымча ялганып, яңа сүз ясала алмый. Монда шунысы да бар: билгеле бер кушымча ялганып ясалган яңа мәгънәле сүзгә тагын бер төрле кушымча өстәлеп, икенче мәгънәле сүз дә ясала ала. Мондый кушымчаларны сүз ясагыч кушымчалар дип атыйлар һәм аларның һәркайсының үзенә бер төрле сүз ясау сәләте, вазыйфасы була. Мәсәлән: *бакча* (агачлар, үсемлекләр, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б. нәрсәләр үсә торган урын, җир), *бакча+чы* (бакчаны карап, тәрбияләп үстерүче кеше, белгеч), *бакча+чы+лык* (җиләк-җимеш үстерү белән шөгыльләнә торган хуҗалык тармагы). Хәзер инде әле искә алган *дәүләтчелек* сүзен анализлап карыйк. Аны безнең тел әһелләре кайчандыр *дәүләт* сүзенә *-че* һәм *-лек* кушымчалары ялгап ясаганнар. Ләкин бу хәл татар телендәге сүз ясалышы кагыйдәсенә каршы килә. Чөнки дәүләт сүзенә *-че* кушымчасы ялганып яңа сүз ясала алмый: зат мәгънәсендәге дәүләтче дигән сүз юк, шулай булгач, аңа тагын *-лек* кушымчасы ялганып, икенче бер сүз дә ясала алмый.Шул ук вакытта, безнең телдә урысчадагы государственность (государственный строй, государственная организация) мәгънәсен телебезне бозмыйча белдерерлек тиешле чаралар бар: урынына карап, аны *дәүләт, дәүләт төзелеше* һәм *дәүләт* оешмасы сүзләре белән белдерергә мөмкин. Мәсәлән: «Татары еще много веков назад имели свою *государственность*. – Татарларның инде күп гасырлыр элек үк үз *дәүләтләре* (яки *үзләренең дәүләт төзелеше*) булган»; «Многие народы нашей страны обрели *национальную государственность* только при советской власти. – Безнең илнең күп халыклары бары тик совет власте елларында гына *дәүләтле* булдылар (*дәүләткә ия булдылар* һ.б.)». *Дәүләтчелек* атамасы бер телдәге һәр аерым сүз башка телгә дә аерым сүз белән тәрҗемә ителергә тиеш дигән ялгыш караш белән эш итү аркасында барлыкка килгән.

Бу уңайдан бер нәрсәне искәртеп китү мөһим.

Телдәге күп меңләгән сүзләрнең һәртөрле мәгънәләрен төгәл белеп бетерү, зиһендә тоту кыен. Шунлыктан, тел белән эш итүче һөнәр иясенә вакыт-вакыт аңлатмалы һәм тәрҗемә (ике тел) сүзлекләргә карап алырга туры килә. Ләкин алардагы һәр сүзгә һәм аларның аңлатмаларына шиксез дөрес, дип карарга ярамый. Аларда да кайбер ялгышлар була. Димәк, каләм иясенә үзенә телне яхшы белү зарур. Сүзлекләрдән тәнкыйть күзлегеннән карап файдаланырга кирәк. Мәсәлән, шул ук *дәүләтчелек* татар теленең аңлатмалы сүзлегендә бар, ләкин ул татарча дөрес сүз түгел: сүзлек авторлары аны ялгыш урысчадан калькалаштырып алганнар.

Туган телне яхшы белмичә, урысчадан ялгыш тәрҗемә итеп, татар телен ясалма, аңлашылмый торган сүзләр, гыйбарәләр белән чүпләү дәвам итә.

«Ведомости» басмасы, үз чыганакларына сылтама белән... берьеллык план әзерләргә мөмкин, дип хәбәр иткән иде». Бу җөмләдәге *сылтама – ссылка* сүзен урысчадан ялгыш тәрҗемә итүгә гыйбрәтле мисал. Тәрҗемәче, *сылта* тамыр сүзенә *-ма* кушымчасы ялгап, ялгыш сүз ясаган: татар телендә мондый исем юк, *сылтама* дигән фигыль генә бар (*«син аңа сылтама»*). Тәрҗемәче бу очракта яңа сүзне *сылтау* мәгънәсенә таянып ясаган. Ләкин ул урыс телендәге ссылка *(сослаться)* мәгънәсен һич кенә дә белдерә алмый, чөнки *сылтау* ул: 1) нәрсәнедер берәү эшләгән дип күрсәтү, шуңа тагу (ачылмаган җинаятьне, исбатланмаган гаепне һ.б.); 2) аклану яки бәйләнү-һөҗүм итү өчен китерелә торган нигезсез, формаль сәбәп. Телне тиешенчә белмәү, сүзгә җитди карап эш итмәү менә шулай зур мәгънә ялгышына һәм телне бозып куллануга сәбәп була. Мисал итеп китергән җөмләдәге «үз чыганакларына *сылтама белән*» дигән фразаны «үз чыганакларына *таянып*» дип, чын татарча һәм аңлаешлы итеп язарга мөмкин иде бит.

Кайбер каләм ияләре, татарча гына язьйк, сөйлик, дип, кирәгеннән артык тырышып җибәрәләр һәм инде халык тарафыннан күптәннән үзләштерелгән, һәркемгә яхшы аңлаешлы урыс алынмаларыннан, халыкара сүзләрдән баш тартып, яңа сүзләр уйлап чыгарып маташалар.

Туган телне яхшы белмичә, урысчадан ялгыш тәрҗемә итеп, татар телен ясалма, аңлашылмый торган сүзләр, гыйбарәләр белән чүпләү дәвам итә. Соңгы вакытта телебездә шактый еш кулланыла торган шундый сүзләрнең берсе – *кыйммәтләр.* «Гаилә кыйммәтләренә җитди караш югалып бара». Бу җөмләдәге *гаилә кыйммәтләре*н укучы аңлыймы икән? Аңласа, нәрсә дип аңлый? Күпчелек укучыларның аның мәгънәсенә төшенүе бик шикле. Әлеге сүз урыс телендәге *ценности* сүзенең хәрефкә-хәреф ялгыш тәрҗемәсе. Аны уртакул урыс укучысы да аңлап бетерми торгандыр. Татар телендә *кыйммәт* дигән сыйфат сүз төркеме бар *(бәяләр кыйммәт)*, ә *кыйммәтләр* дигән исем сүз юк. *Ценности*ның мәгънәсен белдерерлек татар сүзләре бар, әлбәттә. Сөйләмдә, текстта аны *хәзинәләр, байлыклар, нәрсәләр, әйберләр* кебек сүзләр белән тәгъбир итәргә мөмкин. Мәсәлән: *духовные ценности – рухи хәзинәләр* яки *байлыклар*. Әле мисал итеп китергән җөмләне исә «Гаиләгә яки гаилә белән яшәүгә, яки гаилә корып яшәүгә җитди караш югалып бара» рәвешендә яисә башкача шулайрак итеп, чын татарча төзергә була.

Кайбер каләм ияләре, татарча гына язьйк, сөйлик, дип, кирәгеннән артык тырышып җибәрәләр һәм инде халык тарафыннан күптәннән үзләштерелгән, һәркемгә яхшы аңлаешлы урыс алынмаларыннан, халыкара сүзләрдән баш тартып, яңа сүзләр уйлап чыгарып маташалар. Әмма мондый инициатива уңышлы булып чыкмый. Мәсәлән: «Мөхәммәт Мәһдиевнең истәлекханәсе ачылуга да 10 ел үтеп киткән». Бу җөмләдәге *истәлекханә – музей* дигәнне аңлата. Ләкин *музей* ул – бөтен дөнья телләрендә диярлек кулланыла торган сүз. Аны ниндидер ясалма сүз белән алмаштыруның нигә кирәге булды икән? Аннары, кайсы татар кешесе *музей*ны *истәлекханә* дип әйтер-сөйләр?

Интернациональ *бизнес, бизнесмен* сүзләрен ясалма *эшкуарлык, эшкуар, эшмәкәр* сүзләре белән атап йөртергә тырышу да үзен акламас кебек: *бизнес, бизнесмен* һәр телдә, шул исәптән татар телендә дә ныклы урын алды.

Ахыры киләсе санда ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

«ТАТАРИКА» ТУПЛАНМАСЫ

Тел үзенчәлеге ягыннан төрки галәменә кергән татар халкының мәдәнияте һәм тарихы бөтендөнья мәдәнияте һәм тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Безнең китапханәдә төрле ил галимнәренең татар халкы телен, әдәбият һәм сәнгатен, җәмгыяви фикер үсешен, динен, мәгарифен, мәдәниятен һәм Татарстанның хәзерге үсешен өйрәнеп язган хезмәтләре саклана.

«Татарика» коллекциясенә дөньяның уннан артык телендә язылган документлар керә. Болар – XIX гасыр уртасыннан алып XXI гасыр башына кадәрге вакыт арасындагы басмалар. Монда республиканың һәм татар халкының мәдәнияте, тарихы, әдәбият-сәнгате хакында үз илебездә генә түгел, ә күп кенә чит илләрдә дөнья күргән китаплар да тупलануы бу коллекциянең үзенчәлеген тәшкил итә. Әлеге тупланманың нигезен татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, кулъязмалар һәм сирәк китаплар, чит ил телләрендәге әдәбият, вакытлы матбугат бүлекләрендәге фондларда сакланучы басмалар, газета һәм журналлар, кулъязмалар, сирәк китаплар һәм чит телләрдә чыккан әдәбият тәшкил итә.

Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге фондында тупланманың төп өлеше – чит телләрдә басылган 112 исемдәге 165 данә документ исәпләнә. Шулардан зур кызыксыну уятканнарын санап китик. Азадә-Айшә Рорлих китабы (Rorlich A.-A. «The Volga Tatars: A Profile in National Resilience». – Stanford, 1986), автор чит илләрнең тарих фәнендә беренче мәртәбә кузгаткан теманы – татар халкының бүгенге дәвергә кадәрге үсеш этапларын тулысынча чагылдыра. Икътисадчы, тарихчы Б. Ишболдинның (Isboldin B.) «Essays on Tatar history. – New Delhi, 1963» китабында Алтын Урда дәүләте һәм татар халкының рус дәүләте тарихындагы роле яктыртылган. 2003 елда бу китап татар теленә тәрҗемә ителеп дөнья күрде.

Казан каласына багышланган китаплар да игътибарга лаек: «Kazan – the Enchanted Capital». – London, 1995; Bukharaev R. «Saga of Kazan: a biograpby of a tbousand-year-old city in ten songs». – Slavia: St.Peterburg, 2005; «Osmanli belgelerinde Kazan». – Ankara, 2005 һ.б.

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.


Tatar cuisine
HISTORICAL ANTHOLOGY OF KAZAN TATAR VERSE
Voices of Eternity
Edited and Translated by
David J. Matthews and
Ravil Bukharaev
THE STORY OF JOSEPH
RAVIL BUKHARAEV
Saga of Kazan
Alimdjan Baroudi
premier Moufti élu par la population tartare en 1917
ETYMOLOGISCHES WÖRTERBUCH
DER
TURKO-TATARISCHEN SPRACHEN.
EIN VERSUCH
ZUR DARSTELLUNG DES FAMILIENVERHÄLTNISSES DES TURKO-TATARISCHEN WORTSCHATZES.
VON
HERMANN VÁMBÉRY,
LEIPZIG:
F. A. BROCKHAUS.
1878.

Бүлектә төрек телендәге китаплар да бар: Battal-Taymas A. «Kazan Turkleri: Turk tarihinin hazin yapraklari». – Ankara, 1966; Devletsin T. «Sovyet Tatarstan´i /Ceviren Mehmet Emircan». – Ankara, 1981; Kurat A.N. «Turkiye ve Rusya». – Ankara, 1990; Devlet N. «Idil-Ural Ekspedisyonu. Tatarlar-Baskurtlar- Cuvaslar». – Ankara, 1997 һ.б.

Болгариянең ТАНГРА дигән эзләнүләр үзәгендә болгар халкының тарихына караган фәнни хезмәтләр, легендалар, төрле риваятьләр басылып чыга. Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге фондында Дунай һәм Идел буе болгарлары арасында мәдәни, тарихи бәйләнешләргә багышланган китаплар күренекле урын алып тора. Менә аларның кайберләре: Владимиров Г. «Дунаевска България и Волжка България: формиране и промяна на културните модели (VII-XI в.)». – София, 2005; Владимиров Г. «Другата България на Волга: изгубената цивилизация». – София, 2009; Яруллина Т.С. «Величието на Волжка България: науч.-попул. ст.». – София, 2002; «Българите = The Bulgariane». – София, 2000. – Текст болгарча һәм инглизчә янәшә бирелә; Владимиров Г. «Казанското ханство: история, икономика, култура». – София, 2005 һ.б.

Язма, басма сүз – кешелек җәмгыяте уйлап чыгарган иң бөек могҗизаларның берсе. Аннан башка хәзерге фән һәм техниканың, әдәбият һәм телнең үсешен, халыкларның үзара аралашуын күз алдына китерүе дә кыен. Басма сүз – үткән белән бүгенгене, хәзерге белән киләчәкне бәйләүче күпер дә. Китапларда кешеләрнең күп гасырлар дәвамында тупланган бай тәҗрибәсе, күзәтүләре, уй һәм тойгылары, теләк һәм омтылышлары теркәлгән.

Әбрар Кәримуллин

Коллекциядә Татарстан галимәренең чит илләрдә чыккан китаплары махсус урын били. Мәсьәлән: Fahreddin R. «Altin Orda ve Kazan Hanlari». – Istanbul, 2003; Usmanova L. «The Türk-Tatar Diaspora in Northeast Asia». – Tokyo, 2007; Muhammetdin R. «Turkculuqunun doqusu ve qelisimi». – Istanbul, 1998; Ganiyev F. «Tatarcada birlesik kelime tesekkulu». – Ankara, 2010 һәм башка китаплар.

Татар әдипләренең бүтән телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләре, әдәби багланышларны әтрафлы ачып биргән хезмәтләр шулай ук үзгә бер кыйммәткә ия. Шуларның кайберләрен «кулга тотып» карыйк: «ТҮРК тілді халықтар тарихындагы Габдолла Тоқайдың орны: атты халықаралык гылыми-тәжрибелік конф. материалдары». – Орал, 2013; «Historical Anthology of Kazan Tatar Verse: Voices of Eternity /Ed. f. trasl. by D.J.Matthews, R.Bukharaev». – Curzon,

2000; Ozkan F. «Abdullah Tukay´in şiirleri: Inceleme-Metin-Aktarma». – Ankara, 1994; Nurullin I. «Gabdulla Tukay» adli biyografik eserinin Türkiye türkçesine aynen aktarimi. – Izmir, 1997; Baschirow G. Nafisse: roman. – Berlin, 1954; Ğiylecev A. Bir Avuç Toprak. – Ankara, 2013; Veliyev R. Mavi hüzün. – Istanbul, 2007; Muhammedi R. Sırat küprüsü: Sultan Galiyev. – Istanbul, 1993; гарәп телендә Ә.Еникинең «Җиз кыңгырау» дип исемләнгән хикәяләр җыентыгы, Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилнең төрле телләргә тәрҗемә ителгән китаплары фондта саклана.

Милли китапханәнең аерым структур берәмлеге булып 1987 елда аерымланган чит ил телләрендәге әдәбият бүлеге – «Татарика» тупланмасының бер өлешен үзендә саклаучы урын тора. Монда инде чит телләрдә басылган төрле тармактагы гыйлем чыганакларын туплап, фондны баету юнәлешендә эш алып барылды, шулай ук Татарстан һәм татар халкының мәдәнияте, тарихы, әдәбият-сәнгате турында чит телләрдә басылган хезмәтләрне дә алдыру, теркәү юлга салынды.

Танылган шагыйрь, тәрҗемәче, драматург, галим Равил Бохараевның үз

кулы белән бүләк иткән китаплары коллекциянең мактанычы булып тора. Милли китапханәнең уку залында Равил Бохараевның яңа чыккан китаплары уңаеннан үткәрелгән тантаналы очрашулар китап сөючеләрнең хәтерендәдер. Шундый истәлекле сәхифәләрдән болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» эпик поэмасының инглизчәгә Равил Бохараев тәрҗемә итеп чыгарган китабын 2010 елда (Gali, Kol. The story of Joseph = Kissa'i Yusuf / K. Gali, R. Bukharaev. – Kent: Global Oriental, 2010) тәкъдим итү булды. Бүләк ителгән китапларындагы култамгада шагыйрь үзенең туган шәһәренә – Казанга, китапханәгә карата күңел түрендәге җылы хисләрен белдерә. Милли китапханәбез фондында аның 10 исемдәге китабы саклана.



Татар тарихындагы сәяси күтәрелешне үткен публицистик каләме белән беренчеләрдән булып ачып биргән Гаяз Исхакыйның француз телендәге «Idel-Oural» («Идел-Урал») китабы – фондның аерым бер җәүһәре. Иң башта ул аны Берлинда татар телендә бастыра (1933), аннары рус һәм француз телләренә тәрҗемәдә чыгара (Ishaky A. Idel-Oural. – Paris, 1933). Татар милли хәрәкәтенең күренекле вәкиле, җәмәгать эшлеклесе, олуг әдип, публицист, нашир һәм сәясәтче Гаяз Исхакыйның бу хезмәте татар әдәбиятында классик әсәр булып санала.



«Татарика» коллекциясен танылган венгр сәяхәтчесе, ориенталист, публицист, Урта Азиядә эзләнүләр алып барып гаҗәеп ачышлар ясаган галим – Герман Вамбери хезмәтләре дә мәгънәле баетып тора. Ул 1832 елда Шердагели (Будапешт) шәһәрендә туа. Яшьтән үк, мөстәкыйль рәвештә, төрки һәм Азиянең башка халыклары телләрен өйрәнә башлый. Егерме дүрт яшендә инде ул тел белеменә караган хезмәтләрен бастырып чыгара (1856). Милли китапханәбез фондында бу авторның ике хезмәте бар. Шуның берсе – 1878 елда дөнья күргән төрки-татар этимологик сүзлеге (Vambery H. Etymologisches Wörterbuch der Turko-Tatarischen Sprachen. – Leipzig: F.A.Brockhaus, 1878). Бу хезмәтен язганда ул Шәрыкне өйрәнүче Казан этнографларының да язмаларына таянуы хакында искәрмә бирә.

Дәвамы бар ■

ХӘРБИ ЭЛЕМТӘЧЕ ҺӘЙКӘЛЕ

«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖнең идарә бинасы каршында урнашкан һәм шул ук җәмгыятьнең генераль директоры ***Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин*** *инициативасы белән булдырылган әлеге һәйкәл Бөек Ватан сугышының 70 еллыгы уңаеннан, 2015 елның 7 маенда ачылган иде. Әлеге сугышчы-элемтәче һәйкәле Советлар Союзы Герое Борис Кириллович Кузнецов образын гәүдәләндерә.*

90
ЛЕТ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ
Баталов
Алексей
Владимирович
130
ЛЕТ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ
Туполев
Андрей
Николаевич
ВОИНАМ-СВЯЗИСТАМ

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

РЕВОЛЮЦИЯ КАЙТАВАЗЫ

1905-1907 нче еллардагы Беренче рус революциясе бөтен Россия империясенең эшчеләр хәрәкәтен кузгатып җибәрә. Казан губернасы да искәрмә булмый. Эшчеләрнең чуалышлары Кукмара фабрикаларында да уза.

Кукмарадагы 1906 елгы забастовканы бертуган Комаровлар һәм Вавиловлар фабрикаларының ике эшчесе – Киндеркүл авылы кешесе Әхмәтгариф Насыйбуллин белән Иске Йорттан Мөэмин Әюпов оештыра. Ә «котыртучысы» – Казан губернасыннан I чакырылыш Дәүләт Думасының элекке депутаты П.А.Ершов. Ул Кукмара фабрикалары эшчеләре белән элемтәдә тора. Нәкъ менә Ершов 1906 елның сентябрь башында эшчеләргә «Крестьянский депутат» газетасын һәм берничә хат тапшыра. Әлеге газетада ир-ат эшчеләрнең хезмәтенә көненә – икешәр сум, хатын-кызларга берәр сум түләнергә тиешлеге турындагы мәкалә басылган була. Газетаның бу нөсхәсен эшчеләрдән становой пристав җыеп ала һәм бу хәл Кукмарадагы җитди чуалышларның сәбәпчесенә әйләнә. Әюпов Ершов белән элемтәдә тора һәм кукмаралыларны агитация материаллары белән тәэмин итә. Насыйбуллин исә, укый-яза белмәсә дә, актив агитация һәм пропаганда алып бара. Икесе дә эшчеләр арасында зур абруй казана.

Комаров һәм Вавилов фабрикаларының эшчеләре 1906 елның 12 сентябрендә эшне туктаталар һәм хуҗаларга хезмәт хакын арттыру, туклануны яхшырту турындагы таләпләр куялар. Аерым алганда, бер пар итек баскан өчен түләүне 10 тиенгә арттыру һәм, килешүдә каралганнан тыш, кичке кайнар аш белән чәй бирү турында сүз бара. В.М.Вавилов фабрикасының конторасы, ташламага барып, 5 тиенне өстәп түләргә һәм өстәмә кайнар аш бирүне вәгъдә итә. Әмма Комаровлар фабрикасының хуҗалары әлеге таләпләрне кире кагалар, бу исә киеренкелекне арттыра. Ярсыган эшчеләр төркеме бертуган Комаровларның Кукмара авылы читендәге яңа фабрикасына юнәлә. Н.В.Комаров, эш ташлаучыларның көч

Итек басучылар итекләрне чылату өчен куелган сулы шешәләр белән

куллануыннан куркып, полиция чакырта. Ярсыган эшчеләр урядник Осипов белән стражник Гавриловны кыйнап ташлыйлар. Гайрәтләнеп киткән төркем фабрика бинасының тәрәзә пыялаларын вата. Аяныч нәтиҗәләрдән куркып, Н.В.Комаров аларның таләбен үтәргә ризалаша. Күрәсең, үзләрен җиңүчеләр итеп сизеп, эшчеләр, куркытып, лавкаларның сатучыларыннан 100 сум акча алалар һәм эчү мәҗлесе оештыралар.

Эш ташлаучылар икенче көнне яңадан Вавилов конторасына киләләр һәм аракы алырга 50 сум акча бирүне таләп итәләр, әмма 20 сум гына алуга ирешәләр. Бертуган Родигиннар фабрикасының эшчеләре дә забастовкага кушылырга чакырган хатлар алалар, әмма төпле фикер йөртеп, баш тарталар.

1907 елның башында эшчеләр арттыртуга ирешкән хезмәт хакы яңадан төшә. Дөрес, туклану элеккечә кала. Тәртипсезлекләрне оештырган Насыйбуллин белән Әюпов бер елга күрше Малмыж өязенә сөрелә. П.Ершов исә, Казан дары заводындагы хезмәтеннән куылып, Кукмара авылына сөрелә. Ул андагы фабрикада 1917 елга хәтле эшли.

Кукмарадагы эшчеләрнең чуалышлары 1912 елда яңадан кабатлана. Эшчеләр ит җитмәүдән зарланалар. Фабрика хуҗалары моның сәбәбен иткә бәя күтәрелү белән аңлаталар. Бу чыннан да шулай була. «Бертуган Комровлар» сәүдә йорты эшчеләргә якшәмбе көннәрендә ризык бирү турындагы вәгъдәсен дә боза. Родигиннар да шулай эшли.

Өяз исправнигы бу хакта Казан губернасының өлкән фабрика инспекторына хәбәр итә. Ә тегесе, үз чиратында, карарын фабрика җитәкчелегенә җиткерә. Инспектор фабрикантларны эш шартларын бу хакта эшчеләргә ике атна алдан хәбәр итмичә үзгәртергә ярамавы, ит бирүне киметүнең эшчеләрдә ризасызлык тудыруы хакында кисәтә. Бәйрәм көннәрендә эшчеләрне тәэмин итүнең нормаль хәлгә китерелүен дә таләп итә. Ул чорда менә шундый ныклы күзәтү була! ■

СЕНТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru, tatar-congress.org/ru сайтларында

● 2 сентябрьдә Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев Кыргызстан татарлары белән аралашты. Кыргызстанның «Туган тел» татар-башкорт үзәге активистлары белән очрашу вакытында биредә гомер иткән милләттәшләребезнең яшәеше, сөенеч-шатлыклары һәм кыенлыклары турында сүз барды.

● 6 сентябрьдә ТР Фәннәр академиясендә Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан «Гаяз Исхакый һәм XX гасыр башында татар милли яңарышы» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Әлеге чара уңаеннан конференция материаллары җыентыгы, «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» текстологик җыентыгы (5 нче чыгарылыш), «Гаяз Исхакый фотографияләрдә» буклеты нәшер ителде.

● 6 сентябрьдә Гаяз Исхакый исемендәге «Идел-Урал» фонды (вакыфы) җитәкчесе Түләй Дуран татар әдәбияты классигы, танылган публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның 46 көндәлеген һәм 10 меңнән артык документын Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсенә бүләк итеп бирде.

● 8 сентябрьдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Казакъстан татар милли-мәдәни оешмасы җитәкчеләре белән очрашты. Анда Казакъстан татар һәм башкорт конгрессы җитәкчесе Татарстаннан килгән делегация әгъзаларына «Астанада татар мәдәнияте һәм бизнесы» проектын тәкъдим итте.

● Санкт-Петербург татарлары Татарстан Республикасы көне уңаеннан мәдәни чара уздырды. Программа кысаларында «Тукай энциклопедиясе», «Армия генералы Мәхмүт Гәрәев» китаплары тәкъдим ителде. Залга җыелган тамашачыны Татарстан җитәкчелеге исеменнән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев сәламләде. Татар җәмәгатьчелеге активистларына рәхмәт хатлары тапшырылды.

● Цюрихта ике тугандаш халык – Швейцариянең немецлар яши торган өлешендә һәм Германиядә гомер итүче татарлар һәм башкортлар очрашуы узды. Женевадан читтәге беренче очрашуны Швейцариянең «Юлдаш» Татар-башкорт ассоциациясе оештырды.

● 14 сентябрьдә Башкортстанның Дүртөйле, Тәтешле һәм Балтач районнарында халкыбызның кабатланмас тавышлы җырчысы Хәния Фәрхигә багышланган әдәби-музыкаль чаралар узды.

● 14 сентябрьдә Казан шәһәренең 20 нче гимназиясендә А.Алишның тууына 110 ел тулу уңаеннан квест-уен үтте. Чарада әдип исемендәге премия лауреатлары Ләбиб Лерон белән Йолдыз Шәрәпова, А.Алишның туганнары Гөлшат Сөнкишева һәм Фәридә Алишева катнашты.

● 15 сентябрь көнне Мордовия Республикасының Татар Пешләсе авылында Татар мифологиясе фестивале узды. Тимур Чугонов – проект авторы, оештыручы, Наилә Галиева – идея авторы, этнограф.

● 18 сентябрьдә Дәүләт Советында депутатлар Чистайның Яуширмә авылында Гаяз Исхакый музеен төзекләндерү мәсьәләсен күтәрделәр.

● Удмуртиянең «Иман» татар яшьләре берлеге #ТелБел дип исемләнгән яңа проект башлап җибәргән. Ижау яшьләре формаль булмаган мохиттә татар телен үзләштерәчәк.

● 19 сентябрьдә Бөтендөнья татар конгрессы бинасында узган «түгәрәк өстәл» дә Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, матбугат чараларының баш мөхәррирләре катнашты.

● «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлар оешмасы Алексеевск районының Коры Көрнәле авылына нигез салынуга 800 ел тулуга багышланган кичә үткәрде.

Мирасворд

Башкорт халык биюе

Тирән мәгънәле кыска тәгъбир, хикмәтле сүз

Кояш календарендә 21 апрельдән 21 майга кадәр дәвам итүче ай

Бала чыгармаган, ялгыз кош (диал.)

Антал ... (мажар шагыйре)

1912-1918 елларда Казанда татар телендә чыккан газета

Урта мәктәп (иск.)

... Арагон

Сары акациянең бер төре

Шәйхи Маннур романы

... Садриев

Матурлык, хозурлык

Жырчы ... Каhиров

Язучы, «Ике егет» романы авторы

Гомәр Бәширов повесте

XIII йөз фламанд сәяхәтчесе

Гази ... (язучы, тәнкыйтьче, әдәбият галиме)

XII йөз фарсы-таҗик шагыйре

Аяз Гыйләҗев повесте

Кечкенә шома кайрак

Гыйлем, белем (иск.)

Рәссам ... Абзгильдин

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Шагыйрә ... Рәхимова

Җәядән атыла

Фаҗигале рольләр башкаручы артист

«Рено» моделе

Нәсихәт

«... эзе» (Марат Әмирханов романы)

Гарәп хәрефе

Көчле, гайрәтле

... юлны якын итеп

Ыргыту, ташлау

Браун, Польша

Әрмән язучысы, педагог

... - ялгыз

Чит, ят җир (диал.)

Оясында ... күрсә, очканында шул булыр

... Урда

Мунча себеркесе (диал.)

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: туу, скиф, Җамали, Арад, Хуҗа, Наласа, Әрә, Нево, Оха, Илу, равелин, Тым, нида, асаба, Туктамыш, җәя, «Аймыл», Фәттах, кунак, роль, Садә, кын, чыт.

Өстән аска: хан, Җаек, Ерикәй, Усы, Җәвад, яманат, Таҗдарова, да, тәләкә, Усман, олау, Кара, хи, кяф, һилал, Анат, Фидаи, Саттар, имам, Окс, лыбы, Ашлы, туташ, юнь.

Рәис Габдулла төзеде.

Мәскәү шәһәрендә Муса Җәлил һәйкәле

«БЕЗНЕҢ МИРАС» елъязмасы / октябрь

775 ел элек (1243)

Бөек Алтын Урда дәүләтенә нигез салына. Алтын Урда карамагындагы милләтләр (шул исәптән урыслар да) анда яңача төзелгән дәүләт үрнәген күрәләр; яңа хәрби система белән танышалар; яңача идарә итү вә салым җыю тәртипләрен үзләштерәләр; яңа кануннар белән яши башлыйлар...

660 ел элек (1358)

Мәхмүд ибне Гали шәех әл-Болгари «Нәһҗел фәрадис» әсәрен иҗат итә.

190 ел элек (1828)

Казан университетының төрек-татар кафедрасы мөдире вазыйфасына профессор Мөхәммәтгали Казимбәк билгеләнә. Тора-бара ул кафедрага укыту эшенә Ибраһим Хәлфин, Хөсәен Фәезханов вә Мөхәммәтгали Мәхмүдевләрне җәлеп итә. Кафедра карамагында татар кулъязмаларыннан торган гаять бай китапханә барлыкка килә.

125 ел элек (1893)

Заһир Бигиев Үзәк Азиягә сәяхәте хакында «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле юлъязмасын тәмамлый.

100 ел элек (1918)

22 октябрьдә Үзәк мөселман комиссариаты каршындагы Гыйльми һәйәтнең (рәисе – Мостафа Сөбхи) татар телен фәнни нигезләрдә эшкәртү өчен төзелгән махсус «Имля комиссиясе»нең беренче утырышы уздырыла.

85 ел элек(1933)

30 октябрьдә артист һәм режиссер Газиз Айдарский (1898-1933) вафат була.

65 ел элек (1953)

Татарстан Язучылар берлеге каршында Муса Җәлилнең әдәби мирасын җыю һәм өйрәнү буенча махсус комиссия төзелә.

60 ел элек (1958)

Күренекле калмык шагыйре Давыт Көгелтинов Муса Җәлилгә багышланган «Моабит тоткыны» исемле поэмасын иҗат итә.

10 ел элек(2008)

25 октябрьдә Мәскәү шәһәрендә Муса Җәлилгә һәйкәл ачыла.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. ОКТЯБРЬ 2018



Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова; «Судьба Казанского ханства». Б.Хамидуллин; «Эпитафические памятники Золотой Орды и Казанского ханства на кладбище Ямаширмы». Р.Марданов, И.Хадиев; «Татарские деревни после голода в Поволжье». Р.Сабиров; «Ичкинские татары». Р.Исакаев; «Род Риза казия». Р.Шагиев; «Ахмат бай». Ризаэддин бине Фахруддин; «История мечети и медресе Казиле». Э.Гайнутдинова, Л.Закирова; «От просветительства – к электричеству». З.Мингалиев; «Муса Бигиев: «Будущее за исламом». А.Хайрутдинов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Не только я...». Н.Фаттах; «С благословения Хасана Туфана...». И.Фазлуллин; «Стихи Рашита Гарая».

В глубине памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Дорогу осилит идущий».

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Памятник военному связисту»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. OCTOBER 2018

Historic heritage: «Gaukharshad» by O.Ivanova; «The fate of Kazan khanate» by B.Khamidullin; «The recollection about the Golden Horde and the Kazan khanate are in the graveyard of Yamashurma village» by R.Mardanov, I.Khadiev; «The state of the Tatar villages after starvation» by R.Sabirov; «The Ichken Tatars» by R.Isakaev; «The kin of Riza kaziy» by R.Shagiev; «Akhmat bay (richman)» by Rizaiddin bine Fakhreddin; «The history of Kazile mosque and madrasah» by E. Gaynutdinova, L.Zakirova; «The enlightenment of the Tatar world: beginning from education progress to the usage of electricity» by Z.Mingaliev; «Musa Bigiev: the future is for Islam» A.Khayrutdinov.

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov.

Literary heritage: «I am not alone» by N.Fattakh; «With the blessings of Khasan Tufan...» by I.Fazlullin.

In the deepest store of memory: «Still keeping in the memory, still keeping!».

Creative heritage: «The man going ahead».

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «The monument of the bellman»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

1924 елның 3 мартында Татарстанның Шыгай авылында туа. Иваново сынлы сәнгать училищесын (1942), Харьков сынлы сәнгать институтын (1951) тәмамлый. СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1958), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1968), ТАССРның халык рәссамы (1977).

1983 елның 21 июнендә Казан шәһәрендә вафат була.

Мәснәви Хәйретдин улы Хәйретдинов

«Йорт салу», 1961. Киндер, майлы буяу

«Иркәләнү», 1977. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Клавдия Алексеевна Линария (урындыкта) һәм Эмма белән

(«Шагыйрь Бәдрүш Мокамай». Ф.Хәбибуллин)

Кәче иленә кайчан нигез салынган? Фоат Закиров
Туксан ике елдан соң... Мөнирә Хәлим
Шагыйрь Бәдрүш Мокамай. Фәнүз Хәбибуллин
Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы турында. Аяз Гыйләҗев
Тыңлагыз, Казан сөйли! Фоат Галимуллин

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275 (П-7074)
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.